Безнең МИРАС

05

май 2016

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ



ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ПЕДАГОГИК, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

Тукаебыз төрки дөньяны берләштерә!

25 апрельдә башкалабыз Казанда «Габдулла Тукай һәм төрки дөнья» дип аталган халыкара фәнни-гамәли конференция булып үтте. Бөек шагыйребезнең тууына 130 ел тулу уңаеннан узган бу зур чараны ТР Фәннәр академиясе, Халыкара төрки академия, ТР Мәдәният министрлыгы, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оештырды.

Солтан Исхаков фотолары

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдеменд

Безнең Мирас 12 +

5(52)

май 2016

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

45

46 Нәсүр ЮРУШБАЕВ: **«Тарих «әгәр дә» дип сөйләүне өнәми...»** *Рүзәл Мөхәммәтша*

98 **Гади кеше.** *Илдар Хәйруллин*

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Исмәгыйль Гаспралы (Гаспринский)

ТАРИХИ МИРАС

4 Болгар. Кече манара.
6 Гәүһәр Болгарга килдем... *Р.Мәрданов*
11 Чыңгызхан хәйләсе. *Ә.Мөхәммәдиев*
20 Атка сугылган тамгалар. *Ф.Ислаев*
27 Тукай – ядкярләрдә. *Р.Исламов, Җ.Миңнуллин*
30 Исмәгыйль бәк Гаспринский илә очрашу.
35 Эдуард Ганиев: «Дин һәм туган тел – һәрвакыт янәшә!»
41 Кулаткы морзалары. *Х.Насыйров*
45 Сабантуй. *Кадыйр Әхмәров*

ТАТАР ГАМЕ

46 Нәсүр Юрушбаев: «Тарих «әгәр дә» дип сөйләүне өнәми...» *Р.Мөхәммәтша*
54 Готтхольд Вайль туплаган татар текстлары.

ПЕДАГОГИК МИРАС

60 Гаилә дәресләре. *Ф.Сөләймания*

ДИНИ МИРАС

64 Әманәт. *М.Галләм*
65 Догалы китаплар нәшрияты. *А.Гәрәева*

ӘДӘБИ МИРАС

68 Кутадгу билик. (Котайткыч белем). *Й.Баласагуни*
72 Исхак Мосули һәм кәрҗинле сарай хикәяте.
78 Шагыйрә Газизә Баһаветдин кызы Сәмидова. *Җ.Алмаз*
82 Фатих Кәрим: әсәр, чор, язмыш. *Р.Харис*
88 Үткәннән хатлар: Г.Ахуновтан – А.Шамовка
90 Язгы хатирәләр. *К.Булатова*
92 Үтерүче. *З.Ишаев*

СӘНГАТИ МИРАС

98 Гади кеше. *И.Хәйруллин*
102 Вафирәкәй. *Ә.Шакиров*

ХӘТЕР САГЫНДА

104 Сорбонна шәкерте. *Ф.Дәминова*
106 Затлы мирас – гаиләм ядкяре. *Р.Халитов*

ТАТАР ҖЫРЫ

109 Онытылмас очрашу. *Р.Котлыев*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

112 Миллият сүзлеге. *А.Тимергалин*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

114 «Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1916 елның май ае. *Л.Гобәйдуллин*

ШАЯН МИРАС

116 Көлке куа килә...

119 Мирасворд

120 «Безнең мирас» елъязмасы. *Май*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб ЛЕРОН)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары-
җаваплы сәркатип
Марат Закиров
(Марат Закир)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары – ТР фән һәм мәгариф министры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Ирада Әюпова
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча
мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

Заказ №М-1137. Тираж – 2000 данә. Формат 70 Х 108 1/16
Басарга кул куелды: 4.05.2016
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле

Журнал 2012 елның 17 апрелендә
Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм
коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең
Татарстан Республикасы буенча идарәсендә
ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин төшергән, авторларның һәм Татарстан Милли музее архивларыннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Тышлыкның 1 нче битендә – «Сабан туе алдыннан сөлге җыю». *(Фрагмент)*
Киндер, майлы буяу. 2015 ел. *Равил Заһидуллин рәсеме*

ИСМӘГЫЙЛЬ **ГАСПРАЛЫ** (Гаспринский) (1851-1914)

Телдә, фикердә, эштә берлек!

Милләтнең яртысын хатын-кызлар тәшкил итә, милләтнең киләчәге аналарда. (Милләтнең яртысы хатыннардыр, милләтнең аналары, беренче мәгърибияләре хатыннардыр, аларны да укытырга, алар өчен дә мәктәпләр әзерләргә кирәк.)

Ирләремез укытылып мәдәниятләштерелсә, хатыннарымызның әхвале иҗтимагыя вә мәдәнияләре искечә калса, милләтемез тәрәккый итә алмас.

Улым, сез яшьсез, шунлыктан, кирәгеннән артык каты гыйбарәләр истигъмаль итәсез... Сезнең кеби кызу рухлы яшьләремез милләткә хезмәт итеп аның мәдәни дәрәҗәсен үстерсәләр, ул вакытта без дә сезнең әтрафлар тугрысында сөйләшербез, фикер йөртешербез. Мәдәнияте юк милләтнең промышленносте була алмый... Безнең бу көнге вазифабыз әле мәдәни үсүдән вә шуңар юллар әзерләүдән генә гыйбарәт. Аннан соңгысын бездән соңгылар карарлар...

Кызларым! Сез әсир түгелсез, сез дә ирләр кебек үк хөр, хокуклы инсаннарсыз, сезне наданлыгыгыз, берни белмәгәнлегегездән файдаланып ирләрегез әсир хөкемендә тоталар. Сезгә сатлык хайван, җанлы курчак кеби мөгамәлә кылалар. Сез, кызларым, укыгыз. Мәгълүматлы булыгыз, үзегезнең шәригате исламия һәм инсаният каршындагы хокукларыгызны белеп үзегезне мөдафәгә кыйлырсыз.

Тырышыгыз, балаларым, укыгыз, укыгыз! Ничек кенә булса да алга омтылыгыз, мәгълүматлы милләтләр таптап китмәсен – үзегезне наданлыктан коткарыгыз!

«Тәрҗеман»ны Русиядәге мөселманнарның мәгариф вә тәрәккыйлеккә чыгуларына булышлык итәр өчен чыгарабыз.

Ана телемезне саклауның бердәнбер чарасы саутия берлә укытыла торган ибтидаи мәктәпләремезнең күбәюе вә гомуми булуыдыр. Мондый мәктәпләрне тәмам итеп чыккан шәкертләрнең үз телләреннән аерылу ихтималлары юк, әгәр дә бу турыда мәсьәлә хәл ителмәсә, Уфа вә Казан мөселманнарының, Пенза вә Тамбов мишәрләренең ярым русча вә ярым төрекчә бер шивә берлә сөйләшергә мәҗбүр булганлыкларында шөбһә юк.

Текстны ТР Милли китапханәсе хезмәткәрләре әзерләде. ■

Болгар.
Кече манара

Сәхифәне Нурсөя Шәйдуллина алып бара.

XIY гасырның икенче яртысында төзелгән Кече манара 1712 елгы чыганакларда телгә алына. Ул 16 метрлы таш күләмнән гыйбарәт. Аркалы ишек һәм орнаментлы куыш бик бай бизәлгән, биредә таштан уюның нәфис техникасы кулланылган. Бизәлеш эзләре өске галереяда да сакланган, аңа винтлы таш баскыч алып менә.

Бу манара шәһәрлекнең үзәк өлешендә урнашкан манарадан тәбәнәгрәк булганы өчен Кече дип аталган. Ул мөселманнар өчен аеруча изге урын санала. Татар мөселманнарының Болгардагы борынгы манара һәм мәчетләр янында вафат булганнар рухына дога кылу традициясе бар.

2010 елда «Зенит банклар төркеме»нең борынгы Болгар шәһәренең һәм Зөя утрау-шәһәренең тарихи һәм мәдәни истәлекләрен торгызуда һәм аларны тиешле тәртиптә тотуда катнашуы турында меморандумга кул куелды. 2011 елда банк акчасына Кече манарага реставрация ясалды: диварларын чистарту һәм ныгыту буенча төзү-реставрация һәм консервация эшләре башкарылды, гөмбәзе бакыр белән ябылды. Бу тарихи ядкярнең керү өлеше һәм ишек өстендәге декоратив бизәкнең бер өлеше реконструкцияләнде. ■



Шәһри Болгар бәете

Гәүһәр Болгарга килдем...

Раиф Мәрданов

Шәһри Болгарны Ислам дине кабул ителгән төп үзәк буларак, мөселман татарларның изгеләштереп каравы, хәрабәләрен булса да күрергә бару кебек йолалар күптәннән килгән тарихка ия. Гасырлар дәвамында дини һәм милли изелүгә дучар булган татар халкы Болгарны үзенең рухи таянычы итеп санаган, анда баруны хаҗ кылу кебек фарыз гамәлгә тиңләгән. Бу темага караган бәет-мөнәҗәтләрдәге:

Гәүһәр Болгарга килдем, якут Болгарга килдем,
Шәһри Болгар әүлияларыннан дога алырга килдем,
һәм
Шәһри Болгар мәсҗиденең сиксән сигез баскычы,
Шәһри Болгар вәлиләре ислам диненең ачкычы,

дигән юллар менә шуны ачык дәлилли.

«Шәһри Болгар бәете» текстының бер вариантын матбугатта чыгарган күренекле методист һәм педагог, дәреслекләр авторы, тәрҗемәче һәм журналист, сугыш ветераны Шәриф Сайкин (1900-1999) мондый истәлек бастырган иде. *«Элек-электән килә торган йола буенча, һәр җәй саен Тау ягы авылларында карт-карчыклар, төркем-төркем булып, шәһри Болгарга, борынгы әби-бабайларыбызның нигез туфрагына зыяраткә бара торган булганнар.*

Борынгы бабайларга хөрмәт, төп туган нигезгә мәхәббәт билгесе буларак, бу йола XX гасыр башында да дәвам итте. Җәйге аяз көннәрнең берсен сайлап, безнең Аюкөйдергән авылыннан да берничә карчык ерак сәфәргә чыга иде.

Гыймади абзый Камиләсе шуларны озатучылар арасында булган икән. Урам тыкрыгындагы өянкеләр күләгәсенә сыенып утырган күрше-күлән хатын-кызларга ул шуны хәбәр итә.

Янәшәсендә орчык эрләп утыручы Сара абыстай (Мотыйк абзый хатыны) да сүзгә кушыла:

– Былтыр шул Шәһри Болгар дигән җиргә Кәрим абзый хатыны Зөбәйдә астай да барганые бит. Сәвабы зуррак булсын дип, җырак булса да, җәяү барганнар, – ди.

Күршесендәге адашы Сара да аның сүзен куәтли:

– Шулай, шулай, дөрес әйтәсең, адаш, – ди. (Монысы инде Гыйния Сарасы була. Бу тыкрык арасында гына да Сара атлы хатыннар өчәү бит.)

– Садрый абзый карчыгы Шәмсекамәр астай да шунда җыл саен бара бит. Шуннан кайткач, ул безгә күргән-белгәннәрен сөйләде. Идел арҗагында, урман арасында булган икән ул кала. Заманында бик зур булган. Хан сарайлары, зур-зур ташпулатлары, мәчетләре белән шаулап торган.

Әллә кайлардан килеп чыккан дошманнар шәһәрне басып алганнар да халыкларын кырып, ташпулатларын җимереп бетергәннәр. Берничә ташпулат белән бер-ике мәчет манарасы гына исән калган.

...Карт-карчыклар, барган саен шуларны карап, сакчыларга сәдакалар бирәләр икән. Шәмсекамәр әби әйтә: «Безнең борынгы бабайлар, шул җулбасарлардан качып, безнең җакларга килеп урнашканнар», – ди.

Сара абыстай, орчыгын зырылдатудан туктап торып, әйләнә-тирәсендәгеләргә тагын бер хәбәр сөйләп ала:

– Авылыбызның гыйлем ияләре, мәдрәсә шәкертләре Шәһри Болгарга баручылар турында бәет тә чыгарганнар икән. Зөбәйдә әби шул бәетне яттан сөйли белә. Болгарга барып кайткан саен, ул үзе кебек карчыкларга шуны мөнәҗәт көенә салып сөйли, – ди.

Кайчандыр, бик күптән, моннан әллә ничә дистә еллар элек, җәйге аяз көннәрдә өянкеләр күләгәсендә сөйләшеп, кул эшләре белән юанып утырган хатын-кызларның да күбесе хәзер безнең арада юк. Заманында Шәһри Болгарга зыяраткә йөри торган карчыклар да күптән гүр иясе инде. Шулай ук алар яратып әйтә торган мөнәҗәт-бәет тә күптән онытылган.

Әмма, бәхеткә каршы, бу бәетнең бер язма нөсхәсе күптән түгел генә Кайбыч урман арты төбәгендәге Аюкөйдергән авылында табылды. Бәет XX гасыр башында ук кече күләмле дәфтәргә гарәп хәрефләре белән язылган булган.

Бәетнең яңа табылган бу нөсхәсе шушы төрдәге борынгы язмалар белән ни дәрәҗәдә бәйләнештәдер: шуларның күчермәсеме яки охшаш вариантымы? Бу кадәресен ачыклау – киләчәк эше.

Күренекле галим Шиһабетдин Мәрҗани үзенең фәнни хезмәтендә «Шәһри Болгар газилары» исемле борынгы бәетне искә ала. Бу соңгы кульязманың аңа ни дәрәҗәдә бәйләнешле булуы да ачыкланырга тиеш...»[1]

Шәриф Сайкинның истәлегенә караганда, «Шәһри Болгар бәете»нең бер варианты хәзерге Апас районының Аюкөйдергән авылында иҗат ителгән булган. Бу турыда ул авылдашы Сара абыстай исеменнән әйттерә. Бәетнең авторлары, чынлыкта да Аюкөйдергән авылы кешеләре булганмы яисә башкалармы – хәзергә моны расларга да, кире кагарга да читен. Һәрхәлдә, Ш.Сайкин хатирәсе игътибарга лаек. Ничек булса да, бәет текстларындагы «Ки Тәтешкә барып кердем, кичәсе көймәләр күрдем...», «Тәтеш тавын төшеп җиткәч, пиравазсыз үтеп булмый», дигән юлларга караганда,

[1] Сайкин Ш. Борынгылар мирасы: тарихи истәлек. Шәһри Болгар бәете // Шәһри Казан. – 1991. – 30 октябрь. Астай – абыстай; күенә – көенә.

бәет-мөнәҗәтләрнең кайберләре Идел елгасының уң як тарафында – Тау ягында яшәгән татарлар тарафыннан иҗат ителгәнлеге аңлашыла.

«Шәһри Болгар бәете»нең тексты Татарстан Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «302 т» шифры белән саклана торган кулъязма дәфтәрдән алынды.

Бу кулъязма Татарстан Милли китапханәсенә Яшел Үзән шәһәрендә яшәгән Шәриф Сайкиннан китапханә хезмәткәрләре И.Һадиев һәм Р.Мәрданов тарафыннан 1994 елның 16 апрелендә алынган иде.

Ш.Сайкин Бөек Ватан сугышына кадәр үк Буа һәм Апас районнарындагы авылларда шактый гына кулъязма истәлекләр туплаган. Бу шөгылен аннан соң да дәвам иткән. Соңгы чорда, Яшел Үзәндә яшәгәндә, ишегалдындагы сарайлары янып (1990 нчы еллар башында), туплаган кулъязмаларының шактые харап булган. Ә калган хәтле өлешен, күбесенең читләре янып-көйгән хәлдә, Татарстан Милли китапханәсенә алдырган идек.

«Шәһри Болгар бәете» тексты язылган дәфтәр 10 кәгазьдән гыйбарәт. Аның өч як чите алда әйтелгән янгында зарарланган. Бәетне старшина Шиһаби (Шиһабетдин) улы Хәсән күчергәнлеге күрсәтелгән. Бу дәфтәр якынча XIX гасыр ахыры – XX гасыр башына нисбәтле.

«Шәһри Болгар бәете»нең 2 нче варианты, «Манара төбендә», «Шәһри Болгар баһадирларына», «Болгар батыры Рабига хатынның атасына әйткән һәм үзенең шәкертләренә әйтеп, аларны да бергәләп сугышка өндәве» дип исемләнгән текстлары Татарстан Республикасы Милли музеендагы Зәйнәп Максудова фондында (№18369 фонд) саклана торган кулъязмадан алынды. З.Максудова аларны үз дәфтәренә гарәп хәрефләре белән теркәп куйган. Кайдан күчергәнлеге билгеле түгел. Фәкать соңгысына гына «Борынгы бер язмадан күчерелде», дип искәрткән.

ШӘҺРИ БОЛГАР БӘЕТЕ

Бисмилла берлән башлыйк микән, бер мөнәҗәт әйтик микән.
Бер мөнәҗәт әйтер идек, нәбиләргә охшар микән?

Укыйм микән, җитәр микән, укып файда итәр микән?
Гарибең дә бәнем гомрем һаман шулай үтәр микән?

Бу бакчада нәләр үсә, йимеш микән, чыбык микән?
Шәһри Болгарга барырга тәвәккәлләп чыгыйк микән?

Ки Тәтешкә барып кердем, кичәсе көймәләр күрдем,
Болгар урамыны чыккач, Рабига күлене күрдем.

Рабига күлене күргәч, нә гаҗәбтер, һушым китте.
Коендым да суын эчтем, җаным рәхәтләнеп китте.

Шәһри Болгар агачлары җил искәндә тулалар ла,
Шәһри Болгар вәлиләре каршы чыгып алалар ла.

Манарага менгән чакта «Әмин тәзәк» укый алмыйм,
Шәһри Болгарга бармыйчан, хаҗәтемне үти алмыйм.

Манарасы биек икән, санап мендем баскычын,
Мәсҗетенә керә алмадым, кяфер бирми ачкычын.

Шәһри Болгарга барып кергәч, ашадым бән корбан ашы,
Үкенечем шуннан калды – күрә алмадым Түрә ташын.

Өстемдәдер бәнем җиләнем, җакасына ука чиккән,
Бу дөньяның вафасы юк, сахабәләр җәфа чиккән.

Габдрахман кое каршында дәвә корбан чалалар ла,
Габдрахман кое суын дәва өчен алалар ла.

Манарасы биек икән, күргәч аны калдым хәйран,
Кяферләрнең арасында сахабәләр җата вәйран.

Шәһри Болгар манарасын фәрештәләр төзәтәләр,
Шәһри Болгар вәлиләре Иделгәчә озаталар.

ШӘҺРИ БОЛГАР БӘЕТЕ

Шәһри Болгар манарасын яңа башдан сылыйлар,
Аңар килгән мосафирлар куанышып җылыйлар.

Шәһри Болгар мәдрәсәсен тимер белән ябалар,
Әлхәмделилләһ, бу ни дәүләт, аларны алга алалар.

Гәүһәр Болгарга килдем, якут Болгарга килдем,
Шәһри Болгар әүлияларыннан дога алырга килдем.

Рабига хаҗи, күлеңдә пешә кура җиләге,
Шәһри Болгар вәлиләре – Рәсүлуллаһ бүләге.

Шәһри Болгар болынында үсә былбыл куагы,
Җылый-җылый дога кыйлды, без аларның кунагы.

Шәһри Болгарның тирәсе, җирдә-күктә нурлары,
Шәһри Болгар нарыннан килә җофар исләре.

Шәһри Болгар вәлиләренең каеннары бигрәк матур үскәннәр,
Шәрафәтле шәһәрләрдән ни хәл итеп алар күчкәннәр.

Шәһри Болгар урманында Туйбикәнең зияраты,
Анда килгән мосафирларның кабул булсын морады.

МАНАРА ТӨБЕНДӘ

Манара төбенә җиткәч, меналмам дип сагышладым,
Ике рәкәгать намаз укып, вәлиләргә багышладым.

Шәһри Болгар мәдрәсәсе, һич юк икән тәрәзәсе,
Шәһри Болгар вәлиләренең олуг икән дәрәҗәсе.

Шәһри Болгар, мәсҗидең фәрештәләр югалттылар,
Шәһри Болгар вәлиләре тәкбир әйтеп озаттылар.

Шәһри Болгар мәсҗиденең сиксән сигез баскычы,
Шәһри Болгар вәлиләре Ислам диненең ачкычы.

Җаным көйде, эчем пошты, язып бирмәделәр әйрән,
Җыен кяфер арасында сахабәләр ята вәйран.

ШӘҺРИ БОЛГАР БАҺАДИРЛАРЫНА

Әй, болгарлар, баһадирлар!
Баш күтәрең кабердән!
Безгә инде сез сөйләгез:
Моны кемнәр җимергән?!

Иске ташлар, тирән базлар –
Шәһри Болгар базлары.
Ятар анлар бу заман...
Хәзер кайтып күрсә иде –
Танырмы иде Алмас хан?!

Нә сәбәптән улган вәйран?!
Күңелләрем калды хәйран...

БОЛГАР БАТЫРЫ РАБИГА ХАТЫННЫҢ АТАСЫНА ӘЙТКӘН ҺӘМ ҮЗЕНЕҢ ШӘКЕРТЛӘРЕНӘ ӘЙТЕП, АЛАРНЫ ДА БЕРГӘЛӘП СУГЫШКА ӨНДӘВЕ

Әйдәгез, әйдәгез!
Сез дә бездән калмаңыз!
Кяфер керде куенга,
Кылыч җитде муенга! ■

Чыңгызхан хәйләсе

Әзһәр Мөхәммәдиев

Кыя итәге әле күләгәләр белән капланган, нурлы кояш әле күтәрелеп кенә килә… Затлы киемле, киң маңгайлы, тыныч һәм күркәм йөзенә кара сакалы килешеп торган кырык яшьләр тирәсендәге какча гәүдәле бу кеше малайга сихри әкият дөньясыннан килгән нindидер бер затлы вә мәгърур әүлия булып күренде. Ләкин ул бернинди дә әүлия түгел, ә үз чорының шактый ук авыр тормыш кичергән бер болгар укымышлысы иде.

Әлеге кеше, кызыксынып, киндер күлмәкле, унбиш яшьләр тирәсендәге бу малайның тезләре кыршылып беткән ыштанын жәлләмичә, таштан-ташка ябышып, үрмәләп менүен игътибар белән карап торды. Малай эндәшми генә аңа укны китереп бирде. Атлы кеше аның камыш кискәләгән кулларын һәм ялангач аякларын күрде. Ул шундый, үз-үзен аямый торган, эчкерсез һәм уңган затларны ярата иде.

Шул ук вакытта малайның үткен күзле, ярдәмчел һәм тыйнак булуы, олы кешегә башлап сүз кушарга базмавы да аның игътибарыннан читтә калмады.

Ул аңа елмаеп, үз итеп сүз кушты:

– Ә син минем ни өчен ук атканымны беләсеңме?

– Белмим, – диде малай ирексездән елмаеп. Ул атлы кешенең, елмайса да, киң маңгай астыннан караган күзләрендә сагыш чалымнарын тойды.

– Елганың күпме ераклыкта икәнен үлчәдем. Әнә, күрәсеңме тегендә, астагы үзәндә дөяләр утлап йөри?

Чынлап та, кыя артында төтәгән учак янында кешеләр һәм шунда ук утлап йөргән дөяләр күренде.

– Ул безнең кәрван, – дип сүзен дәвам итте ул. – Болгарга юл тотабыз. Бирედә Идел аркылы кичү бар, дигәннәр иде.

– Кичү тегендәрәк, аз гына югарырак, – диде Бибарс. – Анда, тау итәгендә, чишмә дә бар. Шул турыда.

Кыядан елга буйлап югарырак яшел чирәм белән капланган текә генә тау, ә итәгендә коймаланган чишмә күренә иде.

– Һәйбәт тау. Каравыл каланчасы корырга уңай урын. Каравыл каланчасының ни икәнен беләсеңме? Малайның беләм, дип әйтергә кыюлыгы җитмәде. Атлы кеше исә сүзен дәвам итте: – Әй-йе, илбасарлар яки баскынчылар бәреп кергәнлеген чик буе сакчылары каланчада алдан ук әзерләп куелган корды-сардыга ут төртеп хәбәр салалар. Таудан-тауга, каланчадан-каланчага ут яки төтен баганасы калка һәм яңалык көне-сәгате белән башкалага барып җитә.

Башы журналның 2 нче санында.

– Ә-әнә, тегендә, ерактарак, тау артында, яр буйлап югарыдарак урнашкан кирмән-кала бар. Мин анда бүген сакта тордым.

– Ә син безнең аркышны[1] күрдеңме?

– Юк.

– Хәер, күрмәвең бер дә гаҗәп түгел, чөнки кичә мангул нәүкәрләрен очратканнан соң без чокырлардан, үзәнлекләрдән калкулыкларга менмәскә тырышып килдек. Ә таудан-тауга ут ягып ишарәләү оештырылганмы?

– Юк.

– Кирмән хөкемдарына бу эшне күптән оештыру бик тиеш иде дә… Мангул каганнары Болгар йортына күптән күз ата.

– Мин сезне күрүгә ук, – дип сүз башлады малай кыюланып, – олуг падишаһ, дип уйладым…

Атлы кеше малайга кызыксынып карап куйды. Аннары үзенең сагышлы күзләре белән елмаеп:

– Юк, падишаһ түгел мин, мөгаллим вә остаз буламын, – диде. – Ә атым – Җик Мәргән. Сәүдәгәрләргә Бохарадан ук юл күрсәтеп киләм. Иптәшлеккә яхшы булды. Юллар тыныч түгел. Бохарага дәрес бирермен, дәрес тә алырмын, дип барган идем дә… Заманалар бозылып китте… Ә менә Җилтоягым солтан аргамакларыннан һич тә ким түгел. Төрекмән чапкыны! Ә синең атың ничек?

– Бибарс. Әтием белән Үргәнечкә барган идек тә, анда аны мангул нүкәрләре үтерделәр… – Ул, дулкынлануыннан тамак төбендә ниндидер төер барлыкка килүен тоеп, туктап калды.

Игътибар белән тыңлап торган ир, аякларын язып алмакчы булып, атыннан төште. Ләкин уң аягы җиргә тию белән артка чайкалып китте. Шул мизгелдә Бибарс аның култык астыннан тотып алды һәм өзәңгедән сул аягын бушандырганын көтеп торды.

– Әтиең сугышта һәлак булды алайса. Ә син үзең мангул нүкәрләрен күрдеңме?

Бибарс Үргәнечтә башыннан кичкәннәрен түкми-чәчми сөйләп бирде.

Ошады бу тыйнак, сизгер күңелле һәм кыю кыпчак малае Җик мөгаллимгә.

– Йә, минем белән шәһри Болгарга барырга исәбең юкмы соң? – дип сорады ул Бибарска карап.

Яшьләрнең далаларда урнашкан хәзәр яки кыпчак шәһәрләренә, йә булмаса кара урманнарда урнашкан болгар шәһәрләренә генә түгел, чит илләргә дә күпләп китүен белә иде ул… Сүрия яки Мисыр солтаннарының атлы чирүе дә шул Кыпчактан чыккан төрки егетләреннән тора иде. Аларны «мәнлүк» яки «мәмлүк» дип йөртәләр. Ә янында егетләре булмаган «саламторхан»ны мыскыл итеп, кайчак «мәнсез» дип кенә җибәрәләр. Шуңа күрә Баян мөгаллим Бибарс белән сөйләшкәннән соң, эченнән генә: «Ярар, без дә мәнле булыйк әле», – дип уйлап алды.

Малай кинәт кенә бирелгән бу сорауга ни дип тә җавап бирергә белмәде. Әмма күзләрендә күренеп киткән очкыннар аның теләге зурлыгын күрсәтә иде. Шулай да ул:

– Мин бит кеше кешесе, кирмәндә хезмәт итәм, – диде.

– Бусы комачауламас, – диде Җик Мәргән мөгаллим аңа ышандырырлык итеп.

Яшьләрнең күпләп читкә китүләренең сәбәбен галим кеше булаWhile рак аңлый иде ул. Аның нигезендә

---

[1] Аркыш – кәрван.

«Болгар базары». Р.Хуҗин рәсеме

шәхси бәйсезлеккә, иреккә омтылу ята. Элек урман-елга буйларындагы яшел тугайларның, көтү йөргән киң далаларның төп хуҗасы халык үзе булган. Җир-су мәсьәләләре халык җыелышларында – җыеннарда хәл ителгән. Җыен алдыннан атчабарлар авылдан-авылга, җәйләүдән-җәйләүгә: «Җыенга!» – дип сөрән салып йөргәннәр. Ләкин моннан соң инде күп вакытлар үткән. Хәзер бәкләр һәм морзалар җирнең хуҗалары булып алганнар. Шундый киң тугайларда, иксез-чиксез далаларда мал-туар үз иркендә йөри, әмма дә кешегә хөррият юк – ул нинди дә булса бер бәкнең йә морзаның хөкемендә иде...

Җик мөгаллим, кирмәнгә барып җиткәч, Бурнаш морза белән, якташлар буларак, тиз уртак тел тапты. Бибарсны Болгарга җибәрү мәсьәләсендә исә Бурнаш морза ашыкмады.

– Җибәрә алмыйм, – диде ул. – Үзең уйлап кара: көн саен диярлек бәрелеш, гауга булып тора башлады. Бу мангул дигәннәре үләт кебек – каршы торырга кеше җиткереп булмый. Бүген иртән генә ике уланыбыз авыр яраланды. Кирмәндә болай да сугышчылар аз. Ә мангуллар чынлап торып һәм күпләп килеп һөҗүм итә башласалар нишләрбез?

– Мангуллар басып кергән очракта да, бер малайның гына, гәрчә ул бик уңган вә кыю булса да, ярдәме шуның кадәр генә... Монда инде бөтен Болгар чиреге кирәк...

Морзаның һаман киреләнеп тор-

ганын күреп, ул Җиһангирга карап алды да:

– Соң, Җиһангир морза, син бит бу чик буендагы киеренке хәл турында әмиргә хәбәр салырга тиештерсеңдер ләбаса! Ә белдерүче, һичшиксез, җирле кеше булып, кирмән тормышын һәм андагы хезмәтнең шактый ук яхшы куелышын әмиргә тәфсилләп сөйләп бирергә генә түгел, ә ярдәм дә сорарга тиеш. Аннары сиңа дөресен әйтим, Бурнаш морза, Чыңгыз хан, котырып, халыклар өстенә ташлана гына түгел, ә алар аз гына каршылык күрсәтсәләр дә шәһәрләрен җимертә, яндыра, юк итә, ә халкын кырып сала...

– Карале, Җик бәй, шул унбиш яшьлек малай боларның барысын да Болгар әмиренә тәфсилләп сөйләп күрсәтә алыр, дип уйлыйсыңмы?

– Ә мин нәрсә өчен соң, Бурнаш морза? Миңа шул вәхшиләрнең ерткычлыгын, шул шәһәре белән үтерелеп ташланган кешеләрне үз күзләрем белән күрергә туры килде бит...

***

Җик мәргән, Бурнаш морза белән киңәшкәннән соң, кәрванбашы белән дә сөйләште:

– Биредән аргы якка кичәр өчен дөяләрне, атларны һәм тауарларны бары тик көймәләргә һәм салларга гына төяп алып чыгарга мөмкин икән, – диде ул. – Елга тирән, биредә кичәрдәй сай урын юк, ди. Бигрәк тә хәтәре, әле күптән түгел генә бирегә коллар сатарга дип мангул нукәрләре килгән. Дөрес, аларны үтереп бетергәннәр. Ләкин, син үзең яхшы беләсең, алар үзләренең җайдакларын үтергәнне бер дә яратмыйлар. Димәк, аръякка безгә ашыгып чыгарга ярамастыр. Шундый ук, ләкин ат атланган килеш үтәрлек кичү, яр буйлап беркадәр югарырак күтәрелгәч, Самар дигән кирмән янында да бар икән. Минем фикеремчә, Җиһангир киңәшен тоту уңайрак булыр.

– Мин каршы түгел, Җик әкә, – диде кәрванбашы. – Бик дөрес киңәш. Шулай эшләрбез дә.

***

Бер-берсенә тагылган иллегә якын дөядән һәм атлардан торган кәрван, су буеннан менеп килгән каз көтүедәй, тезелешеп, биек елга яры өстеннән, Бибарсны шәһри Болгарга таба алып китте... Йөрәге телгәләнгән әнисе Бибисара кәрван күздән югалганчы карап торды. Ул күңеле белән сизенә-тоя иде язмышның аларны мәңгегә аерганлыгын. Җитмәсә, ачы җил купты, башыннан яулыгын йолкып алып, еракка – Идел яры астына ук очыртып алып китте. Бу начар фал иде...

Юл уңаенда очраган бүре уы, тубалак, казаягы, тубылга һәм башка күптөрле чәчәкләр, шулай ук бихисап куаклар белән капланган тугайлар, җир җиләге һәм чәчәккә бөреләнгән балан куаклы елга-күл буйлары, караңгы, дымлы нарат урманнары, остазның (ул Җик Мәргәнне шулай атады) үз итеп сөйләгән сүзләре, юлдан алган тәэсир Бибарсның хәтерендә озакка уелып калды.

Ул остазы кушкан кечкенә йомышны да тиз һәм төгәл итеп үтәде. Шул ук вакытта остазының яхшы табигатьле, күркәм холыклы кеше булып, улына караган кебек яратып каравын, ихтирам итүен тоеп, эченнән, күңеленнән генә сөенде дә. Мөгаллимнең әйткән бер сүзе исендә калмаса да, аның һәр сүзе тәэсирле булып, мәгънәсе үк күңелен юатты.

– Син бүген яңа тормыш башлыйсың, – диде ул аңа кирмәннән чыгу белән.

– Мин сине хәзергә үземә каравыш[2] итеп алам. Аннары күз күрер. Синә бары унбиш яшь һәм әллә ни җиңел тормышта үсмәгәнсең. Шуңа да карамастан гәүдәң төз, кыяфәтең сөйкемле, уңган егет күренәсең. Алга таба да шулай булып калырга тырышсаң, иншалла, киләчәгең дә якты һәм имин булыр... Тик бернәрсәне исеңнән чыгарма: кешенең киләчәге, аның язмышы колсатарлар яки морзалар, алпавытлар кулында түгел, ә динебез кануннары буенча, бер Аллабыз кулында. Гомерең буе каравыш булып калырга йә кул эшчесе булып йөрергә теләсәң – булырсың. Әгәр инде атаклы бер остаз, акыл иясе яки уңган һәм гадел бер хәким булырга телисең икән, җегәреңне җик, җәлләмә, иҗтиһад кыл, теләгеңә ирешерсең! Мин үзем дә авыр тормыш кичердем, түбәннән күтәрелдем. Әмма дә узган гомеремә борылып карасам, үкенергә урын юк кебек, чөнки һәрчак яхшылыкка омтылдым һәм, кулымнан килгәнчә, кешеләргә игелек кылырга тырыштым...

***

...Юл озак һәм авыр булды. Алар Самар шәһәренә җиткәнче үк Болга суын кичтеләр. Ниһаять, Ык һәм Чирмешән елгаларын да кичеп, шактый барганнан соң, арыган һәм талчыккан кәрван шәһри Болгарга якынлашты. Шәһәргә якынайган саен җыйнак кына авыллар ешрак очрый башлады. Нарат бүрәнәсеннән салынган йортлар, төзек каралтылар кыр-дала ягында үскән Бибарсның игътибарын үзенә бик тиз җәлеп итте. Казы салып пешерелгән, туйдырып бетергән тары өйрәсе һәм сәфәри кипкән ипи урынына алар авыл халкыннан яңа пешкән икмәк тә сатып алдылар.

Бибарсның игътибарлы булуын, күзәтүчәнлеген күреп, Җик аңа кайбер нәрсәләрне аңлатуны кирәк тапты:

– Әйе, бу якларда халык тырыш. Сугышлар борчымаса, баскынчылар килмәсә, ошбу халык беркайчан да ипекәйгә мохтаҗ түгел. Күрәсең ки, каралтылар нык, әвеннәрдә әле сугылмаган икмәкләре дә тора...

***

Көннәрнең берсендә юлчылар, иртә таңнан ук торып, дөяләрне барлап һәм карап, чистартып, йөкләрен өркәчләргә урнаштырып, кояш чыга башлаганчы ук сәфәргә кузгалдылар. Тузанлы олы юл буйлап шәһәргә таба барган атлы-арбалы авыл халкы салмак кына атлаган дөяләрне ешрак узгалый башлады. Көн төшкә авышканда еракта шәһәр һәм аның мәчет манаралары күренде. Бу гүзәл башкала – шәһри Болгар иде...

Үр менгәч, чикләвек куаклары янында туктап, ерактагы шәһәр уртасында калкуырак урында урнашкан кирмәнгә тәэсирләнеп карап торганнан соң, Җик остаз:

– Күпме генә җирләрдә йөрсәм дә, күпме генә шәһәрләрдә булсам да, шәһри Болгардан да күңелемә хушрак килгәне һәм якынрак булганы юктыр! – диде. Аннары кирмән уртасындагы аеруча гүзәл һәм биек манарага күрсәтеп:

– Ә-әнә, гүзәлләрнең дә гүзәле – Сөлек мәчете була инде! – дип өстәде.

Өйлә җиткәндә генә озын һәм ерак юлдан арыган һәм талчыккан юлчылар шәһәр капкасына якынлаштылар. Алар шәһәргә кергәндә генә «доң-доң-доң» итеп өч мәртәбә сугылган чаң тавышы яңгырады.

Җик мөгаллим, елмаеп, Бибарска карады:

[2] Каравыш – хезмәтче.

– Менә, егет, син шәһри Болгарга кергәндә генә чаң кагалар. Игелеккә булсын! – диде.

– Ни өчен сугалар соң? – дип сорады Бибарс, кызыксынуын яшермичә. – Безнең кирмәндә чаң кагып юлчылар килгәнлеген белгертәләр.

– Бу чаңны, Болгарда әмир Сәлим идарә иткән дәверләрдән бирле, хәзергә кадәр өйлә намазына чакырып сугалар. Ул гадәткә кереп калган, – диде остаз.

Капкадан үтү белән юлчылар күп санлы йортлары, зур-зур мәчетләре булган, киң урамнары халык белән тулып, гөжләп торган шәһәр тормышына юлыктылар. Урам уртасындагы тапталган такыр юлдан яхшы атларга атланган затлы киемле кешеләр үз эшләре белән каядыр ашыга, ә бура ихаталар буйлап нарат такталардан салынган янйөрештән (тротуардан. – *Ред.*) җәяүлеләр атлый. Моңарчы дөясеннән дә төшмәгән кәрванбашы Мөхәммәт Кушлавыч та шәһри Болгарга кергәч, югалыбрак калгандай булды. Җик Мәргән Җилтоякның тезгенен Бибарска тоттырды да, Мөхәммәт Кушлавыч янына килеп, кәрвансарайга ничек барырга кирәклеген өйрәтте. Ләкин тегесенең сәүдә белән Болгарга килүе беренче мәртәбә генә түгел иде булса кирәк, ул алай озаклап сөйләшеп тормады.

Остаз Җик, шаулап торган шәһәр тормышыннан каушабрак калган Бибарс янына килеп, аркасыннан йомшак кына итеп кагып, Җилтояккa атландырды һәм, минем арттан калма дигәндәй, ымлап, үз артыннан алып китте. Җилтояк үзе дә, хуҗасыннан калмаска тырышып, аның артыннан атлады.

Зур үзәк урамнарның берсеннән шактый баргач, бер тыкрыкка борылып керделәр. Һәм шактый төзек булган каралты капкасы янына килеп туктадылар. Җик остаз шомартылган киң һәм төз нарат тактадан эшләнгән арба капкасын ачып тормыйча, Җилтоякны ян капкага китерде һәм болгар халкы гадәте буенча, бөтенләе белән түбәсе каплаулы булган ишегалдына алып керде. Болар бар да Бибарс өчен сәер һәм ят иде.

Сап-сары такталардан сырлап һәм нәкышләп эшләнгән болдырдан бер сөйкемле ханым атылып килеп чыкты, ә аның артыннан, ашыгып, ак сакаллы бабай белән бер карчык та күренде, ә аннары Бибарстан шактый кече булган ике малай йөгерешеп килеп, үзләренең әниләрен кочагына алган остазының аякларына барып сырылдылар. Бу – остазның гаиләсе иде…

Аларның күрешеп, исәнләшеп бетүен көтеп торган Бибарс Җилтоякның йөгәнен капка баганасына кагылган боҗрага бәйләп куйды. Аннары читкәрәк китеп басты. Тормышында нинди үзгәрешләр буласын, шәһри Болгарда аны нинди язмыш көтәсен, әлбәттә, ул әле белми иде…

Остазы аның белән таныштырды:

– Менә бу егет Бибарс була инде. Ул – Бөрҗан кирмәненнән Болгар патшасына яңа хәбәрләр белән җибәрелгән егет! Кыюсызланып торуына игътибар итмәгез, ул мангул дигән илбасарларның берүзе икесен кылычлап ташлаган егет! – диде Җик Мәргән.

ӘМИР БУЯН

Болгар дәүләтенең әмире Буян инде бастырылам дигәндә, кинәт кенә уянып китте. Аның башын тагын шул йокы бирми торган тынгысыз һәм борчулы уйлар басты. Мангул яулары, бигрәк тә аларның Туран шәһәрләрен харап итүләре, ә шәһәр халкыннан төркиләрне аерып алып, далага алып

чыгып, махсус кылычлап үтерүләре турында төрле куркыныч хәбәрләр күптәннән йөри иде инде. Менә алар Болгар йорты чикләренә дә якынлашып киләләр. Моннан ике-өч ел элек кенә мангуллар шәһри Болгарга да һөҗүм итәрләр, дип башына да китерми иде ул. Шәһри Болгар – ерак төньякта, урманнар артында, күчмә баскаклар өчен уңайсыз җирләрдә урнашкан ул. Әлбәттә, урманнар гына түгел, ә берүзе ун илбасарны кырып салырдай өйрәтелгән уланнары да бар. Ләкин башкисәр Чыңгыз баскаклары өчен түгел, күрәсең…

Тәхет залында уздырылган соңгы диван утырышын күзаллады әмир.

…Менә ул утырган тәхет каршында көрәктәй ак сакаллы Гали һәм башка сәетләр утыра… Нишләптер, илгә авырлык килә башласа, хәлиткеч бер генә эшкә дә ярамаган сәетләр күбәя башлый… Алар белән берочтан киң ефәк хөллә һәм башына зур чалма ураган, тирләгән йөзен калкытмыйча, маңгай астыннан гына карап, Хаҗи тархан утыра. Диванда Чыңгызханга баш орыргамы, әллә кичекмәстән сугыш игълан итәргәме, дигән сорау карала. Белә бит ләгъзин мәсьәләнең бик четерекле, җитди булуын, ләкин бер сүз дә дәшми. Чирүне җыяр, төзер, оештырыр һәм коралландырыр өчен күп чыгымнар кирәк. Казнада акча бар-барын, тик бит ул төпсез кое түгел…

Мәрхүм хәлиф Насиретдин хәлифәлек иткән дәвердә Болгарда башта аның исеменнән эре-эре бакыр пуллар, ә соңрак аларны ваграк итеп сугып, уналты пул хисабына көмеш «динарлар» да суктыра башлаган иделәр. Сәүдә эшләре дә гөрли башлады. Тик Үргәнеч тарафыннан килгән кәрваннар белән бергә Туранга бәреп кергән нindидер вәхши Чыңгыз хан сукбайлары турында хәбәр Болгарга да килеп җиткәч, кулдан-кулга күчеп йөргән көмеш тәңкәләр, күрәсең, шунда ук «хәзинәләргә» әверелеп, җиргә күмелделәр, юкка чыктылар…

Узган ел шул ук Хаҗи тархан Арча ягыннан ясак җыю рөхсәтен әмирдән ике йөз мең алтынга сатып алды, ә үз кесәсенә салыр өчен салымны халыктан, һичшиксез, икеләтә артык итеп җыйгандыр…

Әмир үзенең сүзен: «Явыздан күтәрелгән, балаларны ятим, кызгыналарны хур, хатыннарны тол иткән вәхши һәм мәкерле бер илбасар хакимгә баш ору турында сүз дә булуы мөмкин түгел! – дип бетерде. Бу сүзләрне Бордас-инәл, Байчура бегич, чирмеш ягыннан килгән Айпулат кебек бәкләр аягүрә басып, хуплап каршы алдылар. Ләкин боларының, күбесе әмирнең тугрылыклы алпавытлары булсалар да, кесәләре буш анда җилләр уйный. Болар – «салам торханнар» гына иде. Ә Хаҗи, Күбәк, Бикбулат кебек атаклы тарханнар, сәет Галине сөйләп торасы да юк, мыштым гына көлеп утырдылар булса кирәк. Гүя эчтән генә алар: «Яу чабасың киләме, әмир? Чап! Вәләкин бездән чирү оештырыр һәм аны коралландырыр өчен бер тиен дә акча көтмә. Чыңгызмы яки башка бер башкисәр хакимме, безнең өчен барыбер. «Иелгән башны кылыч кисмәс», – ди мәкаль. Тик биләмәләребезне генә таптатмасын, безне тынычлыкта гына калдырсын», – дип утыралар иде…

Төнге шомлы тынлыктан һәм авыр уйлардан башы чыңлаган әмир иртән үк торып, киенеп, дөя йоныннан тукылган келәмле идән буйлап арлы-бирле йөренде. Сарайның арткы ягындагы төрле төстәге пыяла өлгеләр куеп ясалган тәрәзә аша иртәнге кояш нурлары

төшкән бакчага күз салды, ләкин чыкмады. Анда да тынычлык таба алуына ышанмады ул.

Әмирнең инде күптән торганлыгын ишетеп өлгергән шактый олы яшьтәге вәзир Баттал үз бүлмәсенә килеп тәрәзә янына куелган тәбәнәгрәк кенә өстәл артына кереп утырды һәм эшкә кереште. Баттал сакалына чал төшкән илле яшьләр тирәсендәге уртача буйлы, гәүдәсе кирәгеннән артык юаная башлаган кеше иде. Ул, махсус рәвештә ябылып бетмәгән ишегалдыннан үтеп барган әмирне күрү белән, кәгазьләрен җыйды да, ашыга төшеп, бүлмәдән чыкты һәм тәхет залы ишеге төбендә аны куып җитте. Вәзирнең сәламен алганнан соң, әмир:

– Тәхет залына керик, Баттал ага, – диде.

Әмир кәнәфигә, ә вәзир үзенең гадәти урынына барып утырды.

– Ничек анда, яңарак хәбәрләр юкмы, кырагайлар уран (оран. – Ред.) салмыймы? – дип берничә сорау белән берьюлы сүз башлады әмир.

– Бөрҗан кирмәне йөзәгендә йөзәгән җайдак килгән, әфәндем.

– Соң?

–Ургәнечне мангуллар талаган вакытта анда булган ул. Яшь егет. Мангуллар Сәмәркандны да харап иткәннәр икән...

– Бу кадәрлесе дә мәгълүм, беләбез.

– Әйтәсем килгәне шул, – дип өстәде вәзир, – бер төркем качакны исә, мангуллар үзләре коллыкка сату өчен, Бөрҗан кирмәненә китергәннәр – бу кадәрлесен үз күзләре белән күргәннәр. Сәмәркандны җимергәннән соң, Тугай бәкнең утыз меңлек төрки җайдагын башка әсирләрдән аерып, шәһәр читенә чыгарып кылычлаганнар. Мангуллар, бигрәк тә безне – төркиләрне күрә алмыйлар икән.

– Алай...

– Ә аннары Чыңгыз Туран солтаны Мөхәммәтнең башкаласы Үргәнечне ташын-ташка куймыйча җимертеп, шәһәр урынына су җибәрткән, арпа чәчтергән, ди.

– Яман, яман, мангул дигәннәре! Болар бар да хакмы?

– Хак. Солтан Мөхәммәт үзе качкан. Улы Җәләлетдин углан гаскәр туплап, мангулларга каршылык күрсәтүен дәвам итә икән...

– Хәтта Хәлиф Насиретдиннең үзенә каршы кул күтәрергә җөрьәт иткән солтан Мөхәммәт кая булган соң, нишләп ул Чыңгыз гаскәренә каршы күтәрелмәгән?!

Бу соңгы хәбәр әмиргә аеруча тәэсир итте булса кирәк. Ул урыныннан торып, идән буйлап ярсынып йөренә башлады.

– Беләсеңме, мин кем? – диде ул вәзиргә кинәт борылып, – Мин солтан Мөхәммәттән кала, Чыңгыз ханның икенче корбаны!

– Болгар йортында уланнар юк түгел, әфәндем. Ишләребез дә җитәрлек. Иншалла...

– Ишләр – коралың, куәтең барында гына иш! Кул астында җитәрлек кадәр сугышчың, таянырдай бер кодрәтле баһадирың булмаса, ишең дошман баскакларына юл күрсәтеп, күпер салып торучы бер азгынга әверелә.

Вәзир дәшмәде. Хәлнең гаять тә катлаулы булуын, Болгар йорты өчен куркыныч икәнлеген алар икесе дә аңлый иде.

Вәзир Баттал, әмир Буянның мирас буенча тәхеткә утыруына ике ел гына булса да, әле аның әтисе хакимлек иткән вакытта ук вәзирлек вазифасын башкара иде. Вәзир ярдәмендә әмир Буян үзе дә идарә итү гамәлләрен шактый ук тиз һәм яхшы үзләштерде. Әмма

дә заманалар үзгәреп, дөньялар кайный ук башлаган бу чорда, вәзир Баттал мондый җаваплы эшләрне башкарыр өчен үзенең олыгаюын тойды. Яшь әмиргә исә, һичшиксез, чирү җыеп, аны оештырырлык кына түгел, ә яу чабарлык, аның уң кулы булырлык кодрәтле һәм сәләтле кыю баһадир кирәк иде.

Әмир, әрле-бирле йөрүеннән туктап, яңадан диванга килеп утырды да, борчулы тавыш белән сүзен дәвам итте:

– Тураннан килгән берәр зиһенлерәк качакның үзе белән сөйләшергә иде. Дошманның явызлыгын, кайчан баскынлык итәргә җыенуын, сугышта нинди корал һәм хәйләләрдән файдалануын белми торып, аның белән көрәшү мөмкин түгел!

– Андый кеше бар, әфәндем. Ул Бохарадан килгән, әмма үзе чыгышы белән Болгардан. Гаиләсе дә биредә икән.

– Монысы яхшы яңалык. Чакырырга боер үзен!

– Мин, әфәндем, кызыксыначагыңны алдан сизенеп, аңа – ул Җик Мәргән атлы – үзенең сәяхәтнамәсен төзеп китерергә кушкан идем...

Ул өстәл эченнән шактый калын битле бер кульязма чыгарып, аны әмиргә тапшырды. Әмир Баттал вәзирнең шулай алдан чара күрә белү сәләтенә ия булуын исенә төшереп, елмаеп куйды һәм сәяхәтнамәне укырга кереште. Вәзир исә акрын гына ишектән чыгып, үз бүлмәсенә таба юнәлде.

***

Шәһри Болгарга килеп яши башлагач, язмышы Бибарска тагын бер кат игелек күрсәтте: остазы Җикнең хатыны Гәүһәрбикә ханым йомшак һәм киң күңелле кеше булып чыкты. Күп тә үтми остазының ак карын элпәле якты тәрәзә төпләрендә гөлләре чәчәк атып утырган сары нарат бүрәнәсеннән салынган йорты Бибарс өчен күңелгә җылы өстәп һәм өмет чаткылары кабызып торучы урынга әверелде.

Буянның күптөрле йомышларыннан бушап, өйгә сугылып чыккан арада, Рушания апа аны кызыл бакырдан эшләнгән чәйгүнен гөжләтеп, кунакка гына куела торган кәрәзле балын, чәкчәген, җимешен һәм башка ризыгын чыгарып, аны чәй белән сыйлап алырга да өлгерә иде. Ә көзен, эшләр бетә төшкәч, остазы аны үзенең өлкән улы Тәвәккәл белән бергә мәдрәсәгә дәрес алырга җибәрде.

Дәрес алу Корьәннән төрле сүрә яки шигырь ятлаудан гыйбарәт булганга күрә, Бибарсның тырышлыгы, хиреслеге монда да үзенә урын тапты. Бервакыт шулай аның як-якка каранып утыруына игътибар иткән сабак бирүче югары сыйныф шәкерте аңа:

– Сабагың укып утыр, ятла! – дип кисәтү ясады.

– Мин ятладым инде!

– Моны ятлар өчен балалар кыш буе сабакка йөриләр, – диде ул аңа бик ук ышанып бетмичә. – Йәле, сөйләп күрсәт, ятласаң!

Бибарсның хәтере чыннан да укуның ни икәнен дә белмәгән кеше хәтере кебек ачык һәм ни күрсә, шуны истә калдыра, ни укыса, шуны бер кат карап чыгу белән диярлек күңеленә сеңдерә торган хәтер иде. Шуңа күрә дә ул сабагын да ачык итеп яттан сөйләп күрсәтте. Анда мондый юллар да бар иде:

Мәним җаным сәниң гыйшкың беләдир,
Тәнем гаҗиз вәләкин җаным үләдер.
Бу гыйшык гәр булмаса ниткәй ирдем,
Барлык аһым мәним гыйшкым кыладыр!

Дәвамы бар ■

АТКА СУГЫЛГАН ТАМГАЛАР

Фәйзелхак Ислаев

Төрки халыкларда киң таралган иң борынгы тамгалар ыру тамгалары булуы турында галимнәр арасында бәхәс юк диярлек. Һәр ыру үзенең үзенчәлекле традицияләре һәм йолалары, гореф-гадәтләре булган аерым бер төркем булып, соңыннан ырулар кабиләгә, ә кабиләләр төрле союзларга һәм дә дәүләтләргә берләшеп яшәгән. Ыру-кабиләнең иң мөхтәрәм җитәкчесе булып, ул төрле титул белән аталган. Төрки каганатында (VI-VIII гасырлар) илтабар була. Орхон-Янәсәй ташъязмаларында ул «eltebär» - «ельтебер» дип теркәлгән һәм аларда мондый сүзләр бар: «Күлтәгин утыз бер яшендә Алып Шәлче дип аталган ак айгырына атланып оран сала, һөҗүмгә ташлана һәм аз халкының илтабарына һөҗүм итә»; «илтабар Туйгут Күлтәгинне искә алу мәрасимендә катнаша»; «уйгырлар илтабары йөз сугышчы белән көнчыгышка качып китте»; «карлукларның илтабары бер мең ат һәм дә ун мең сарык басып алды»[1].
Язмалардан аңлашылганча, илтабар титулы төркиләрнең аз, уйгыр, карлук кабиләләрендә булган.

Илтабар титулы Идел буе болгарларында X гасырга кадәр сакланып калган. Моны Багдад илчесенең сәркатибе Ибн Фадлан язмалары дәлилли. 922 елны ислам динен кабул иткәндә болгар бабаларыбыз җитәкчесе Алмас (Алмыш) Шиләкә улы илтабар титулында булган. Бу сүзне сәяхәтнамәне урыс теленә тәрҗемә итүче галим А.П.Ковалевский «йылтывар» дип укыган[2].

Борынгы төркиләрнең хокук тарихын тирәнтен өйрәнгән күренекле тарихчы, сәясәтче Садри Максуди фикеренчә, ыру җитәкчесе итеп шактый олы яшьтәге, җитәкчелек итү өчен мөһим сыйфатлары булган шәхесне генә сайлаганнар. Һәр ыруның аерым билгесе – тамгасы да булган[3].

Бабаларыбызның шанлы тарихында иң көчле ыру җитәкчесе Ашина булган (ашина сүзе «зәңгәр», «күк», «хөрмәткә лаеклы», «затлы» мәгънәләрен аңлата). Ашина кабиләсе – VI гасыр уртасында Төрки каганатка нигез салучы. Ул һун патшасының улы һәм аның турында бүредән туган дигән риваять тә бар. Риваятьнең эчтәлеге түбәндәгедән гыйбарәт. Озак еллар зур сазлык буенда яшәгән төрки ыруы күрше

[1] Тугушева Л.Ю. Тюркские рунические письменные памятники из Монголии. М., 2008. С.47, 49, 62, 111.
[2] Ковалевский А.П. Книга Ахмеда Ибн-Фадлана о его путешествии на Волгу в 921-922 гг. Статьи, переводы и комментарии. Харьков, 1956. С.121.
[3] Максуди Садри. Тюркская история и право. Казань, 2002. С.285.

кабилә сугышчылары тарафыннан бер бәрелештә кырып бетерелә. Шулай да, дошманнар тарафыннан яраланган, имгәтелгән ун яшьлек бер малай исән кала. Аны үлемнән бүре коткара һәм аның хатынына әверелә. Тик дошманнар бу егетне барыбер табып үтерәләр. Бүре Турфан үзәненең[4] (оазисының) төньягында урнашкан таулар арасына качып котыла һәм тау куышында үзе коткарган егеттән ун ир бала таба. Бүре тудырган балалар Турфан оазисында яшәүче кызларга өйләнәләр һәм үзләренең ыруларына нигез салалар. Балалар арасында иң гайрәтлесенең исеме – Ашина. Ул туганнарыннан җитезрәк, өлгеррәк булганлыктан, башка ыруларны үзенә буйсындырып берләштерә, яңа кабилә төзи һәм аның юлбашчысы итеп тәгаенләнә. Кабиләдә ырулар саны берничә йөзгә җитә. Ашина варисларыннан булган Асән-шад кабиләне Турфан тауларыннан Алтайга алып килеп урнаштыра. Биредә жуань-жуаннар[5] кул астына эләгәләр, тимер эшкәртәләр, аннан төрле җиһазлар эшлиләр. Алтайда ул кабиләне төрек дип атый башлыйлар. Ә төрек сүзе белән элекке заманда Алтай тауларын атаганнар. Ашина атамасы исә идарә итүче төрки кабиләнең династия исеменә әверелә[6]. Бу риваятьтә ыру атамасының килеп чыгышы, ыру-кабилә җитәкчесен сайлау, ырулар берләшеп кабилә формалашу, кабиләләрнең исемнәре алмашу механизмы бик яхшы тасвирлана.

Ашина ыруының байрагында алтын белән йөгертелгән бүре башы сурәте җилфердәгән. Шунысын әйтергә кирәк: бүре борынгы төркиләрдә байракка төшерелгән символ гына түгел, аның мәгънәсе киңрәк булган. Тарихчы Ю.А.Зуев фикеренчә, бүре төркиләр арасында титулны да аңлаткан икән. Ул титул белән киләчәктә тәхеткә утырачак каганны атаганнар. Әлеге атама борынгы төрки кабиләләренең анасы, нәсел башы бүре икәнлегенә ишарә итә[7]. Икенче версия буенча, бүреләр дип каганны саклаучы гвардияне дә атаганнар. Кызганыч ки, без әлегә кадәр бүре башы нинди символ белән сурәтләнгән икәнлеген күрсәтә алмыйбыз, гәрчә казакълар арасындагы Найман кабиләсенә кергән Матай ыруы тамгасы «бүре» дип атала.

Биредә без Чыңгыз ханның ыруы нәсел башында ала-кола бүре һәм чибәр болан, ә Бөек Болгар дәүләтенә нигез салучы Кубрат ханның Ашина ыруыннан аерылып чыккан Дулу ыруыннан булып, үзләренең нәсел башын изге барс белән бәйләгәнлеген дә искәртеп китәбез. Татарстан гербында урнаштырылган Ак Барс сурәте халкыбызның борынгы тамырларына ишарә ясый.

Әлбәттә, ыруларның ата-бабалары легендар хайваннардан яисә кешеләрдән туган, дигән риваятьләр соңыннан уйлап чыгарылган һәм төркиләрнең тарихи хәтерен формалаштыру өчен борынгы заманнардан бирле сакланган. Илаһилаштырылган хайваннар, кошлар һәм үсемлекләр тамгалар сурәтендә берникадәр чагылыш тапкан. Һәр ыруның үз атамасы, үзбилгесе ыру атамасында саклана. В.Н.Чернецов фикеренчә: «кайбер оч-

---

[4] Турфан үзәне – Синҗан-Уйгыр автономиясендә урнашкан урын.
[5] Жуань-жуан – Кытайдан төньяктагы дала хуҗасы булган төрки халыкларны кытайлылар шулай атаган.
[6] Кляшторный С.Г. Древнетюркские рунические памятники как источник по истории Средней Азии. М., 1964. С.103-104.
[7] Зуев Ю.А. Тамги лошадей из вассальных княжеств // Новые материалы по древней и средневековой истории Казахстана. Труды института истории, археологии и этнографии. Т.8. Алма-Ата, 1960. С.93-140.

ракларда ыру исеме итеп хайван, кош, үсемлек, ә икенче очракта баһадирлык күрсәткән ата-бабаларның берсе, ә кайчакта ыру атамасы итеп кушамат файдаланыла» [8].

Элегрәк тамгада ыруның яклаучысы формасындагы тотем сурәтләнгән. Җәмгыять үсеше белән, ул тотем мәгънәсен һәм әһәмиятен югалтып, көндәлек тормышта файдаланылган предметларга охшатылып яңа исем-атама ала һәм пиктограммага әйләнә. Чынбарлыкта тамгаларның беренче мәгънәсе тотем итеп файдаланылган хайван, кош, үсемлек сурәте икәнлеген борынгы мәдәниятен саклап калган халыкларның этнографиясен өйрәнүче галимнәр күп мәртәбә раслады.

Төркиләрнең иң борынгы ыру-кабилә тамгалары VII-VIII гасырларга караган Кытай елъязмаларында теркәлеп калган һәм саклаган. Ул тамгаларның сурәтләрен һәм ыру-кабилә исемнәрен беренче булып үткән гасырның 60 нчы елларында Кытай чыганакларыннан табып, Алматы шәһәрендә яшәп иҗат итүче тарихчы-галим Ю.А.Зуев фәнни дөньяга чыгара. Заманында кытайлылар төньякта яшәүче төрки кабиләләр белән сәүдә эше алып барганнар, алардан хуҗалыкта файдалану, Тан армиясе өчен атлар сатып алганнар. Атның базар бәясе шактый югары исәпләнгән, бер ат өчен 15-20 кисәк ефәк бирергә туры килгән. Сатып алынган атларга тамгалар да сугылган. Кытайлылар төрки кабиләләрдән сатып алынган тамгалы атларны чын мәгънәсендә затлылык, сыйфатлылык билгесе итеп кабул иткәннәр.

Елъязмада Кытайның төньяк-көнбатыш якларында күчеп йөрүче 36 төрки ыру атамасы һәм тамгасы күрсәтелгән. Без бирeдә урта гасырлар документларында очраган ыру-кабилә исемнәре язылган 12 тамга сурәтен күрсәтү белән генә чикләнәбез, чөнки кайбер тамгалар сурәте кабатлана.

ЫРУ-КАБИЛӘ ТАМГАЛАРЫ

Тамга	**Ыру-кабиләнең кытайча укылышы**	**Ыру-кабиләнең төркичә атамасы**
	Янь-то	Сир, тардуш
	Хуй-хе	Уйгыр
	Фу-ли-юй	Бокли?
	Цзюй-ло-бо	Курабор
	Юй-мэй-хунь	помут-гун

[8] Чернецов В.Е. Нижнее Приобье в I тысячелетии н.э. // МИА. 1957. №58. С.161.

	Чи	Чиг
	А-ши-дэ	Ашина
	Сы-цзе	Сыгир
	Си-цзе	Айгыр
	Цзе-гу	Киркут
	Ци	Кыбир
	А-дэ	Эдиз

Чыганак: Зуев Ю.А. Тамги лошадей из вассальных княжеств // Новые материалы по древней и средневековой истории Казахстана. Труды института истории, археологии и этнографии. Т.8. Алма-Ата, 1960. С.93-140.

Безнең өчен дулат, айгыр, сыгир (сыер), ашина, чиг, уйгыр, сир (сары) ыру-кабилә исемнәре бигрәк тә кызыксыну уята, чөнки аларның кайберләре, чыганакларда сакланып, фәнни әйләнешкә кереп киткән, ә кайберләре безнең өчен яңалык булып күренә. Һәрхәлдә, төрки кабиләләр арасында сыер, айгыр дип аталган кабиләләр турында мәгълүматлар моңа кадәр юк иде.

Тамгалар арасында бигрәк тә Ашина, Эдиз ырулары тамгалары игътибарны җәлеп итә, чөнки аларда Магул империясенең җитәкчеләре, Алтын Урда, Казан, Кырым ханнарының тамгаларына охшашлык сизелә.

Биредә китерелгән сурәтләр аша тамга ыруның тотем хайван исемен йөрткәнен, шулай итеп ыру-кабилә-клан атамасы белән тамга атамасы арасында турыдан-туры бәйләнеш булганлыгы хакында фикер йөртә алабыз. Сирәк булса да, тамга атамасы белән ыру атамасы тәңгәл килгән очраклар бар. Шушы нисбәттән, берничә мисал китереп китәбез.

Тамга һәм ыру-кабилә атамалары арасында табигый бәйләнеш булганлыгы турында казакълар арасында киң таралган риваятьләрнең берсендә кызык мәгълүматлар сакланган. «Урта Җүз җитәкчеләреннән Акджалның законсыз хатыныннан туган 4 улы Кирәй, Уак, Тараклы һәм Тюленгут законлы хатынының 4 улына (Кыпчак, Аргын, Найман, Конграт) хезмәт итәргә тиеш булганнар. Юртаны себергәненең

тамгасы чилик (чыбык); бер урыннан икенче урынга күчеп киткәндә юртаны коручы бакан тамгасын алган (бакан – чырганакны терәп куяр өчен файдаланган җайланма); өченчесе атларны чистартып торган, шуңа күрә аның тамгасы тарак-тамга дип аталган; дүртенчесе кулына пика тотып атларны көтүгә куган, тамгасы пайза (пика) дип аталган».

КАЗАКЛАРНЫҢ ЫРУ-КАБИЛӘ ТАМГАЛАРЫ

Тамга				
Тамга атамасы	Чилик (лоза)	Бакан	Тарак	Пайза (пика)
Кабилә атмасы	Кирей	Уак	Тараклы	Тюленгут

Чыганак: Аристов Н. Опыт выяснения этнического состава киргиз-кайсаков Большой Орды и каракиргизов на основании родословных сказаний и сведений о существующих родовых делениях и о родовых тамгах, а также исторических данных и начинающихся антропологических исследований // Живая история. Вып. III-IV. СПб., 1894. С.404.

Татарларга иң якын халык нугайлар арасында да ыру-кабилә атамасы белән тамга атамасының туры килүе күзәтелә. Каберташларда сакланган тамгалар коллекциясен тикшергәндә Бодырак, Ыргаклы, Кара сыйрак, Кырык чумышлы, Казаяк тамгалары һәмырулары очрый.

НУГАЙЛАРНЫҢ ЫРУ ТАМГАЛАРЫ

Тамга			
Кабилә атамасы	Ыргаклы	Кырык чумышлы	Казаяк

Чыганак: Баскаков Н.А. Ногайский язык и его диалекты. М.-Л., 1940.

Кызганыч ки, татарлар арасында тамгалар һәм ыру-кабилә атамалары арасында бәйләнешне исбатлый торган дәлилләр сакланмаган диярлек. Шулай да, авыллар тарихын тирәнтен өйрәнүче галимә Фирдәүс апа Гарипова хезмәтендә тамгалар һәм ыру-кабилә арасындагы бәйләнеш турында Яшел Үзән районы Акъегет авылына мөнәсәбәтле кызыклы мәгълүмат теркәлгән. Бу авылда 7 кабилә кешеләре яшәгән, һәр ыруның аерым тамгасы да булган. Менә аларның атамалары: чүкеч, казаяк, дүрт сука, бөти (талисман), өчборма, чана муен, тустаган[9]. Кызганыч, биредә тамгаларның сурәте китерелми, шуңа күрә дә биредә үзебезнең тамгалар тупланмасындагыларын гына күрсәтәбез.

Тамга						
Тамга атамасы	Чүкеч	Казаяк	Бөти	Өчборма,	Чана муен	Тустаган

Төрки каганлыкның (552-743 еллар) дәүләт әләме

[9] Гарипова Ф. Авыллар һәм калалар тарихыннан. Казан, 1997. 17 б.

Этнограф Геннадий Макаровның эзләнүләре нәтиҗәсендә, керәшен татарларында сакланып калган ыру тамгаларын да күрсәтү мөмкинлеге туды. Без аны таблица формасында күрсәтәбез:

	Өч җәпле сәнәк тамгалы тукран ыруы
	Ике җәпле сәнәк тамгалы бүре ыруы
	Казаяк тамгалы мәрәс ыруы
	Бөгелҗе тамгалы шайкай ыруы
	Чүкеч тамгалы керән ыруы
	Сәнәк тамгалы үнич ыруы
	Кисәү агачы тамгалы пүләк ыруы
	Ике кыяк чыбык тамгалы кәкәй ыруы
	Бождра тамгалы җапай ыруы
	Әрҗә тамгалы такый ыруы
	Дуга тамгалы кыйтан ыруы
	Аю башы тамгалы тазлар ыруы
	Капка тамгалы чытыр ыруы
	Өч чыбык тамгалы җапай ыруы

Чыганак: Макаров Г. Ыру тамгасы, баш казыгы һәм таш билге – борынгыдан килгән тарихи хәтер билгеләре // Проблемы изучения истории заселения и образования населенных пунктов Альметьевского региона. Казань, 2000. С.143-156.

Борынгы төрки-татар тамгалары – халкыбызның онытылмас мирасы, меңъеллык тарих көзгесе, үткәнебезнең әлегә чишелмәгән сорауларына җавап бирә торган тылсымлы чыганак.

Тамгаларның рәсемен КФУның Л.Н.Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының 4 курс студенты **Булат Мөбарәкшин** ясады. ■

ТУКАЙ – ЯДКЯРЛӘРДӘ

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Рәмил Исламов һәм Җәүдәт Миңнуллин әзерләде.

Габдерахман Галиәкбар улы Камал II (1869-1948) – актёр, режиссёр. Аның тарафыннан зәңгәр кара белән гарәп хәрефләрендә язылган (1946, 6 март) әлеге истәлек хәзерге вакытта Татарстан Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас фондында саклана: 9 ф., 4 тасв., 67 сак. берәмлеге. Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә басыла.

Габдулла Тукай Галиәсгар Камалда кунакта. Камал II истәлеге

Галиәсгар Камалның каенатасы Садыйк Хәйбуллин (җиңги Садыйк) Большой Мишчанский (хәзер Нариман урамы[нда]) бер йорт[1] алып, аны кызының приданы итеп биргән иде. Шул йортның югары катында без әткәй, әнкәйләр белән торабыз, түбән катында Галиәсгар абый хатыны һәм балалары белән тора. Бу ике квартира икесе дә 4шәр бүлмәле һәм аерым кухнале. Түбән катның кухнасында Галиәсгар абыйның приказчигы Габдулла абый Вәлиев белән өйрәнчек малай (ул Юнысовлар прийүтыннан[2] алынган иде) Миңҗан торалар. Һәр ике симийа эчендә аш-су бергә югары кухнада хәзерләнә. Ләкин һәр симийа аерым үз квартирында ашый иде.

Хәтеремдә калмаган, кайсы ел булгандыр, без җомга көнне (безнең сабак-

[1] Казанның Нариман урамындагы 48 нче санлы бу йорт хәзерге вакытта да бар. Ул 2012 елда төзекләндерелде.

[2] Бу ятим балалар йорты 1844 елның 6 декабрендә Казан сәүдәгәрләре, җәмәгать эшлекләре, иганәчеләр агалы энеле Ибраһим (1806-1886) һәм Исхак (1814-1885) Гобәйдулла уллары Юнысовлар тарафыннан нигезләнгән. Ике катлы кирпеч йорт (архитекторы П.И.Романов) 1872 елда үзгәртеп корыла. 1917 елдан соң ябылган. Бинасы хәзерге вакытка сакланып калган (Тукай ур., 89).

тан буш көн) Галиәсгар абый әнкәйгә пилмән һәм катлит, аш артыннан суда җебеткән өрек әзерләргә һәм чәй яныннан мич ашлары пешерергә куша һәм үзенә бик кадерле, якын кунагы киләсен белдерә. Ул вакыттагы бай кызларының гадәте буенча, безнең туганым апа (без Галиәсгар абыйның хатыны Гайшә[3] җиңгәбезне туганым апа дип йөрибез, чөнки аның атасы җиңги Садыйк. Шуңа күрә аңа җиңги дип әйтергә ярамый) җомга көн итеп аталарына кунакка китә. Әткәй җомга намазыннан кайту белән, без (югары өй симийасы) ашыбызны ашыйбыз. Түбән өйдә әле кунак юк. Шул вакытта Галиәсгар абый безнең янга менә дә минем икенче агам Габдулланы (соңга таба атаклы артист Камал I[4]), адрис өйрәтеп, Тукайны алырга җибәрә. Габдулла абый озак йөрми әйләнеп кайта да әнигә: «Галиәсгар абыйга әйтегез, чакырган кешесе өйдә юк», – дип әйтә дә уенга чыгып китә. Бераздан Галиәсгар абый яңадан югары өйгә менә, аңа Габдулла абыйның җавабын әйтәләр. Галиәсгар абыйның ышанасы килми: «Габдулла ялкау ул, бармагандыр (Габдулла абый бала вакытында ялкаурак табигатьле иде), бар, Габдерахман, син барып кайт. Габдулла әфәндене үзең белән алып кил», – дип, миңа «Болгар» нумирларының 39 нчы нумирын өйрәтеп җибәрә.

Мин, нумирны эзләп табып, барып керәм. Бер тәрәзәле, тар гына бер бүлмә. Ишектән кергәч, сул якта – карават, аның өстендә прастина-фәлән юк, кара тышлы бер кечерәк мендәр, җәйге бер адиял бөгәрләнеп ята. Караватның аяк очында, сул як култыкта – бер кечкенә генә умывальник, уңда – өстенә кәгазь генә ябылган кечкенә өстәл. Аның өстендә берничә китап, вак-төяк кәгазьләр чуалып ята. Өстәлнең бер кырыенда пыяладан эшләнгән 7 ле лампа тора. Өстәлнең ике ягында һәм уртасында барлыгы 3 урындык. Уң як эстинага кагылган вишалкада каралып беткән ак төстә бер күлмәк, зур якалы кара бәрәннән эшләнгән дублёный толып, бер кара фуражка эленгән. Тәрәзә төбендә ике буш шешә (берсе кара төстә), тарилкада ашалып бетмәгән французский булки кисәкләре; тәрәзәнең пәрдәсе-фәләне юк. Идән себерелгән иде. Мин бүлмәгә кергәндә, кечерәк буйлы, ябык кына, бер күзе чалышрак карый торган, тузгыган чәчле бер егет ике кулын баш астына куеп караватка сузылып ята иде. Бу кеше Тукаев иде.

Мин барып кергәч, Тукаев бер дә кыяфәтен үзгәртмәде: «Нихәл, җегет (мин малай булсам да, ул мине җегет дип атады), ни йомыш?», – диде.

Мин үземнең Галиәсгар Камалның энесе икәнемне һәм Тукайны кунакка алырга килүемне сөйләдем.

Менә шуннан соң инде Тукайның йөзе үзгәрде, ничектер бер уңайсызлану, ирексезләнү сизелде, йөзе чытылды. Бераз уйга калып торды да: «Син, энекәш, Галиәсгар әфәндегә кайтып әйт: мин авырыйм, кәефем юк, бара алмыйм, ачуланмасын инде», – диде.

Минем борылып чыга башлаган вакытымда: «Мин бер дә кунакка йөреп өйрәнмәгән шул, уңайсыз ничектер», – дип сөйләнеп калды.

Мин кайтып Галиәсгар абыйга Тукайның җавабын әйткәч, Галиәсгар абый: «Бар әле, энекәш, иренмә, тагы бер кат барып кайт. Аның хатын-кыздан коты чыга, Гайшә бар, дип уйлагандыр, шуңа килмәве булыр. Әйт, туганым апа бала-

---

[3] Бибигайшә Садыйк кызы Камалова (1879-1918).

[4] Габдулла Галиәкбар улы Камалетдинов (1893-1933) – актёр, режиссёр, татар профессиональ театрына нигез салучыларның берсе.

лары белән әткәләренә китте, Галиәсгар абый берүзе көтеп тора. Авырса да килсен, аны төзәтергә миндә дару бар, дип әйтте, диген», – диде. Мин яңадан Тукайга киттем. Мин барган вакыт Тукай бүлмәсендә юк иде (ләкин бүлмә ачык иде). Мин бераз көткәч, Тукай сызгыра-сызгыра харчивна ягыннан килеп чыкты. Мин Галиәсгар абый әйткәнчә сөйләдем. Шуннан соң Тукай теләр-теләмәс кенә вишилкага эленгән фуражкасын алып киде, билендәге зиннарын (кара төсле билбау) рәтләде, зур кара толыпны алып киде. Ул кара толып шулкадәр зур иде, алдынгы итәкләре җирдән сөйрәлеп бара иде. Аның аягында ышкулниклар итеге иде (ул итекнең тегелеше арттан түгел, ике ягыннан тегелгән була иде). Без Тукай белән, Евангелистовский урамга чыгып, Большой Мишчанский урамы почмагындагы Аитов Сөләйман[5] йортына кадәр бардык, безнең йортка таба киттек (ул Печән базары аркылы узмады).

Без кайтып кергәндә, Галиәсгар абый янында бер ир кеше бар иде инде. Ул кеше урта буйлы, симез, чалыш күзле, ялтырап торган күгәргән сыман борынлы, авызы тулы алтын тешле, сөйләшкәндә ың-ың итеп тора торган тыңкыш танаулы кеше иде. Аның өсте-башы бик яхшы, алтын сипачкасы күренеп тора, сул кулының чәнчә бармагында борчак кадәр зурлыкта бриллиант кашлы йөзек ялтырый. Бу кеше Галиәсгар Камалның баҗасы (заманасында типтерүләре, бозыклыклары белән халыкка мәгълүм) Хөсәен хаҗи Хөсәенов иде (Оренбургның атаклы миллиунеры Мәхмүд[6] байның улы Хөсәен хаҗи Хөсәенов Казанның җиңги Сабит кызы Хәдичәгә өйләнгән иде. Җиңги Садыйк җиңги Сабит бертуганнар иде. Галиәсгар Камал белән Хөсәен хаҗи баҗайлар иде). Хөсәен хаҗины күргәч, Тукайның кәефе китте, ләкин Галиәсгар Камал:

– Менә, Тукай, таныш бул, бу минем баҗай була, – дигәч, Тукай актырып китте. Галиәсгар Камал яңадан:

– Тукай! Синең ишеткәнең бар бит инде, дөньяда ук хурлар кочып, Кәүсәр шәрабын эчеп, дөнья оҗмахында кәеф-сафа кылучы Оренбур миллиунеры Хөсәен хаҗи Хөсәенев менә шул кеше инде. Минем баҗай була инде ул, – диде.

Тукай:

– Алай бик зур, мөхтәрәм зат икән, – дип җылмайды.

Алар утырыштылар. Галиәсгар абый камудның югары тартмасыннан куе чәй төсле эчемлек торган бер шешә чыгарып өстәлгә куйды (ул коньйак булырга кирәк). Ишек янагына сөялеп торган мине күргәч: «Бар, Габдерахман, әйт, ашарга төшерсеннәр. Шуның белән синең йомыш тәмам булды», – диде. Мин бүлмәдән чыгып киттем. Кунаклар ничек утырганнардыр, мин артыгын белмим, ләкин кунаклар кич җиткәч кенә таралдылар.

Галиәсгар абый соңыннан Хөсәен хаҗиның Тукайны Оренбурга кунакка чакыруын, Тукайның әсәрләрен бастырмакчы булуын, зур гонорар тәкъдим итүен һәм Кәримев-Хөсәеновлар[7] типографиясендә хезмәт тәкъдим итүен сөйләде.

Ләкин Тукай Оренбурга бармады, Хөсәен хаҗиның тоттырган төтен ауларына ышанмады, әсәрләрен Хөсәен хаҗи кулына тапшырмады.

Минем Тукай турында истәлегем барлыгы шуннан гыйбарәт. ■

---

[5] Сөләйман Мөхәммәтҗан улы Аитов (1862-1922) – Казан сәүдәгәре, җәмәгать эшлеклесе, иганәче.
[6] Мәхмүд Мөхәммәтгали улы Хөсәенов (1839-1910) – Оренбург сәүдәгәре, җәмәгать эшлеклесе, иганәче.
[7] «Кәримев-Хөсәенов һәм Ко» – Оренбургта Фатыйх Гыйльман улы Кәрими (1870-1937) һәм Шәмсетдин Хөсәенов матбагасы.

1908 елда «Тәрҗеман» газетасының чыга башлавына 25 тулу һәм 1914 елда күренекле мәгърифәтче, нашир, сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе, педагог, әдип Исмәгыйль Мостафа улы Гаспринскийның вафаты уңаеннан барлык татар газета-журналлары да үзләренең махсус саннарын бастырып тарата, соңрак та аерым язмаисәлекләр дөнья күрә. Игътибарыгызга тәкъдим ителә торган мәкалә «Йолдыз» газетасыннан алынды (1914. – №1284. – 7 октябрь; №1286. – 10 октябрь), ә газетаның мөхәррирләре аны Төркиядә чыгучы «Тасвире әфкяр» газетасыннан күчереп бастырган.

Исмәгыйль Гаспралының «шималь төрекләренә», ягъни Идел буенда яшәүче татарларга мөнәсәбәте ничек булган? Ул нигез салган мәгариф системасы төрки, шул исәптән татарлар тормышына ничек йогынты ясаган? Әлеге сорауларга җавапны мәгърифәтченең Төркиядәге «Тасвире әфкяр» газетасы мөхәррире белән булган әңгәмәсеннән табарга мөмкин. Шунысы игътибарга лаек: Исмәгыйль бәк татар халкын, Русия мөселманнарын төрек укучысы алдында күтәрә, данлый, аларда укый-яза белмәгән һичбер кеше калмады, ди.

Тексттагы кайбер гарәп алынмалары хәзерге әдәби телгә күчереп бирелде, ә стиль, архаик кушымчалар «Йолдыз»дагыча калды.

ИСМӘГЫЙЛЬ БӘК ГАСПРИНСКИЙ ИЛӘ ОЧРАШУ

Бер төркем татар зыялылары. Түбән Новгород шәһәрендә III мөселман съезды үткәрелгән көннәр.
Сулдан уңга утыралар: икенче – Габдулла Бубый, Тимерша Соловьев, Исмәгыйль Гаспринский, Габдулла Әхмәров.
1906 ел, август

«Тасвире әфкяр» газетасының моннан берничә айлар элек чыккан бер нөсхәсе, кайлардандыр әйләнеп килеп, ошбу көннәрдә идарәбезгә килеп җитте. Газетаның бу номерында Исмәгыйль бәк Гаспринскийның җәнаплары илә газетаның мөхәррире арасында булып узган сөйләшүләр һәм Исмәгыйль бәк агызыннан Русия мөселманнары хакында сөйләнгән кайбер сүзләр язылган. Болар тарихи җәһәттән шактый әһәмиятле сүзләр булдыктан, аларның ике арада булган сөйләшүләрен бу урында күчерүне муафыйк күрдек.

Гаспринский илә «Тасвире әфкяр» мөхәррире арасында ошбу рәвешчә әңгәмә булып узган.

Мөхәррир:

– Әфәндем, төньяк тарафындагы кардәшләребездә соңгы көннәрдә күрелгән тәрәккыйләр хакында безгә бераз мәгълүмат бирә алмассызмы?

Гаспринский:

– Бик, бик! Милләт, кирәк хаким, кирәк буйсындырылган милләт булсын, аның яшәве фәкать мәгариф илә генә булуына ышаныгыз. Мәгарифтән мәхрүм булган бер милләт яши торган бер мәмләкәтне теләгән кадәр тимер юллар илә чолгап алыгыз, алар өчен иң мөкәммәл лиманнар ясагыз, тереклек вә тәрәккыйгә ярдәм итә торган нәрсәләрнең иң соң ижат кылынган һәм иң яңаларын кулларына бирегез, шулвакытта әгәр аларда мәгариф булмаса, ул милләт мондый мәдәни нәрсәләрдән файдалана алмас. Бәлки, киресенчә, алардан башкалар файдаланырлар да, мәгарифтән мәхрүм булган милләтләр әүвәлге дәрәҗәләреннән дә түбәнгә төшәрләр, хурлыкка дучар булырлар. Бер милләтне иң шәп, иң яңа сугыш кораллары илә коралландырып карагыз, әгәр ул милләт мәгарифтән мәхрүм булса, боларның һичберсеннән хәер күрмәс. Һәрнәрсәдән элек мәгариф кирәктер. Һәр мәмләкәттә тимер юллардан, банклардан, юллардан, корылмалардан элек, һичшиксез, мәктәп кирәктер. Хәтта мәктәп шулкадәр мөкатдәс һәм мөхтәрәмдер ки, һичбер нәрсә аннан алда була алмыйдыр. Һәрнәрсәдән, хәтта гыйбадәтханәләрдән дә элек, мәктәп булырга тиеш. Әгәр дә эш моның киресенчә булса, күреп торганыбыз шикелле, милләтебезнең күздән югалуы, бетүе мөмкиндер.

Мөхәррир:

– Азияле кавемнәр арасында хакыйкый мәдәнияткә зирәклек күрсәткән, һичбер җирдән ярдәм күрмичә гыйлем алуны күптән уңыш илә җайга салган Русия мөселманнарының уйгану вә тәрәккыйләренең ничек башланганлыгын вә ни сурәттә ачылган вә камилләшкәнен аңлатсагыз иде?

Исмәгыйль бәк:

– 1880 нче еллардан элек Русиядәге мөселманнар бик тирән гафләт йокысында иделәр. Шул елдан башлап, кинәттән, бер уйгану башланып, бөтен милләт мәгарифкә ябышты. Егерме ел эчендә Русия мөселманнарының мәчет вә мәхәлләгә буйсынган мәктәп вә мәдрәсәләре бөтенләй дип әйтерлек ысул җәдидәгә әйләндерелде. Чынлыкта бу мәктәпләр Яуропа мәктәпләре дәрәҗәсендә мөкәммәл булмасалар да, мохит вә миллиятнең ихтыяҗларына артыгы илә йитәрлектер. Русия мөселманнарында мәгариф юлында булган уянулар нәтиҗәсендә узган утыз ел эчендә алты мең кадәр мәктәп барлыкка килде. Бу кадәр мәктәпләрне тәрбия итәчәк мөгаллимнәрнең кайдан йитешүләре тугрысына килсәк, алар дарелмөгаллиминнәрдә[1] йитешмәделәр, чөнки Русиядә мөселманнарга махсус дарелмөгаллиминнәр хәзерге көндә дә булмаган шикелле, ул вакытларда

[1] Дарелмөгаллимин – ирләрдән укытучылар әзерли торган уку йорты.

да юк иде. Бу мөгаллимнәрнең чыгуына 1883 елда Бакчасарайда төзелгән үрнәк ибтидаи *(башлангыч)* мәктәбе булышты. Ел саен Русиянең төрле нокталарыннан монда берникадәр мөгаллимнәр килеп, башлангыч белем бирүнең ысул җәдидәсен, гамәлиятен күреп китәләр иде. Уку срогы өч-дүрт атна иде. Үрнәк мәктәбенә укырга килгән мөгаллимнәрдән яшәү урыны һәм уку өчен һичбер хак кабул ителмидер иде. Бары тик бу мөгаллимнәрдән алмашка, үрнәк мәктәбендәге кеби, үз җирләренә кайтканнан соң, үзләре шикелле ысул җәдидәгә әшнә иң аздан ике мөгаллим йитештерүләре хакында вәгъдә алынадыр иде. Үрнәк мәктәбендә гамәлият күргән мөгаллимнәргә, сәләт дәрәҗәләренә вә булдыклылыгына карап, минем тарафымнан шәһадәтнамә биреләдер иде.

Русия мөселманнары арасында *таралган* ысул җәдидә мәктәпләрендә уку срогы өч елдыр. Дәрес программалары ана телендә укып-язу, бик ачык язылган гыйльме-хәл, төркичәнең кавагыйде сарфиясе *(морфология кагыйдәсе)*, җиңел булган берникадәр мәсьәләләр берлә әгъмале әрбәга *(дүрт гамәл)*, хөсне хат *(матур язу)* һәм мөгаллимнең үзенең сәләтенә карап җәгърафия *(география)*, тарих вә башка фәннәргә караган мәгълүматтан гыйбарәттер. Башта бу ибтидаи мәктәпләрдә ир вә кыз балалар бергә укыйлар иде. Соңыннан күп урыннарда ир балалар вә кызларга махсус аерым-аерым мәктәпләр барлыкка килде.

Төп теләк – бу мәктәпләрдән чыккан балаларның укуга-язуга сәләтле булулары, киләчәктә үзләреннән мәгълүмат һәм уку һәвәсләрен арттырудыр. Чынлыкта, мондый мәктәпләрдән мәгълүмат алган һәм укуга һәвәс булып йитешкән шәкертләр, рус югары мәктәпләренә кермәгәннәре, бер фән вә гыйлемдә белгеч булмасалар да, һәммәсе дә мәгълүмат вә уку илә мәнәүвәр *(нурланган)* бирәр адәм була алмакталардыр.

Буның нәтиҗәсе буларак, Русия мөселманнары арасында, бу заманда укып-яза белмәгән һичбер яшь кеше булмаган шикелле, яшьләрнең күбесе мәктәбе ибтидаиядә алган тәрбияләре буенча өзлексез уку илә мәгълүматларын киңәйтеп килгәнлекләреннән, милли-мәдәни һәм иҗтимагый һәртөрле үзгәрешләр вә вакыйгалардан хәбәрдар булып торалар һәм ул вакыйгаларны һәрвакыт күзәтеп киләләр. Сәүдә йортлары, фабрикалар вә башка оешмалардагы татар хезмәткәрләреннән кайсын гына кулга алсаң да, аларның әхвәл җиһан вә милләттән яхшы ук хәбәрдар булганлыгын, милли вә иҗтимагый мәсьәләләрдә фикер белән дә, эш белән дә азмы-күпме мәшгуль булганлыгын күрәсең.

Русия мөселманнары, ибтидаи мәктәпләрендә укуга һәвәс уяндыру, вә моңа юл күрсәтү нәтиҗәсендә, бер тарафтан нурланганы кеби, икенче тарафтан халык арасында мәгънәсез искелекне яклау бик күп кимеде. Бер тарафтан балаларның ата-аналарында, икенче тарафтан мәктәпләрдә укый торган шәкертләр арасында гыйлем вә мәгариф хакында пәйда булган гадәттән тыш тәкъдир, һәвәс һәм мәхәббәт нәтиҗәсе буларак, халыкны, ялгыз ир балаларын гына түгел, кызларын да мөмкин булган дәрәҗәдә укырга мәҗбүр итмешләр. Мәсәлән, бер авылның имамы кызын милли мәктәпләрдә укытканнан соң, рус гимназиясенә вә аны тәмам иткәннән соң, дарелфөнүннең *(университетның)* тыйббия шөгъбәсенә *(медицина бүлегенә)* бирә. Ниһаять, бер көн бу авыл имамының кызы табибә булып чыга. Мәгарифкә һәвәс нәтиҗәседер ки, өч йөз илле елдан бирле хатыннар хакында кискен рәвештә хөкем сөргән искелек бетеп, ислам кызларына, хәтта мөфти, имам вә ахуннарның кызларына рус

Гаиләсе белән. Уңнан сулга: Зөһрә Гаспринская, Исмәгыйль Гаспринский, Фатыйма ханым (И.Гаспринскийның әнисе), балалары Рифат һәм Шәфика. 1890 ел

урта вә югары мәктәпләренең ишекләре ачылды. Бу көндә пайтәхет *(башкала)* дарелфөнүненең төрле шөгъбәләрендә егермедән артык мөселман кызлары укыган шикелле, Мәскәү дарелфөнүнендә дә ун кадәр мөселман кызы бардыр. Моннан башка Харьков һәм Киев вә башка дарелфөнүннәрдә һәм башка югары мәктәпләрдә дә берникадәр мөселман кызлары укыйлардыр. Гимназияләрдә укучы мөселман кызларының саннары, табигый, тагын да артыграктыр. Янә халык арасында мәгариф һәм укуга һәвәс уянганлыктандыр ки, 1882 нче елдан элек Русиядә бер данә дә мөселман газетасы булмаган хәлдә, хәзерге көндә Казан, Оренбург һәм пайтәхет шәһәрләрендә берничә көндәлек газета вә журналлар нәшер ителмәктәдер. Бу газеталарның гомуми абүнәләрен җыйсаң, 60 илә 70 мең арасындадыр.

Әүвәлдә бәян иткәнемчә, кирәк авыл кешесе булсын, кирәк шәһәр кешесе булсын, Русия мөселманнары арасында укый вә яза белмәгән яшь кеше бик аздыр. Русия мөселманнары арасында китапчылык та бик яхшы тәрәккый иткән. Русия мөселманнарының никадәр хәят иясе булганлыгына бер мисал да, кайбер мәмләкәтләрнең хилафында булапак, аларда зыялы сыйныф илә халык арасында аермалар булмаудыр. Зыялы сыйныф ни уйласа, ни тасвир кылса, ни нәрсәне хөкем кылса, шунда ук һәрбер кеше моннан хәбәрдар була, алар да аңар нисбәт үзләренең урыннарын тәгаен итеп, хөкем кыла башлыйлар һәм шул хактагы фикерләрен бәянга керешәләр. Русия мөселманнарының димагы *(мие)* таза, алар яхшы уйлый, уйлаганын яхшы башкара торган бер инсанга охшыйдыр. Аларда зыялы сыйныфлар ни

уйласа, гомум халык та моннан хәбәрдар була, һәм шуны сизә, һәм үзенә төшкән вазифаларны башкарадыр.

Русиядә әфкяр гомумияне *(иҗтимагый фикерне)* хәрәкәткә китереп, фикер йөртергә һәм нинди булса да бер карарга килергә теләмәгән һичбер милли, иҗтимагый, дини вә икътисади мәсьәлә юктыр. Русия мөселманнарының дини, милли, иҗтимагый вә икътисади файдаларына бәйләнешле бер мәсьәлә мәйданга чыкты исә, гүя бөтен милләт сихерле бер кулга буйсынган шикелле хәзер җанланып, бөтен мәҗлесләрдә, җыелышларда, кыскасы, ике кеше кара-каршы килеп бер җирдә җыелсалар, бөтен фикерләре вә сөйләшүләре шул мәсьәләгә караган була, һәркем фикерләрен уртага салалар, ниһаять, әфкяр гомумия күпчелек илә ул мәсьәлә хакында раслау яки кире кагу илә хөкем чыгара. Әгәр дә ул хөкемне барлыкка китерү кайбер инициативаларга мохтаҗ булса, хәзер берникадәр кешеләр үзләренең эшләрен ташлап, «милләт эше, җәмәгать вазифасы» дип, бу фикерне гамәлгә ашыру өчен тырышалар.

Бары тик Азияи Русиядә, бигрәк тә Төркстандагы мөселманнар арасында гына уяну вә тәрәккый хәрәкәтләре яңарак башланды. Бу якларда уяну бераз соң башланса да, аларның тиз заман эчендә төньяктагы мөселманнарның артларыннан җитүләре өмид ителәдер.

Мөхәррир:

– Әфәндем, хәзер дә Русия мөселманнары күбрәк мәгариф мәсьәләсе илә шөгыльләнәләрме?

Исмәгыйль бәк:

– Бер милләтнең тәрәккые өчен беренче шарт мәгариф икәнлеген сөйләгән идем. Мәгарифсез тереклек тә, төзелеш тә, тәрәккыят тә, сәнәгать тә мөмкин түгелдер. Русия мөселманнарында инде мәгариф юллары тиешлесенчә танылган булганлыктан, үзләренең хакыйкый камилләшүләре тиздән булыр, дип өмид итәргә мөмкиндер.

Бу көндә бөтен әфкяр гомумия икътисадият илә мәшгульдер. Шул сәбәптән хәзерге заман «икътисад дәвере» дип тәгъбир ителсә, бик тугры булыр.

Бүген проблема, бәхәс булган мәсьәләләр, милләтнең икътисад җәһәтеннән күтәрелүенең сәбәпләре банклар, ширкәтләр, фабрикалар төзү кеби икътисади маддәләргә карыйдыр. Русия мөселманнарының милләт тарафыннан танылган юлбашчылары бөтен игътибар-дикъкатьләрен шул ноктага терәгәннәр. Мөселман авылларында бер-бер артлы кооператив ширкәтләре оештырыла, чикләнгән микъдарда бурыч бирү җәмгыятьләре ачыла башлады. Шәһәрләрдә дә взаимный кредит банклары ачыла, боларны оештыруда максат һөнәр ияләренә һәм вак сәүдәгәрләргә мал эшләрендә ярдәмдә булудыр. Алар бик яхшы тәрәккый итмәктәдер ки, җөмләдән Бакчасарайда моннан дүрт ел элек кырык мең сум акча илә ачылган взаимный кредит банкының балансы нәкъ егерме өч миллион сумга йитешмештер. Буның өч миллионы үз суммасы илә әйләндерелгән могамәләләр булып, калганы комиссия һәм әманәтләр илә әйләндерелгән оборотлардыр. Банкның дәфтәрләрен йөртүче язучысыннан башка һәрбер мәэмүрләре, ике директоры һәм идарә мәҗлес рәисе – һәркаюсы мөселманнардыр.

Моннан соң «Тасвире әфкяр» мөхәррире бу ел пайтәхеттә ясалган киңәш мәҗлесе хакында сораса да, Исмәгыйль бәк Гаспринский хәстә булганлы җәһәтенннән ул мәҗлескә бара алмаганлыгын сөйләп, табигый, ул хакта мәгълүмат бирә алмаган.

Текстны басмага
***Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

Эдуард Ганиев: «Дин һәм туган тел – һәрвакыт янәшә!»

Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы районы хакимияте башлыгы, «ГЭКСАР» электротехника заводының генераль директоры, Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты әгъзасы, РФнең атказанган машина төзүчесе, электротехника фәннәре докторы, академик Эдуард Әнвәр улы Ганиев белән әңгәмә.

– Эдуард ага, Сез үз районыгызга, туган җирегезгә хезмәт итүче мөхтәрәм җитәкчеләрнең берсе. Әбибабаларыгыз шушы җирдә нәрсә белән шөгыльләнгән? Ничек көн күргән?

– Җиде буын бабамның исеме мәгълүм, нәсел шәҗәрәбез төзелгән. Мин белгән бабаларымның һәммәсе дә авыл җирендә эшләгән. Аларның үз иген җирләре булган, терлекчелек белән шөгыльләнгәннәр. Бабам, ягъни әтиемнең әтисе Исхак Хәбибулла улы 1908 елда патша армиясенә алына. Мәчет каршындагы мәктәпне тәмамлаган егет бик тиз арада урыс телен өйрәнә, соңрак аны, сәләтен күреп, Варшава шәһәрендәге унтер-офицерлар курсына укырга җибәрәләр. Ул шунда немец телен өйрәнә, тылмач булып китә. Бу һөнәре аңа Вольский цемент заводында эшләгәндә дә ярдәм итә. Әлеге заводның директоры – немец. Бабам анда эшләүче урысларга да тәрҗемәче булган. 1914 елда Исхак бабам Беренче Бөтендөнья сугышына алына, революциядән соң кызылармеецлар ягына күчә, гражданнар сугышы чорында совет хакимияте өчен көрәшә. 1920 елда туган җиренә әйләнеп кайткан бабам, булачак әбием Бәхерниса Габдрахман кызы белән тормыш корып җибәрә.

Кулаткы – урманга бай төбәк. Биредә заманында 16 леспромхоз булган, хәтта сугышка кадәр үк авылларда пилорамнар эшләгән. Төп җитештерү үзәге райүзәктә урнашкан. 1920 еллардан бабам Иске Кулаткы промкомбинатында, соңрак 1944 елга кадәр урман хуҗалыгында җитәкче вазифасын башкарган. Сугыш вакытында биредә хәрби әсирләр хезмәт куйган, чөнки төп эшче көч фронтка киткән була. Бабамның немец телен белүе бу очракта да, һичшиксез, ярдәм иткәндер. 1944 елда Исхак бабам аты белән көчле буранда чыгып китә, кирәкле урынга зур авырлыклар белән барып җитә, әмма өши һәм үпкә ялкынсынуы ала. Ике атнадан бакый дөньяга күчә.

Әтием Әнвәр – гаиләдә беренче бала – 1926 елда туа. Ул сугыш вакытында Куйбышевтагы ФЗӨне бетерә, аз гына вакыт Бөек Ватан сугышында төзүче буларак катнаша, күперләр төзи. Аннары Ташкентка хәрби заводка җибәрелә, шунда топография начальнигы булып эшли, әсир немец офицерлары белән идарә итә, Советлар Союзының карталарын ясый. 1946 елда туган ягына кайта, Иске Мостякта башлангыч класс укытучысы булып эшли башлый, педагогик белем ала. Укытучы, булачак әнием Сафия Хәсән кызы белән гаилә корып җибәрә. Соңрак Муса авылындагы мәктәптә директор урынбасары, озак еллар Иске Атлаш авылында мәктәп директоры булып эшли, яңа мәктәп төзетә, тарих фәнен укыта.

Иске Мостяк – әтинең туган авылы, Муса – әнием Сафияның туган авылы, соңрак, әйткәнемчә, әтиемне Иске Атлашка мәктәп директоры итеп куялар, шунда күченәбез. Без менә шушы өч авылда тәрбияләндек, барыбыз да югары белем алдык.

Исхак бабамның икенче баласы Сәрвәр абый полковник иде. Өченче улы Алмаз озак еллар хәрби очучы булды. Дүртенче улы Марат абый төп йортта, Иске Мостякта яши, «Дружба» колхозында гомере буе прораб булып эшләде. Ул хәзер исә авылыбызның сиксән яшькә җитеп килүче мөхтәрәм карты.

Әниемнең әнисе – Мәликә әби турында аерым әйтәсе килә. Ул Коръән-хафиз булды, заманында Җаекта мәдрәсә тәмамлаган, Муса

«Гани» мәчетен ачу тантанасында

авылының зыялы, укымышлы кешесе – мөгаллимәсе иде. Аның Совет чорында качып-посып балаларга дин сабагы укытуы – үзе бер батырлык. 1930 нчы елларда, өенә тикшерү белән килгәндә, ул кыз балаларны мич яки идән астына качыра торган булган. Бу гамәле өчен аны кулга алып озак ябып та тотканнар, сөргенгә озатабыз, дип куркытканнар. Әмма гомере буе ул иманлы булып калды, авыл кызларына гыйлем һәм тәрбия бирде. Минем әтиәнием дә, совет чоры балалары булуга карамастан, динне хөрмәт итте, алар гарәпчә укый белә иделәр.

Кыскасы, әби-бабаларым җир кешесе булган, кайберләре исә хәрби хезмәттә дәрәҗәләргә ирешкән, мәгарифне үстерүгә дә күп көч салган. Алар, кайда гына эшләмәсен, иманлы, укымышлы, гыйлемле шәхесләр булып, уртак Ватаныбыз – Россиягә намуслы хезмәт иткән.

– Иске Кулаткы районыннан укымышлы имамнар күп чыкканын беләбез. Бүгенге көндә ата-бабаларыгыздан килгән рухи кыйммәтләр сакланамы?

– Татар халкы динне саклаган, дин телне саклаган. Дин белән туган тел – һәрвакыт янәшә. Мин алар арасына тигезлек куям. Дин дә, тел дә гасырлар буена бергә барган һәм, аларга үрелеп, мишәр-татарларның гореф-гадәтләре дә сакланган.

Бүген районыбызда 26 мәчет эшли. Аллага шөкер, аларның һәрберсенең төзелешендә минем катнашым бар. Иске Кулаткыда бүген – биш мәчет. Заманында, икенче мәчет төзелгәч, халык өченчесен сорый башлады. Берзаман «Күмәк көч» газетасын укып утырам: анда Кулаткыга өченче мәчет кирәкме, дип язганнар. Берәү, кирәкми, биредә ике мәчет тә җитә, ди. Мин тоттым да, өченче мәчетне төзеп куйдым. Тора-бара тагын бәхәс кузгалды: өч мәчет Кулаткыга күп, дүртенчесе нигә кирәк булыр икән, дип, тагын бер мәкалә бастырдылар. Бу әле совет идеологиясенең сүнеп бетмәгән вакыты, ике фикернең – дин

Иске Кулаткы авылы

белән дәһрилекнең каршылыклы чоры иде. Мин тоттым да тагын бер мәчет төзеттем һәм аңа әнием Сафиянең исемен бирдем. Аннан тагын, динсезләргә ачу итеп, әтием Әнвәр исеменә бишенче мәчетне төзеттем. Бүгенге көндә, Аллага шөкер, халкыбыз иманга кайтты. Һәрбер мәчеттә, авылларныкында да, мәдрәсәләр эшли, аларда компьютер, урындык-парта, дәреслек – һәммәсе дә бар.

Авыл мәдрәсәләре дә мөгаллимәләр белән тәэмин ителгән. Без теләге булган барлык татар теле һәм әдәбияты укытучыларын да «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыттык. Имамнарыбыз барысы да дини белемле, алар – Сембернең «Биләр» мәдрәсәсендә һәм Казанда белем алган мөхтәрәм затлар. Алар ел саен, абыстайларыбыз өч елга бер «Казанның 1000 еллыгы» мәдрәсәсендә – Ильяс хәзрәт Җиһаншинда берәр атна белем эстәп кайта, шул гыйлем нигезендә аттестация уза. Районыбызда дин өлкәсендә бер генә очраклы кеше дә юк, барысы да үзебез тәрбияләгән, традицион ислам кыйммәтләренә тугры имам-абыстайлар.

Райондашларыбызны аң-гыйлемле итү, югары дин әһелләре белән якынайту өчен 2011 елдан ел саен ишан Хәбибулла хәзрәт Хансөяров истәлегенә багышланган «Хансөяр укулары» һәм елына дүрт мәртәбә «Кулаткы укулары» дип аталган фәнни-гамәли, бер үк вакытта дини конференцияләр үткәрәбез. Быел 14 нче мәртәбә Кулаткы, 6 нчы мәртәбә Хансөяр укулары узды. Гадәттә, язын Хансөяр укулары белән Кулаткы укулары бер вакытка туры килә. Бер көн Хансөяр укулары оештырабыз, Зимничәдә корбан чалабыз, икенче көнне җамигъ мәчеттә Кулаткы укулары була. Кулаткы укуларының берсе, өченче ел инде, Рөстәм Нургали улы Миңнеханов һәм Минтимер Шәрип улы Шәймиевләрнең киңәше белән, Болгар шәһәрендәге Ак мәчеттә уздырыла. Бүгенге көндә әлеге мәчетнең имам-хатыйбы – Иске Мостяк авылы егете Руслан хәзрәт Фәрхетдинов. Без аны Согуд Гарәбстаны, Төркия кебек чит илләрдә укытып, үзебез тәрбияләдек, аңа гыйлем бирдек. Хәзер исә ул үз белеме белән халкыбызга, милләтебезгә игелекле эшләр башкара.

– Татарның хәлле кешеләре борынгыдан әдипләрнең китапларын үз акчаларына бастырган. Сезнең ярдәм белән укучыларга барып ирешкән китаплар бар икәнлеген дә беләбез...

– Авыл тарихларын, биредәге төбәк белгечләренең (краеведлар) китапларын чыгаруны үзебезгә максат итеп куйдык. Соңгы сигез ел эчендә һәр авылның китабы басылып чыкты. Аларның авторлары нигездә тарих, татар теле һәм әдәбияты укытучылары.

– Һәр төбәкнең килгән кунакларны кабат-кабат үзенә җәлеп итә торган тарихи урыннары була. Бу уңайдан, сезнең районда тарихи-мәдәни ядкярләрнең сакланышы ни хәлдә?

– Районыбызда дүрт төп тарихи урын төзекләндерелде. Шуларның беренчесе һәм иң мөһиме – Яңа Зимничәдәге Хәбибулла ишан Хансөяров каберлеге. Зиярәт кылучылар бирегә көн саен килә, ә җомга көннәрендә халык аеруча күп.

Иске Кулаткының үзендә Мәрдән баба каберендә мемориаль комплекс ясалды. Мәрдән баба остазы Хәбибулла ишан янына барганда Кулаткыга җитәрәк туңып үлә.

Өченчесе – Евлейка белән Муса авыллары арасындагы кырда. Революциядән соңгы елларда анда бер мосафир – укымышлы хатын-кыз – ишан бабайга барган юлда вафат булган. «Чыктым юлга, укытучыма зиярәт кылырга...» – дип, ул үзе язып калдырган була. Ул җирләнгән урын әүлия зираты дип атала.

Атлаш авылы янында да укымышлы имамнар каберлеге яңартылды. Мәгълүм булганча, анда 1918 елда унике имамны аталар, әмма аларны җирләргә рөхсәт ителми. Халык аларны төнлә җыеп күмәргә уйлый, әмма берсенең исән икәнлеге ачыклана. Аны төнлә яшереп дәвалыйлар да Саратов өлкәсенә илтәләр. Ул аннан Урта Азия якларына барып чыга, фамилиясен алмаштыра. Хәзерге көндә мин аның уллары, оныгы белән аралашып яшим.

Кулаткы төбәгенең борынгы, халык изге санаган урыннары төзекләндерелде, яңа ташлар куелды, чардуган белән уратылды, юлларга таш түшәлде. Хәтта утырып дога кылырга урын, сәдака салырга махсус савытлар да куелды. Кыскасы, әүлияләр янына зиярәт кылырга теләүчеләр өчен бар мөмкинлек тә бар. Бирегә гади халык белән бергә югары дәрәҗәдәге руханилар да еш сәфәр кыла. Хәбибулла ишан Хәнсөярнең тууына 200 ел тулуны зурлап билгеләп үткәндә бирегә Россиянең иң зур һәм мөхтәрәм 12 мөфтие килде.

Мине суфичылыкны күтәрүдә, аны пропагандалауда гаепләүчеләр еш булды. Әмма Әстерханнан алып, безнең җирләрдә, хәтта Болгарга кадәр элек суфичылык тәгълиматы чәчәк аткан, аның тамырлары бик борынгыга барып тоташа. Безнең традицион ислам кыйммәтләре дә суфичылык тәгълиматы белән тыгыз үрелгән.

– Соңгы елларда рус авыллары белән бергә татар авылларына да юкка чыгу куркынычы яный. Авылларны саклап калу өчен нәрсә эшләргә кирәк, дип саныйсыз?

– Барыгызга да мәгълүм, элек авылдан китү мөмкинлеге юк иде, чөнки җирдә эшләүчегә паспорт бирмәделәр, халык колхозның баганасына береккән иде. Соңрак авылга күпләп техника үтеп керде, йөзләгән кеше ура торган икмәкне бер комбайнчы башкарды һәм кеше кирәкми башлады. Күрше-тирә шәһәрләрдә сәнәгать оешмалары халыкны үзенә йотты, туксанынчы елларда да, колхозлар таркалу нәтиҗәсендә, авылдан халык качты. Ата-аналар да балаларын читкә җибәрү ягын карый... Иске Кулаткыда гына да унберенче сыйныфны тәмамлаган балаларның 95%ы урта махсус һәм югары уку йортына керде, аларның берсе генә дә машинист-тракторчы һөнәрен сайламады. Бу бездә генә түгел, ә Россиянең күп авылларына хас күренеш...

Ничә еллар дәвамында авылда яшәүче әти-әни үзенең балаларына, хәзер инде оныкларына итен, маен, каймагын җибәреп торды, әмма балаларның берсе генә дә авылда яшим, дип кире әйләнеп кайтмады. Күп нәрсә ата-анадан һәм аларның җиргә булган мөнәсәбәтеннән дә тора.

Халыкны тормыш авырлыгы гына җиргә бәйләячәк. Соңгы елларда кризис китереп чыгарган күренешләр, санкцияләр акрынлап шәһәр халкын җиргә, авылга китерә башлады. Менә бүген генә минем яныма 3-4 кеше, абый, авылга кайтам, ызба салырга җир бир инде, дип килде. Кулаткы районында гына да 10-12 кеше эшләргә җир сорый, шунысы куанычлы, барысы да яшьләр... Авылның киләчәге, миңа калса, кооперацияләрдә – бер кеше игенне үстерсен, икенчесе эшкәртсен, өченчесе сатсын, ә башкасы фәкать югары сортлы, элиталы орлык белән генә тәэмин итеп торсын... Бүгенге авыл белгечләргә һәм җирнең чын хуҗаларына мохтаҗ. Хәзер безнең авылларда 43 фермер, шуларның 11е генә югары белемле, 3се генә агроном.

Шулай да без Татарстан Республикасында алып барылган авыл хуҗалыгы сәясәтенә ак көнләшү белән карыйбыз. Сездәге крестьян-фермер һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үзебездә дә булдырырга хыялланабыз.

– Тиздән Иске Кулаткыда Бөтенроссия авыл Сабан туе булачак. Бу мөбарәк бәйрәмгә ни рәвешле әзерләнәсез?

– Сабан туе – татарның ЮНЕСКО таныган бердәнбер бәйрәме, аның гореф-гадәте, традицияләре. Без Сабан туе белән җирдә эшләүче кешене күтәрәбез, аны данлыйбыз. Россия күләмендә үткәрелә торган авыл Сабан туенда төрле төбәктән килгән җир кешеләре, җитәкчеләр бер-берсе белән очраша, тәҗрибә уртаклаша, үзара элемтә урнаштыра. Федераль Сабан туе бәйрәмен оештыруны без башлап җибәрдек. Аның беренчесен 2001 елда Саратов шәһәрендә үткәрдек, аннары Сембер, Мәләкәс, Тольятти, яңадан Саратов шәһәрләрендә оештырдык. Башка Федераль һәм Бөтенроссия авыл Сабантуйларында да булдым, үземә яңа танышлар, дуслар таптым. Иске Кулаткы авылында үтәчәк быелгы Бөтенроссия авыл Сабан туенда илебезнең төрле төбәкләреннән мөхтәрәм кунакларыбызны көтеп калабыз.

Әңгәмәдәшләр – ***Ленар Гобәйдуллин, Рәдиф Сәгъди*** ■

Кулаткы морзалары

Хәнәфи Насыйров

Безнең район җирләре моннан өч гасыр элек «ялан кыр» дип аталган. Көньяк чикләрне ныгыта барып, Петр I XVII гасыр ахырларында бу якларга йомышлы татарларны урнаштыра. Алар Темников, Тамбов, Сембер, Касыйм һәм Казаннан килеп төпләнә.

Мәскәүнең борынгы актлар архивындагы бер документта 1765 елда Саратов казна палатасында статский советник Иван Иванович Нечаев, капитан Иван Кварцов, генерал-майор Петр Никифорович Ивашевларның гаризалары каралуы турында сөйләнә. Алар Кулаткы, Зимница, Кирюшки авылларының җирләрен дәгъва кыла. Казна палатасы түбәндәге эчтәлекле карар кабул итә: «И.И.Нечаев, И.Кравцов, П.Н.Ивашев әфәнделәргә Кулаткы, Зимница, Кирюшкино җирләрен бирмәскә, чөнки әлеге авыллар яхшы хезмәт иткән өчен татарларга Петр I Указы нигезендә тапшырылган». Шунда ук 1700 елның 1 июлендә татар милләтеннән булган йомышлы морзалар Шәмион Уразмәмәтов, Осман (Усман) морза Уразов Тимушин улы һәм алар белән 48 кешенең, Петр I Указы буенча, кырдан 50шәр чирек җир, меңәр чүмәләлек печәнлек (ике морзага), ә калган 46сының 25әр чирек сөрүле җир, 500әр чүмәләлек һәм каралты-кура төзү өчен мәйдан алганлыклары турында мәгълүмат бар.

Архив документларыннан күренгәнчә, 1704 елның 10 гыйнварында янә халык күчеп утыра. Морза Уразгилде Усаев һәм аның якыннары – йомышлы кешеләр, патша Указы буенча, һәркайсы бер ярым дисәтинә җир һәм 55 чирек печәнлек ала. Йомышлы татарлар Кулаткыга шул ук елның 25 гыйнварында да килеп урнаша. Бу юлы морза Байгилде Бакмиевның йомышлы кешеләре – 11 җайдак 50шәр чирек сөрү мәйданы, каралты-кура төзү өчен җир һәм 12,5шәр дисәтинә печәнлек ала. 1704-1705 елларда Сембер морзасы Бәхти һәм аның якыннарына хәзерге Бахтеевка авылы тирәсендәге җирләр өчен Грамота бирелә. Аның белән бер үк вакытта чуваш, мукшы крестьяннары да күчеп утыра.

1718 елның июнендә морза Биктимер Сөнчәләев һәм башка йомышлы татарлар – барлыгы 28 кеше 50шәр чирек сөрүлек җир һәм 1000әр чүмәлә чыгарлык печәнлек, каралты-кура төзетү өчен

Мәкаләнең авторы **Насыйров Хәнәфи Әхмәтҗан улы** – Халык мәгарифе отличнигы, Россия Федерациясенең атказанган укытучысы, 20 елдан артык Иске Кулаткы районы мәгариф бүлеге мөдире булып эшли. Лаеклы ялга чыккач төбәкне өйрәнү музеен, район ветераннар советын җитәкли. Хәнәфи ага – «Иске Кулаткы районы тарихы (1700-2000 еллар)», «Солдаты победы», «Симбирская книга», «История Старокулаткинской районной комсомольской организации за 1920-1990 годы», «История муниципального образования Старокулаткинское городское поселение», «Старокулаткинцы в боях за Родину!», «Детство, опаленное войной» һ.б. китаплар авторы.

җир мәйданы алган. Шул ук елда морза Андургачев үзенең якыннары белән Кулаткы янынннан җир ала һәм туганнарын кыш чыгарга калдырып китә, шулай итеп, Зимница авылына нигез салына.

Урнашуның һәр этабында морзаларга һәм аларга буйсынган кешеләргә күрсәткән хезмәтләренә нисбәтле төрле күләмдә җир мәйданы бирелгән. Ә «йомышлы кешеләр» дигәнне патшаның атлы гаскәре, җайдаклар, дип аңларга кирәк. Патшага морзалар басып алу сугышлары, баш күтәрүләрне бастыру өчен кирәк була. Шуңа күрә ул аларны үзенә якынайта. Татар җайдаклары, тарихтан билгеле булганча, Азов, Полтава, Төньяк сугышларында, Каспий походларында, «башкорт чуалышларын» бастыруда актив катнаша һәм үзләрен кыю, батыр сугышчы итеп таныта, патшага итагатьле икәнлекләрен күрсәтә. Батырлыклары өчен Император бүләге белән бүләкләнгәннәре барлык төр салымнан да азат ителеп, гомер азагына кадәр казна хисабына гына яшәгән. Аеруча Муса, Иске Атлаш, Ислаев (хәзерге Яңа Зимница) авылы атлы гаскәрдә тырышып хезмәт иткән. Бу авылларда аеруча сугышчан морзалар, солтаннар һәм аларның балалары, оныклары яшәгән.

«Кулатка» сүзе «кулат-күл» сүзеннән чыккан. Ул «тозлы күл» дигәнне аңлата. Биредә күп санда чишмәләр һәм коелар булган. Архив мәгълүматларына караганда, 1912 елда Кулаткы халкы 29 чишмәнең һәм 91 коеның суын эчкән. Төбәгебез элек тә, хәзер дә үзенең су запасы белән дан тоткан, һәм аның сыйфаты да төрле булган. Шунысы да кызык: Болгариядә дә Кулат исемле зур авыл бар, аның да исеменең мәгънәсе «тозлы су» дип аңлатыла.

Шулай итеп, XVIII гасыр башында патшага аеруча тырышып хезмәт күрсәткән йомышлы татарлар «ялан кырдан» җир алганнар, аларга рус булмаган әсирләрдән 2-3 хезмәтче дә тотарга рөхсәт ителгән. Шул ук вакытта буш казна җирләренә крепостной крестьяннар да качып килеп урнашкан, чувашлар да көчләп чукындырудан бирегә килгән, шулай ук мукшы милләтеннән дә качаклар булган. Алар бистәләргә берләшкән һәм казна крестьяннарының бер өлешен тәшкил иткән. Чуваш Кулаткы, Зирекле, Лебежайка авылларының барлыкка килүе нәкъ менә шул чорга карый.

Иске бистәләрдән аерым хуҗалыкларның аерылып чыгуы һәм ерак җирләргә күчеп урнашуы нәтиҗәсендә дә яңа авыллар барлыкка килгән. Мәсәлән, 1700-1708 елларда 80нән артык йомышлы татар Кулаткы волостенда 15405 дисәтинә җир ала һәм якынтирәдәге яңа авылларга нигез сала.

Соңрак йомышлы татарлар гаиләләре белән Кулаткыдан ераккарак та аерылып китә башлый. Балта осталары йорт, каралты-кура төзү эшенә яраклы урман үскән җирләрне сайлый һәм 1787 елда Иске Яндовка авылы барлыкка килә. Биш ел эчендә бу авылда яшәүчеләрнең саны 60ка җитә, ә 1793 елда Иске Яндовкадан ун гаилә аерылып чыга һәм Яңа Яндовкага нигез сала. Бу авылларда яшәүчеләр арасында әле һаман да туганлык җепләре саклана. Усть Кулаткы авылы исә 1780 елда Иске Кулаткыдан күчеп килүчеләр исәбенә барлыкка килә.

Тагын бер мисал: 1714-1725 елларда 92 морза гаиләсе Терешка елгасының уң як яры буенда 20000 дисәтинә (һәр кеше башына 50 һәм 25 чирек) җир ала. Бу гаиләләр иң элек Югары Терешка авылына нигез сала, соңрак, аннан аерылып, Урта Терешка, Мансур, Карамалы, Каргалы авыллары бар-

лыкка килә. Казна палатасы алар янына Кирюшки (Кирюшкино) һәм Яңа Терешка авылларын да булдыра.

Безнең бабаларыбыз ничек яшәгән? Алар күчеп утырган дәвер – XVIII гасырның беренче яртысында – Урта Идел буенда, бөтен Россия империясендәге кебек үк, феодаль-крепостной мөнәсәбәт хөкем сөрә. Бабаларыбызга бирелгән җирләр дәүләт милке булып санала һәм аны сатарга, алыштырырга да дәүләт рөхсәтеннән кала беркемнең дә хакы булмаган. Йомышлы морзалар, татар милләтеннән булган солтаннар үз җирләрен үзләре кебек үк морзаларга гына сатарга хокуклы булган.

Хәнәфи Насыйров китаплары

1720 елдан морзалар әкренләп үзләренең өстенлекләрен югалта. Петр I ислам динендә булган алпавыт-морзаларга крепостнойлар тотуны тыя. Морзалар һәм аларның якыннары өчен йөкләмәләр билгеләнә. Мәсәлән, кирпеч, известь җитештерүгә, хәрби хезмәт өчен җыемнар, артиллерия припаслары ташу өчен олаулар бирү. Җан башыннан түләнә торган салым күләме дә тәгаенләнә. Хәзер татарлар, руслар кебек үк, рекрут бирергә һәм кунарга кертү йөкләмәләрен үтәргә тиеш булалар. Сөрү җирләренә дә салым куела.

Бабаларыбызга Адмиралтейство өчен кораблар ясарга яраклы агач материалларын әзерләү иң авыр йөкләмә булып саналган. Канун буенча теркәлгән һәр тугыз татарның икесе, чиратлашып, ярты елга урман кисәргә җибәрелгән, 25 кешедән өч атлы бер елга китәргә мәҗбүр ителгән. 1704-1724 елларда йомышлы татарларны Петербург төзелешенә дә алганнар.

Петр I үлгәннән соң да йомышлы татарлар һәм морзаларның өстенлекләрен чикләү дәвам итә. XVIII гасырның икенче яртысыннан аларның хәле дәүләт крестьяннарыныкыннан аерылмый башлый. Морзаларның нибары бер өлеше генә, христиан динен кабул итеп, урыс фамилиясен алганнары гына бөлгенлектән котылып кала. Чукынган морзалар рус дворяннары сафын тулыландыра. Бу хөкүмәткә уңай була, чөнки рус булмаган милләтнең өстен, зыялы катлавын идеологик яктан буйсындыру крепостной системаны ныгыта. Шулай итеп, безнең якларда яңа, татар фамилияле, чукынган җирбиләүчеләр барлыкка килә. Алар – Давыдов, Богданов, Богдалов, Кутузов, Карамзиннар... ■

Фотолар search.tatar73.ru сайтыннан алынды

Сабантуй

Без сугышта юлбарыстай көчлебез,
Без тынычта аттан артык эшлибез.
Г.Тукай

Бар дөньяга
сибелгәнсең
бүген халкым.
Сабантуйлар
берләштерә
сине тагын!
Күпер салып
араларга,
чаба алга
тулпар атың –
Бөтендөнья
конгресс – атың!

Җир белән күк
якынлашкан
кара-каршы,
татар моңы –
арадашчы!
Монда бүген –
Кулаткыда
Бөтенрәсәй
Сабан туе!
Хезмәт туе!
Кунаклары
мәйдан тулы!

Яңа дуслар
танышалар,
танышлары,
кочаклашып,
аркалардан
кагышалар.
Ярышларга,
уеннарга
чират тора.
Монда һич тә
тәнәфес юк
җырга-моңга.

Без сугышта
юлбарыстай
көчлебез дә,
без тынычта
аттан артык
эшлибез дә.
Ял иткәндә
бар дөньяны
искитәреп,
шау-гөрләтеп
бәйрәм белән
бизибез дә!

Әй милләтем!
Киләчәккә
барыр өчен
җитә синең
бетмәс көчең!
Егәрлегең
кимемәсен,
ташып торсын!
Җитәкләсен
алга гына,
җиңүләргә
таба гына!
Җиңүләргә
таба гына!

Кадыйр Әхмәров,
Иске Кулаткы.

Милләтебезнең төп сыйфаты нидән гыйбарәт икән? Кайсы төшенчәне асыл билгебез итеп күрсәтергә мөмкин?
Беркатлы фикерләвемнән кыенсынып, урынлы-урынсыз уйларымны кул изәп куам да... яңадан әйләнеп кайтам: ә шулай да, кайсы соң? Һәм сорауга сорау белән белән җавап биреп карыйм: фидакярлек түгелме?..

Нәсүр Юрушбаев: «Тарих «әгәр дә» дип сөйләүне өнәми...»

Рүзәл Мөхәммәтша

Журналист, милләтпәрвәр, халкыбызның дөньяга сибелгән хәзинәләрен барлаучы Нәсүр Юрушбаев, үзе әйтмешли, Габдулла Тукайның якташы – Пермь төбәгенең Барда районы егете (Мәмдүдә абыстайның әтисе Зиннәтулла хәзрәт шул туфрактан). Туксанынчы еллар башында мөһаҗирлеккә тарып, бүгенге көндә Алманиянең Лейпциг шәһәрендә гомер кичерә. Хәер, соңгы җөмләм хакыйкатькә хилафлык китерер, мөгаен. Чөнки аны тәгаен бер административ берәмлеккә генә «теркәп кую» – һич ярарлык эш түгел: Нәсүр абый һәрвакыт сәфәрдә, юлда, эзләнүдә һәм, тырышлыгының күркәм нәтиҗәсе буларак, табуда да.

«Безнең мирас» журналханәсе бусагасы аша җәт-җәт атлап кергәндә Чиләбе җиле аның иңбашыннан бармак очларын ычкындырып өлгермәгән иде әле...

АУРУПАДА ТАТАР ЭНҖЕЛӘРЕ

– Беләсездер, Наполеонга каршы иң зур сугыш 1813 елның 16-19 октябрьләрендә, Алманиянең Лейпциг шәһәре тирәсендә була, – дип башлады ул сүзен кирә-керешкә. – Яуда алманнар, французлар, шведлар белән бергә Россиянең урыс, татар, чуаш, якут, башкорт гаскәриләреннән торган регуляр һәм иррегуляр (казаклар) армияләре дә катнаша. Чиләбе өлкәсендә шундый ук исемле станица барлыгын белгәч соң дәрәҗәдә гаҗәпләндем. Алай-болай бу авыл кешеләре арасында «Халыклар бәрелеше»ндә катнашучылар булмадымы икән, дип эзләнә башладым, шунда бардым, сораштым. Таптым бит! Бар булып чыкты андыйлар. Нәтиҗәдә, күңелемдә бер уй төенләнде: нигә Алмания Лейпцигында «Халыклар бәрелеше»нә куелган һәйкәлнең кечерәк күчермәсен Россиядәге Лейпцигта да торгызмаска әле? Аурупага кайтып шул хакта чаң суктым. Хуплаучылар табылды. Был тыр, беркадәр акча җыйгач, алман дусларымны ияртеп яңадан Чиләбе өлкәсенә юл тоттым. Көрәкләр таратып: «Казыгыз, – дидем. – Безнең ата-бабалар сезнең шәһәрне французлардан коткарган, хәзер инде сез аларга гамәл аша рәхмәтегезне белдерегез». Җәйдә үк нигезен эшләдек. Бүгенге көндә эскизлар да әзер диярлек.

Төп максатым колачлырак, билгеле: «Лейпциглар», халыклар, цивилизацияләр, кыйтгалар (Аурупа һәм Азия) арасында «дуслык күпере» урнаштыру. Тормыш девизым да шундый: тынычлык китмәсен, калганы булыр, калганына ирешелер!

– Һәйкәл Алманиядәге сыңарын ташка-таш кабатлаячакмы?

– Юк. Беренчедән, «Халыклар бәрелеше» урынына мин «Халыклар дуслыгы» атамасын якынрак күрәм. Икенчедән, алманнарда унике апостол сурәтләнгән. Халыкның хәрби куәтен символлаштырып, кылыч тотып тора алар. Безнекендә башка сыннар куелачак. Тәгаен нәрсә куелуын уйлап бетермәдек әле. Өченчедән, Алманиядәге һәйкәлдә «Илаһ – безнең белән!» дип чокылган. Бу сүзләр соңрак нацист сугышчыларының каешына да «күчкән». Шунлыктан, билгеле, мин моны да «Тынычлык – безнең белән!» вариантына үзгәртү яклы. Уйлыйбыз әле. Анык ки, бу һәйкәлдә «алман рухы»ның эзе дә булмаячак.

– Сез Аурупа архивларында табып, Татарстан архивына тапшырган литографияләр дә XIX гасырга карый сыман.

– Әйе, нәкъ шулай. Наполеон

«Әтиемнең тавышы» фильмының тышлыгы

армиясенә каршы көрәшкән татар-башкорт кавалеристлары сурәтләнгән утыз сигез литография турында әйтәсез. Бүгенге фотография кебек алар – үзләре төсле, гаскәриләрнең киемнәре, кораллары һәр детальгә кадәр төп-төгәл сурәтләнгән. Таң калмалы табыш.

Лейпциг янындагы сугышта бабаларым да катнашкан. Шуңа күрә әлеге тема күңелемә аеруча якын. Карагыз: татар-башкорт полклары ул чакта Парижга кадәр барып җиткән бит! Очынып китеп, бу хакта документаль тасма төшерергә уйладым. 2008 елда. Таныш-белешләр Башкортстанга барырга, андагы киностудия белән хезмәттәшлек итәргә киңәш бирде. Нәтиҗәдә фильм ут күршеләргә багышланды, «Сенада курай моңнары» дип атала. Шуның белән монда, Казан кинофестивалендә катнаштым. Бик яратып карадылар. Соңрак «Әтиемнең тавышы»н алып килгән идем. Анысы да җылы кабул ителде.

– Бу фильмны төшерүгә баш әйләндергеч вакыйгалар, шәхсән үзегез өчен дә, милләтебез өчен дә бәһасез хәзинәләр табылу сәбәпче булды дип беләм. Шул хакта искә төшереп үтмәссезме?

– Беренче Бөтендөнья сугышында катнашкан татар солдатларының тавышларын таптым бит – җәмгысе кырык өч пластинка (Эдисон цилиндры)! Алманнар әсирләрдән безнең җырларны, мәкальләрне, мәзәкләрне яздырып алган. Аннары Готтхольд Вайль исемле галим аларның барысын анализлаган, тәртипкә салган, китап итеп бастырган. Мин ул пластинкаларның да, халкыбызга нисбәтле башка материалларның да барлыгын белеп, һәммәсен чынлап торып махсус эзләдем. Бихисап байлыкка тап булдым. Шуларның берсе – «Татар язмалары» китабы.

Аурупа рәссамнары татар гаскәриләрен шулай күргән. XIX гасыр

Болай иде ул. Мавыга торгач, Грасси музее архивына (Лейпциг) кердем. Татарлар турында эзләгәч, иң беренче «т» хәрефенә башланган сүзләрне карыйсың, шулай бит? Берзаман 1931 елда нәшер ителгән «Tatarische Texte» дигән китап килеп чыкмасынмы! Карточканы сузып, миңа шуны табып бирегез әле, дидем. «Ярар, ике-өч көннән килегез», – диделәр.

Укый башлагач, бөтен гәүдәмә каз тәне чыкты! Шаккатмалы! Искитмәле! Күпмедер вакыттан соң айнып киттем: бәй, пластинкалар буенча эшләнгән китабы булгач, аның пластинкалары да булырга тиеш ләбаса. Берлинга юл тоттым. Өч ай эзләдем. Таптым барыбер. Бүгенге техник әсбаплар укырлык форматка күчереп, яздырып, монда алып кайттым. Мәдәният министрлыгында ай ярым вакыт дәвамында урысчага аудардым. Ләкин, ни гаҗәп, китап минем тәрҗемәче икәнлегемне искәртмичә генә дөнья күрде...

Соңрак, чыннан да, кино төшердем. Ибраһим Хәлимов исемле әсирнең хәзерге Питрәч районы Күн авылыннан булуы ачыклангач, шул тарафка хат салдым: фәлән-фәлән хәлләр, абзыйның исән туганнары юк микән? Җавап хәбәре мине, урынымнан кубып, шул мизгелдә үк Татарстанга очарлык итте: анда «Ибраһим Хәлимовның кызы Венера апа бүген дә исән-сау гомер кичерә» диелгән иде. Әүвәлге очрашуда аудиоязманы тыңлатмадым, йөрәге түзмәс, дип курыктым...

Дөресен әйтергә кирәк, Беренче Бөтендөнья сугышында әсир төшкән Россия мөселманнарының байтагы алманнарда яхшы яшәгән: кәрҗиннәр үргән, уенчыклар ясаган, хезмәт хакы алган, кайберләре алман кызлары белән гаилә дә корып җибәргән. Алмания җиңелгәч, әсирләр үз язмышына үзе хуҗа булып калган, теләгәннәре шунда төпләнгән, теләгәннәре Төркиягә, Франциягә, Америкага күчкән. Ибраһим Хәлимов исә, күпчелек сыман, өченче юлны сайлаган – туган иленә, туган йортына кайткан. Кесә тулы акча. Иңендә фото-

аппарат. Велосипед. Авылында яңадан укытучы булып эшли башлаган. Җылы бәдрәфле өр-яңа мәктәп салдырган. Һәм (соңрак ачыкланганча – үз башына) күргәннәре-белгәннәре белән бүлешкән: Алманиядә яхшы юллар, матур йортлар, бөтен җирдә тәртип, иплелек, гүзәллек... «Ялачы»ны 1937 елда кулга алып, 1938 елда Казанда атып үтергәннәр. Хәзер Венера апа да вафат инде. Әмма әтисенә багышланган тасмада ул мәңге исән калды.

ЯХШЫЛЫК КЫЛ ДА СУГА САЛ...

– Беренче татар басма китабын табуыгыз турында да беләбез.

– Бусын эзләү коткысы Әбрар ага Кәримуллинның язмалары аша Казан университетында (әңгәмәдәшем биредә журналистика факультетын тәмамлый – *Р.М.*) укыган чакта ук салынды: кайдадыр Аурупада, Алманиядә, шундый-шундый китап булырга тиеш, дип язган иде ул. Шактый гомер узгач юлыктым мин аңа.

Беренче басма татар китабы дип саналса да, Австрия галиме Иероним Мегизер тарафыннан алман телендә язылган һәм татар-төрки теле грамматикасын, фонетикасын өйрәнгән, мәкаль-әйтемнәрен, дога тәрҗемәләрен туплаган саллы җыентык ул. «Institutiones linguae Turcicae» – «Төрки тел нигезе» дип атала. Мин аны Лейпциг шәһәренең университет китапханәсендә таптым. Ул Бөек Рим империясенең заказы буенча язылган булырга тиеш. Хәрби сер дәрәҗәсендәге басма. Алар, аурупалылар, монда килеп җитәселәрен әллә кайчан уйлап, ниятләп, шуңа әзерләнеп торганнар. Үзегез уйлап карагыз – без 1612 елда чыккан китап турында сөйләшәбез!

– Татарлар – язмыш тарафыннан мөһаҗирлеккә дучар ителгән халык. Аның материаллары, документлары бөтен дөнья буйлап сибелгән, әллә нинди архивларда әллә нинди энҗеләребез ятадыр әле...

– Әлбәттә, шулай: Гыйракта, Кытайда, Төркиядә... Үзегез әйтмешли, җиһан тулы. Һәм аларны, һичшиксез, кайтарырга тырышырга кирәк. Ләкин кайвакыт аяк астында яткан мирасны да күтәреп ала алмыйбыз бит. Ерактагыны күрәбез, ә борын төбендәгене – юк. Милләтебезнең нигезе – авылда, дибез. Бу да хак. Әмма салаларыбыз бушый, кешеләре кайсы кая тарала: читтән бәхет эзлибез, башка илләргә, җирләргә күчәбез, башка кавемнәргә кушылып сыекланабыз... Нигә моны искә төшерәмме? «Россиянең ачык капкалары» дип аталган яңа проектым шул борчуларга җавап рәвешендә уйлап табылды. Элек авылга кергәндә капка торган. Хәзер ул юк. Капкасы булмаганда авылның, бәлки, иминлеге, тынычлыгы, бәхете дә була алмыйдыр? Бәлки, борынгы традицияне яңартырга вакыт җиткәндер?

Пермь краеның кендек каным тамган Бакчавылында гомер кичергән яшь гаилә (кардәш-тумачаларым) көннәрдән беркөнне әти-әниләреннән калган агач капканы йолкып ташларга, аның урынына тимердән һәм пластмассадан эшләнгән яңаны корырга ният итте. Мин шунда идем, карышып карадым. Алай да үз фикеремә күндерә алмагач: «Әйдәгез, сатып алыйм», – дидем. Исләре китте: «Нәрсәгә инде ул сиңа?» «Иртәгә күрерсез», – дип җавапладым. Сатмыйча, болай бирделәр.

Мәчеткә барып ниятемне Нәзир хәзрәт Кучуковка җиткердем. Ул берсүзсез хуплады. Бер көн эчендә аның аша иганәчеләр, цемент, тимер торбалар (агач баганаларны нygy-

Жиңү көне. Татар диаспорасы вәкилләре. Россиянең Лейпцигтагы консуллыгы. 9 май, 2014 ел

тыр өчен) табылды, Каенавылдагы Мәсгут Имашев исемендәге мәктәп кадәр мәктәп укучыларын ярдәмгә җибәрде, трактор бирде. Укытучылар, директор үзе килде! Без, туган җирне җан кыйммәте күргән авылдашлар, иске капканы сүтеп алдык, өч көндә авыл башына күчереп, яңадан җыеп та куйдык!

Бу гамәлемнән дә, үземнән дә сәерсенүчеләр булды, әлбәттә, аның каруы, идея һаман яши, һаман үсә, чикләре һаман киңәя бара! Ничә авылның шундый ук эш башкару теләге белән янып йөргәнен беләм. Исеме дә исеме: «Бәхет капкасы» бит! Өйләнешкән парлар элек Ленин һәйкәле янына басып фотосурәткә төшсә, хәзер монда килеп рәсем алдырачак.

Капка – такталар җыелмасы гына түгел, ул – символ, ачкыч. Мәхәббәткә, куанычка, өметкә һәм... ышанычка да. Димәк, дошман эчкә үтеп керә алмаячак! Ә кунаклар өчен ишек мәңге ябылмас. Шуңа күрә үз капкаларымны ачык калдырдым мин...

– Ихтимал, сез һаман эзләнүдәдер. Тагын яңа ачышлар көтелмиме соң?

– Беләсезме, алманнар Беренче Бөтендөнья сугышында әсир эләккән татар гаскәриләренең тавышын (мәкальләр әйтүен, хикәятләр сөйләвен, җырлар җырлавын) гына алдырып калмыйча, аларның төрле-төрле уен кораллярында уйнавын да яздырган. Шуларны да таптым әле мин Берлинда.

– Ул Татарстанга кайттымы?

– Юк. Моңа шәхси үпкәм дә комачау итте кебек. Берсендә Казанга кайтып җанымны бушаттым: «Күпме йөрдем, күпме рухи һәм матди байлыклар таптым, бер тапкыр булса да самолет билеты хакын түләгез әле? Һичьюгы, ике көнгә кунакханәдә бүлмә бирегез?» Финанс мөмкинлекләрем чиксез түгел бит. Бүгенге көнгә кадәр һәрбарчасын үз хисабыма эшли килдем.

– Коры энтузиазм белән әллә ни еракка китеп булмый лабаса...


Personalkarte I: Personelle Angaben

Kriegsgefangenen-Stammlager:

Beschriftung der Erkennungsmarke Nr. 120453 Lager: XI B

Des Kriegsgefangenen

Name: ДАВЛЕТШИН DAWLESCHIN

Vorname: ТАМУРБЕК TAMURBEK

Geburtstag und -ort: 26.7.1904 UFA Уфа

Religion: MUSL.

Vorname des Vaters: MUXAMET Мухамет

Familienname der Mutter: BULATOWA

Staatsangehörigkeit: RUS (TATAR) Татарин

Dienstgrad: INTENDANT интендант

Truppenteil: I.R. Komp. usw.:

Zivilberuf: PROFESSOR профессор Berufs-Gr.:

Matrikel Nr. (Stammrolle des Heimatstaates):

Gefangennahme (Ort und Datum): 13.VIII.41 NOVGOROD Новгород

Ob gesund, krank, verwundet eingeliefert: GESUND здоров

Nähere Personalbeschreibung

Größe: 169 Haarfarbe: SCHWARZ Besondere Kennzeichen:

Fingerabdruck des rechten! Zeigefingers

Name und Anschrift der zu benachrichtigenden Person in der Heimat des Kriegsgefangenen

Татарская АССР

Wenden!

«Нәсүр Юрушбаев Икенче Бөтендөнья сугышында һәм әсирлектә һәлак булган байтак татар сугышчыларының исемнәрен (кайберәүләренең – хәтта карточкасын да) таба, алар турындагы мәгълүматларны Казанга, Уфага юллый, ләкин аңа һичкайдан һичнинди җавап кайтармыйлар...»

– Нишлим соң? Ярдәм итәргә атлыгып тормыйлар. Булыр, булыр, бу эшләр программага кертелде, диләр дә... вәссәлам. Гаҗәп нәрсәләр бар инде. Ләкин зарланып әйтүем түгел. Факт буларак искәртәм генә. Мин үз эшемне беләм. Кулдан килгәнчә эшлим. Монда сүз шул, һичьюгы, юл чыгымнарын өлешчә каплау турында бара ала. «Архив таптым, акча бирегез!» – дип әйтергә... Аллам сакласын! Кабахәтлек, түбәнлек булыр иде бу.

Берәр кайчан мин аларның барысын да илгә кайтарырмын, билгеле. Ләкин бүген түгел. Бәлки, иртәгәдер? Хәзер Чернобыль турында документаль фильм төшерү белән мәшгульмен.

МОҢ

– Алманнарга килгәндә, дикъкатькә лаек: алар Беренче Бөтендөнья сугышында да татарлар белән кызыксынган, Икенчесендә дә... Мөнәсәбәтләре безгә карата җылырак булган, димме соң. Уңайрак, димме?..

– Алар тарихыбызны белә бит. Һәм гомер-гомергә белгән. Прагматикларча бик гади уйлаганнар: урыска каршы яу чапсак, татарлар безнең якка авышырга тиеш. Наполеон да шул фикерне алга сөргән. Сугыш башлаганчы монда үз кешеләрен җибәргән ул. Вазгыятьне өйрәнергә, тикшерергә. Уралга кадәр килгәннәр. «Урысларның аркасына пычак кадагыз!» – дип котырту өчен. Ләкин безнең халык аңа бармаган.

– Бу нилектән, сезнеңчә?

– Менталитет. Намус кушмый. Хәтәр-хәвеф килсә, барыбер үзебезнең ватанны (хакиме кем генә, нинди генә милләттән, диннән булса да!) саклаганбыз.

– Россиядә хәзер Бөек Ватан сугышы турында бик бәхәсле фикерләр яши. Ревизия ясау очраклары бихисап. Хәтта илкүләм мәгълүм затлар арасында да: «Гитлер өлгерлек күрсәтеп СССРга басып кермәсә, бераздан Сталин үзе Алманиягә басып керер иде» сыман инанулар да яшәми түгел. Милләтебез эченнән дә андый фаразлар ишетелгәли. Алманиядә коткаручы күреп, Шәфи Алмасларны каһарман югарылыгына күтәреп, Муса Җәлилләрне, киресенчә, империя әнчекләре түбәнлегенә төшереп, каралтып күрсәтергә тырышучылар очраштыргалый. Бу хакта сез, яңа

Алманиядә гомер кичерүче татар кешесе, ни уйлыйсыз?

– Узган елгы Казан кинофестивалендә мин «Җәвит һәм Вальтер» фильмы белән катнаштым. Ике әсир турында ул. Ике гомер. Ике язмыш. Берсе – Кызыл Армия солдаты, татар егете, Уфадан. Сугышны постта каршылый. Өч көн оборона тоталар. Аннары, камалышта калып, өч ел таш капчыкта ята. Шунда, Җәлилебез кебек, яшерен оешма эшчәнлегендә катнаша. Ничә тапкыр асарга, ничә тапкыр атарга хөкем ителә – ләкин, үлемгә үч итеп, барыбер исән кала. Биш мәртәбә кача. Икенчесе – вермахт солдаты, алман. Анысы монда, Магнитогорскида утыра. «Гомеремнең иң матур, рәхәт мизгелләре совет әсирлегендә узды», – дип бәян кылды. «Ничек алай?» – дип сорадым. «Әфисәрләр кыйнамады, кешечә мөнәсәбәт, шимбә саен мунча, чиста кием, якшәмбе – ял», – дип тезеп китте. Шулай яшәгәннәр. Кинода чиратлашып әсирлекләре турында сөйләде алар.

Менә шуны төшергәндә мин Икенче Бөтендөнья сугышына, анда кан койган гаскәриләргә, әсирләр газап чиккән лагерьларга бәйле бик күп документаль фактлар белән таныштым. Берлин янында урнашкан Заксенхаузен концлагерен күрдем. Бу гади лагерь гына булмаган, анда кешеләрне ничек үтерергә кирәклеген өйрәткәннәр, ягъни, тәҗрибә уртаклашканнар. Алманнарның ничә концлагерь оештыруын беләсезме?

– Белмим.

– Якынча?

– Якынча да белмим.

– Рәсми булмаган мәгълүматлар буенча – җитмеш мең. Ә болай, ким дигәндә, ун мең. Аларның һәрберсендә меңләгән-меңләгән кешенең җанын кыйганнар! Шундый вәхшилекләр кылган халыктан рәхим-шәфкать көтәргә ярыймы соң?

Гомумән, тарих «әгәр дә» дип сөйләүне өнәми. Ничек булган – шулай булган. Илаһ тарафыннан шулай дөрес, шулай тиеш табылган, димәк.

– Ә Аурупада, тәгаен Алманиядә, бу сугыш турында үзгә фикерләр борын төртмиме? Без хаклы булганбыз, димиләрме?

– Юк. Анда мәктәптән башлап университетка кадәр үз хаталарын таныйлар, Гитлерның кеше кыяфәтле иблис булуын аңлаталар, рейх хакимиятен гаять ялгышкан дип исәплиләр һәм әлегәчә үкенү кичерәләр. Аларда Сигезенче май – азат ителү көне. Капитуляция көне түгел.

Алманнар – гаҗәпләнерлек халык. Аларны кемнәр генә тукмамады – Наполеон, «Антанта», совет гаскәрләре, союздашлар... Һәммәсе ничә килеп ничә тапкыр Алманиянең сыйрагын сындырып китмәде. Барыбер күз алдында аякка басалар! Рухлары сау чөнки. Рухлары нык. Халыкның рухы, моңы булырга тиеш. Татарның да моңы бар, шуңа күрә аны күпме изсәләр дә, кыйнасалар да, ул изелми, юкка чыкмый. Милләтебезнең барлык кыйтгаларга сибелгән уллары, кызлары да шушы моңнан мәхрүм түгел – ул кайда да безнең белән йөри. Моңы булган халык беркайчан да үлмәячәк.

Нәсүр абый Юрушбаев белән әңгәмәбез бу урында өзелмәде әле. Озак сөйләштек без. Кирәген дә, бәлки, кирәкмәгәнен дә... Ләкин хәзер, әллә кайчангы очрашу вакыйгасын хәтердән барлап утырганда, шушы урында нокта куясы килеп китте: «Моңы булган халык беркайчан да үлмәячәк!»

Готтхольд Вайль
туплаган татар текстлары

(Өзекләр)

Шәрык белгече Готтхольд Вайль 1883 елның 13 маенда Берлинда дөньяга килә. Алман башкаласындагы Ирекле университетны тәмамлап, 1914 елдан шунда тюркология буенча семинарлар алып бара башлый. 1918 елда Пруссия Милли китапханәсенең Шәрык бүлеген җитәкли. Соңрак, 1931-1934 елларда, Франфуркт-Майн шәһәрендәге Гёте университетында шәрык фәннәре профессоры була, Берлиндагы Яһүди институтында укыта.

Хакимият национал-социалистлар кулына күчкәч, Готтхольд Вайльне, яһүд доценты дип, мәҗбүриләп, эшеннән азат итәләр. Шуннан соң ул Фәләстыйнга күчә һәм 1948 елга кадәр Иерусәлим шәһәрендәге Яһүди университетында Милли китапханәнең җитәкчесе булып тора. 1960 елның 25 апрелендә Иерусәлимдә бакыйлыкка күчә.

Готтхольд Вайль «Татар язмалары» җыентыгын бик озаклап, җентекләп, берничә этапка бүлеп эшли. Иң әүвәл Вюнсдорф лагеренда тотылган татар әсирләре арасында сораштыру үткәрә, аннары, «чимал»ның өйрәнелергә, тикшерелергә лаек булуына инангач, җиң сызганып, материал туплый башлый. Аның турыдан-туры катнашында күп кенә татар җырлары, мәкальләре, табышмаклары, әкиятләре һәм башка шундый җәүһәрләр пластинкага яздырылып, Пруссия Милли китапханәсе фондларына тапшырыла, алай гына да түгел, җентекләп анализлана һәм 1930 елда ук мөстәкыйль китап итеп бастырыла.

Җыентык өч бүлектән тора: җырлар, чәчмә язмалар һәм грамматик язмалар. Автор татар текстларын тулысынча транскрипцияли, аларны оригинал телнең аваз үзенчәлекләрен мөмкин кадәр якын чагылдырырлык итеп латин имласында, татарча (гарәп имласында) һәм, ниһаять, алманчага тәрҗемәдә урнаштыра. (Без исә латин шрифтында язылган өлешне генә, мөмкин кадәр бозмаска, чыганактагыча калдырырга тырышып, кирилл хәрефләрендә бирәбез, шунлыктан кайбер сүзләр бүгенге татар теле орфографиясе кагыйдәләренә туры килмәскә мөмкин. – *Р.М.*). Галим һәр текстны тәфсилле искәрмәләр белән ныгыта, алман колагы өчен ятышсыз, катлаулы фонетик әйләнмәләргә, географик атамаларга, этнографик күренешләргә аңлатма бирә.

Автор сөйләүчеләрнең (башкаручыларның) туган урынын, яшен, һөнәрен сорап китапта күрсәткән, ләкин, кызганыч ки, исемнәрен үк язып алмаган (әсирләргә лагерьда номер гына бирелгән). Аның каруы, әти-әниләре турындагы мәгълүматны теркәргә кирәксенгән. Димәк ки, теләгән кеше, архивларны өйрәнеп, әсирләрнең шәхесен дә билгели ала.

Хөрмәтле укучыларыбыз!

Беренче Бөтендөнья сугышында әсир төшкән кайбер татар сугышчыларының тавышларын «Безнең мирас» сайтына кереп (http://beznenmiras.ru/tatar-esirlerenen-tavyshlary/) тыңлый аласыз.

Von der Feier des Beiramfestes im mohammedanischen Gefangenenlager in Wünsdorf bei Zossen: Die gefangenen Russen mohammedanischen Glaubens während des Gebets.
Zensur genehmigt 144
Aus der Leipziger „Illustrirten Zeitung".

Гает уңаеннан әрвахларга дога кылу. 1914-1918 еллар

Пластинка РК 627

«ТАТАРЛАРНЫ ҮЗГӘРЕШКӘ ЧАКЫРУ»
«Икенче садә»гә ияреп (1)

1. ғафил улған татарларны
ник уйғатмыйсың зәман
аһ син зәман зәман зәман
ник уйғатмыйсың һәман

2. йуқ алардай алға бару
йалқау йаталар һәман
аһ син зәман зәман зәман
ник аңлатмыйсың (2) һәман

3. аңлат ғилем кирәклеген
тормасын алар надан
аһ син зәман зәман зәман
ник аңлатмыйсың һәман (3)

4. күфрү золым мәйдан алып
хақиқәт артта қалан (4)
аһ син зәман зәман зәман
ник өскәлмыйсың һәман

5. болыт китте кәрwан күчте
татарлар йоқлап қалан (5)
аһ син зәман зәман зәман
ник уйғатмыйсың һәман

Искәрмәләр
1) 1905 елгы инкыйлабтан соң Россиядә татарлар күтәрелә башлый: мәдрәсә шәкертләре фетнә кубаралар, дөньяви фәннәр өйрәтүне, православиегә каршы фәнни методлар куллануны таләп итәләр, бу күтәренкелектә сугышчан, дәртле җырлар туа. Шулар арсында Беренче садә һәм Икенче садә дә бар. Әлеге җырны әсирләр хәтердән башкардылар, әмма ул ни текст, ни көй ягыннан Икенче садәгә туры килми.
2) Бу юлны кабатлаганда ул уйгатмыйсың, дип җырлый.
3) Өченче һәм дүртенче строфа арасында әсирләр тагын бер строфа башкара иде:
йоқлый йоқлый булды инде
анларның хәле йаман

аһ син заман заман заман
ник уйғатмыйсың һаман
4) Монда һәм алдагы строфада кулланылган калан сүзе госманлы-төрки теле йогынтысында үзгәреш кичергән калган сүзе булырга тиеш.
5) Табигать һәм кешеләр алга бара, татарлар гына алай түгел мәгънәсендә.

РК 627 пластинкасын башкаручының биографиясеннән:

Тубылда туган. Әти-әнисе дә шул төбәктән. Кызылбайдагы татар урта мәктәбен тәмамлаган. Гомерен, нигездә, Тубылда уздырган.

Һөнәре: укытучы һәм мәзин.

Яше: 31.

Белгән телләре: татарча, урысча.

Яздыру вакыты: 30. XII. 1916

Пластинка РК 629

УНБЕР МӘКАЛЬ

Өч кеше тарафыннан башкарылды.

1) Керәреңдән элек чығарыңны уйла
2) Иртәге өчен ишәктә қайғырған
3) Күп күргән күп белгән
4) Ашыққан җитми быйорған җитә
5) Кәғәсе қыйбат түгел мәзәге қыйбат
6) Үрдәк бирсәң қаз алырсың
7) Ашыққан ашқа батқан әкреннәгән морадына җиткән
8) Ни чәчсәң шуны урырсың
9) Алты йәшәр йулдан қайтса
алтмыш йәшәр күрешә килсен
10) Аwызың пешсә өреп қабарсың
11) Аз ашасаң күп ашарсың

Искәрмәләр

1) Мәгънәсе: нindидер эшкә керешкәнче аны ничек тәмамлаячагыңны уйла. – Беренче сөйләүче чыгарынга сүзен әйтеп баш селкеде.
2) Мәгънәсе: киләчәгең турында уйла. – Икенче сөйләүче ишәк, дип кисәкчәсез генә әйтте.
3) Икенче сөйләүче күп сүзен беркадәр ясалма кыланыш белән әйтте.
4) Мәгънәсе: ашыгу осталыкка җитми. – Өченче сөйләүче бойорган, диде.
5) Мәгънәсе: башка берәүнең кайгысына куану, берәр нәрсәңне җуюдан да начаррак. – Кыйбат гарәпләрнең кыйммәт сүзеннән килеп чыккан.
6) Мәгънәсе: син эшләгән кечкенә яхшылык та берзаман зур яхшылык булып үзеңә кайтыр.
7) Монда баткан урынына пешкән сүзен кулланырга кирәк. Икенче сөйләүче бу урында яңадан 4 нче мәкальне кабатлады. Өченче сөйләүче әкренләгән диде.
9) Мәгънәсе: өлкәнәюгә караганда сәяхәт кылу зуррак тәҗрибә бирә (3 нче мәкаль белән чагыштырып кара). Күрешә килмәк – кочаклашу, исәнләшү. Беренче сөйләүче, ялгышып, күрсинә, диде.
11) Мәкальне берничә төрле шәрехләргә мөмкин. 1. Аз ашасаң сәламәт булырсың. 2. Кунакта күп ашасаң, икенче килгәндә ашарыңа берни дә бирмәсләр һәм, киресенчә, тыйнак булсаң, икенче юлы күбрәккә ирешерсең. – Икенче сөйләүче яңадан күп сүзен сәер әйтте.

РК 629 пластинкасын башкаручыларның биографиясеннән:

1) Бөгелмә (Самара) тирәсендәге Колшәрифтә туган. Әти-әнисе шул ук төбәктән. Әлмәттәге татар башлангыч мәктәбен тәмамлаган. Егерме яшьтән – Никольск-Уссурийскида.

Яше: 27.

Һөнәре: крәстиян.

Белгән телләре: татарча, урысча.

2) Курмыш (Сембер) янындагы Чүмбәлидә туган. Әтисе Чүмбәлидән, әнисе Нижгардан. Алты яшькә кадәр Чүмбәлидә яшәгән, аннары Казанда урта мәктәп тәмамлаган. Егерме яшьтән Мокшанда (Пенза) гомер кичерә.

Яше: 24.

Һөнәре: игенче.

Белгән телләре: татарча, урысча.

3) РК 627 пластинкасын башкаручыны карагыз.

Яздыру вакыты: 31. XII. 1916



Вюнсдорф лагере мәчете (Алманиядәге беренче мәчет) сурәтләнгән открытка. XX гасыр башы

Пластинка PK 1249

ТЕЛ БЕЛМӘҮ (1)

Старыста (2) старшина (3) урысча брәргенә сүз белгәнләр берсе: «зачим пришул субака (4)» дигән сүзне, икенчесе: «пушчити (5)» дигән сүзне белгән. Боларның аwлына земский начал’ник (6) килгән. Староста қаршы алған wақытында земскийға йахшы сүз әйтәм дийеп: «зачим пришул субака» дигән. Земский ачуланып старостаға ун биш рузга (7) дигән. Суғып торғанда старшина килеп миндә русча беләм дийеп «пушчити» дигән. Земский икенче аwылға китмәк булған русча «дайте меня патвуда (8)» дигән. Болар русча белмәү сәбәбле нишләргә дип торғанда бер салдат килгән. Бу русча блә дигәнләр. Земский солдатқа: «дайте меня патвуда» дигән. Салдат «такточна (9)» дигән. «Ат буғы китерегез» дигән (10). Ат буғы (11) китергәнләр. Земский буқны күреп бик қаты «патвуда патвуда» дигән. Салдат: «ә белдем белдем ағамның путвалында (12) бер батман (13) балы бар шуны сорый» дигән. Хәзер балны китергәнләр. Земский балны көлә көлә алып арбаға қуйған, үзе арбаға ат булып җигелеп күрсәткән. Салдат: «ә белдем ат кирәк икән» дигән. Земский әйткән: «визите меня деревня Шумуртувай (14). Салдат: «ә белдем» дийеп «бу шомырт җыйарға бара» дигән. Салдат кучер булып киткән. Салдат атларын бар көченә қуа икән. Земский: «тихон’ка (15) салдат» дигән сүзгә «синең тихон’ка дип әйтүеңә атларны үтеримме» дигән, исчу (16) қуа икән. Барып йиткәнләр шомырт урманына. Салдат атларын туқтатып (17) «менә шул шомырт урманы» дигән. Земский әйткән: «йа пайду гул’ат’ меня не оставл’айте (18)». Салдат «тактучна» дигән дә атларын бурлуп қуа биргән. Земский күреп «пастуйте (19)» дип

Мулла әсирләр тәгаменнән авыз итә. 1914-1918 еллар

кычкыра икән. Салдат ишетеп пастуйы пустау (20) тун бирә дийеп кычкыра икән дийеп «нигә синең миңа пустау туның» дийеп атларын куа биргән һәм земский тел белмәү сәбәбле утыз чакрым җәйәү кайткан.

Искәрмәләр

1) Татар крәстияннәре – урысча, урыс түрәләре – татарча сөйләшә белмәгәнгә күрә, еш кына аңлаешсызлыклар килеп туган.
2) = урысча: староста.
3) = урысча: старшина.
4) = урысча: зачем пришел, собака.
5) = урысча: пустите.
6) = урысча: земский начальник.
7) = урысча: розга.
8) = урысча: дайте мне подвода.
9) = урысча: так точно.
10) Монда сөйләүче буталды; пластинкада текст бу рәвешле яздырылган: ат бугы китергән дип китерегез, дигән.
11) Урыс телендәге подвода сүзе татарча падвуда дип әйтелә, солдатлар сөйләшкәндә ул еш кына яңгырашы буенча охшаш ат бугы кәлимәсенә әверелә.
12) Шул ук гыйбарә подвалда (в подвале) сүзе белән буталган.
13) Батман – төрки һәм фарсы кабиләләрендә авырлык үлчәме, ул төрле җирдә төрле үлчәү берәмлегенә тигез булган.
14) = урысча: везите меня в Шумуртувай. Шумуртувай җирлегенең шомырт сүзенә охшаш булуыннан.
15) = урысча: тихонько. Мәгънәсен аңламаган солдат аны тиз, җәтрәк, дип уйлый.
16) = урысча: еще.
17) Сөйләүче бу урында туктатып сүзе урынына башканы әйтте.
18) = урысча: я пойду гулять, меня не оставляйте.
19) = урысча постойте сүзе татарча постау (юка эскәтер) сүзе белән буталган.
20) = урысча: не уезжай без меня! Солдат, аңламыйча, түрәнең монда каласы килә, дип уйлый.

Пластинка РК 1250

А
ТАПКЫР МӘЗӘК (1)

Бер карчыкның һөтенә һыскан төшкән (2). Һөте бик жалка (3) булгас (4) муллаға алып килгән. «Мулда (5) балакайым һөтем бик куйы ине (6),

һөтемә бер дәлил тапмассыңмы» дийеп муллаға үтенгән. Мулла «аббирһе қитабты (7)» дигән. Аббиргәннәр қитабны. Қарчыққәйткән «һин (8) бик йахшы тыңнап тор бән хәдис уқыйым» дигән. Мулда уқый. «Харчық (9) йахшы тыңла, әлһөткә мәлһөткә (10) һысқан төшсә ипрагин типрәндәп (11) алып килеп сықса һиткә (12) әл-мәкрүһын мәкрүһ булсада сайдап (13) ичмәк йарыйдыр дигән. Қарсың «балам бик рәхмәт бик рәхмәт» дийеп йегерме тин тәнкә биреп қайтып киткән.

В
ГАДИ САННАР

Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез, туғыз, ун, унбер, унике, унөч, ундүрт, унбиш, уналты, унҗиде, унсигез, унтуғыз, йегерме, утыз, қырық, илле, алтмыш, җитмеш, сиксән, туқсан, йөз, мең.

Брәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү, алтау, җидәү, сигез, туғыз, унау, унбер, унике.

С
ТӨРЛЕ СҮЗЛӘР (14)

Йир, қойаш, ай, йолдыз, күк, болыт, йаңғыр, қар, боз күктән йаwа, су, боз, суық, җил, ут, томан, қызу, төн тарафы, қойаш чығышы, қыйбла тарафы, қойаш батышы, диңгез, инеш, күл, су буйы, айу, мәче, сыйыр, үгез, эт, кәҗә, қаз, дуңғыз, қара, күк, қара қуч (15), йәшел, қызыл, ақ, сары, йаз, җәй, көз, дүшәмбә, сишәмбә, чәршәмбә, пәнҗешәмбә, җомға, шәмбә, йәкшәмбе, қан, тән, баш, чәч, күз, борын, аwыз, тел, теш, ирен, қул, қолақ, йөз, қул, бләзек, борын, тырнақ, айақ тырнағы, йомырқа, аwыз, он, икмәк, сөт, май, сары, қуфийа (16), чәй, арақы, қош, дуңғыз, хатын, ир, ата, ана, уғыл, қыз, ағай-эне, тута, сеңел, бала.

Искәрмәләр

1) Карчыкның кызыклы сөйләм үзенчәлеге бар: ул ч урынына с куллана.
2) = татарча: тачкан төшкән.
3) = урысча: жалко.
4) = татарча: булгач.
5) = татарча: мулла.
6) = татарча: бик куе иде.
7) = татарча: алып бирче китапны. Китап сүзе монда Коръәнне түгел, ә дин хокукы буенча белешмәлекне белдерсә кирәк.
8) татарча: син.
9) = татарча: карчык.
10) Гарәпчәдән алынган әл артикле үзеннән соң килгән сүзне (мәлһүткә) ассызыклабрак җибәрер өчен генә кулланыла.
11) Сүзлектә табылмады, бәлки = татарча: пычргын тыпырланып?
12) = татарча: чыкса читкә.
13) = татарча: сайлап.
14) Әлеге сүз үрнәкләре РК 1245 пластинкасында да кабатланды. Әмма уку тәҗрибәсе зур булмаганлыктан, бу сөйләүче күп кенә сүзләрне бозып укыды. Шуңа күрә пластинкада яңгыраган вариантны диалекталь үзенчәлек дип түгел, ә хаталы уку дип кабул итәргә кирәк. Ике пластинканы чагыштырган кеше моңа бихисап мисаллар таба ала.
15) Кара кучкыл булырга тиеш.
16) Күфи булырга тиеш.

РК 1249, РК 1250 пластинкаларын башкаручының биографиясеннән:

Шадринскидан ерак түгел, Чиләбе янындагы Кунчак җирлегендә туган. Әти-әнисе шул ук төбәктән. Кунчакта халык мәктәбенә йөргән. Озак вакыт читкә чыкмыйча яшәгән.

Һөнәре: игенче.

Яше: 40.

Белгән телләре: татарча, башкортча, урысча.

Яздыру вакыты: 16. III. 1918

Рүзәл Мөхәммәтша әзерләде. ■

عائله درسلری

Гаилә дәресләре

Фәхрелбәнат Сөләймания

ГАИЛӘ, ӨЙЛӘНМӘК

Ата-ана, ир-хатын вә балаларның яки шул нәселдән булганнарның бөтенесенә гаилә диелер. Бөтен гаиләләрнең бер җиргә җыелуы һәйят иҗтимагыя инсанияне *(кешелек җәмгыятен)* вөҗүдкә *(барлыкка)* китерә. Гаиләләр никадәр бәхетле булса, алардан җыелган җәмәгатьләрнең бөтенесе дә шул дәрәҗәдә бәхетле була. Шуның өчен гаилә кадерен яхшы белмәк вә гаилә халкының һәрберсенең гүзәл тәрбия кылынуына күп тырышмак лязимдер.

Өйләнмәк – адәмнәрнең табигый мохтаҗ булган хәлләредер. Дөньядагы мәхлукларга күз салсак, бөтен мәхлукларның бер җефеткә мохтаҗ булганын күребез. Адәмнәр дә шулайдыр. Өйләнү булмаса, ни бу күренгән адәмнәр вә ни дә башка хайваннар булмас иде. Болай булгач, өйләнү Алла тарафыннан куелган бер табигый канун булып, безгә ияру лязим булган бер дини эштер.

Өйләнмәк – бер ир берлә бер хатынның һәрбер җәһәттән җыелуы димәктер. Ягъни ир берлә хатынның шәригать боерган рәвештә бер тән, бер җан кеби берләшеп торуларыдыр ки, боларның берсенә килгән кайгы вә мәшәкать икенчесен дә кайгыртыр.

Димәк ки, ир берлә хатын – берсенең рәфикъ хәяте *(тормыш иптәше)*, һәрвакыт бергә була торган юлдаш, вафалы *(бурычлы)* ярыдыр. Өйләнүдән максуд – балалар җитештермәк, Аллаһы Тәгалә каршында тәкъдир кылынган бер заман эчендә дөньяда нәсел калдырырга хезмәт итмәк, гаиләнең бәхетле булуына сәбәп булган нәрсәләрне тәмамламактыр. Өйләнү – берничә кичәлек кунак булу түгел, мәгыйшәт галәмендә юлдашлык вә һәрвакыт бергә тереклек итмәктер.

Бер ирнең дүрткә кадәр хатын алуына шәригать рөхсәт бирсә дә, боларның һәрберсен яхшы тәрбия кыла алмак, болар хакында һәрбер эштә тигезлек кылмак, тигез сөймәк вә тигез ашатмак, тигез киендермәк шарттыр ки, бу нигездә мөмкин түгелдер. Хатынсыз, ягъни буйдаклыкта тереклек кылучыларның һичбер вакытта бәхетле булганнары күренгәне юктыр. Никадәр дәүләтле вә ихтыяҗсыз булса да булсын, бер ир ничек тә тугры, гыйффәтле бер хатынга, бер хатын да шундый бер иргә мохтаҗдыр.

Ялгызлар, никадәр рәхәттә булсалар да, һаман үксезләрдер. Буйдакларның ялгызлыклары җәһәтеннән очраган бәлаләре, чиккән җәфалары чиксез. Ирсез бер хатын кулагәсез агачка охшый.

Бала таба торган хатыннарны

Аллаһы Тәгалә дә сөяр. Җимешле агач һәрбер җирдә кадерледер. Халыкның күплеге гаиләләрнең вә алардан җыелган һәйят иҗтимагыянең *(җәмгыятьнең)* куәтен арттырыр. Әмма балаларның яхшы тәрбияләренә тырышмак иң лязим булган шартлардандыр.

Ничек өйләнергә кирәк? Өйләнәчәк ир алачак кызны тәрбия кыла алырлык, кыз да барачак ирен бәхетле итә алырлык булмак шарттыр. Байлыгына кызыгып, кирәк яшь җәһәтеннән вә кирәк башка хәл җәһәтеннән муафыйк булмаганнар берлә өйләнмәк сәбәбеннән бик зур зарарлар туар. Туган балалар да зәгыйфь вә хәлсез булыр. Байлыгына кызыгып алтмыш яшендәге иргә егерме яшендәге кызны бирелсә, ул кыз бәхетле ителгән булмый. Ир берлә хатын бер-берсенең тиңе булырга тиештер. Ир кыздан бик күп булса ун яшь артык булырга тиеш. Юкса, ата кеби яшьле кешеләргә бармак, гаилә арасында көтелә торган сәгадәтне хасил итә алмас.

Бер кызны сарык саткан кеби сатмак яки мал алган кеби алмак – яхшы эш түгелдер. Өйләнүдән максуд булган сәгадәтләр ялгыз байлык берлә генә хасил булмый. Саулык, яхшы нәселдән булмак, күркәм холык, мәгърифәт – бу тугрыда иң беренче күзәтелә торган нәрсәләрдер. Гыйффәтле вә муафыйк *(тиң)* булган бер кызны фәкыйрь булса да алырга яраклы. Гаиләсен тәрбия кыла алырлык яхшы ир, ямьсез булса да, ирлеккә лаектыр.

Ханым-кызлар барасы ирләренең матурлыгына яки байлыгына алданмаска тиеш. Болар үтә торган нәрсәләрдер. Һәрнәрсәдән әүвәл аларның тәннәренең куәтлеген, намусларын, яхшы холыклы булганлыкларын тикшермәк лязимдер. Асылы-нәселе билгеле булмаган, начар холыклыларга абынмак дөрес түгелдер. Бу тугрыда бик яхшы тикшермәк файдалыдыр.

Кияү сайлауда эшче, язучы, түрә вә сатучыны талымламак тиеш түгелдер. Яхшы вә холыклы булып, гаиләсен кичендерә алырлык бер ир, эшче булса да, язучы вә солдат булса да зәүҗлеккә *(ир булуга)* лаектыр.

Ханым-кызлар өчен ата вә аналары үзләренчә бер яхшы ир эзләүләре мәгълүмдер. Яки ир үзе яучы васитасы *(арадашлыгы)* берлә кызны вәлиеннән *(хуҗасыннан)* соратыр. Менә шул вакытта кызның бу ирне каршысыннан күреп, сыйфатларын тиешенчә белүе кирәк. Әмма кызлар үзлекләреннән тапкан яки күңелләре теләгән тиешсез урыннарга кияүгә бармакчы булсалар яисә бу кияүгә бару тугрысында яшьлекләре берлә ашыксалар, алданган булырлар. Кыз бирүдә ата-ананың муафыйк күрүләре вә ризалыклары шарттыр. Әлбәттә, ата-ана үз баласының бәхетле булуын теләр. Вакыты җиткәч, насыйбы кайвакытта чыгып, муафыйк урын тугры килсә, шул вакытта ата-анасы кызларын кияүгә бирерләр. Шуның өчен гыйффәтле кыз балаларның кияүне телгә алулары да гаептер. Ләкин ата-анасы кызның мәсләгенә бөтенләй хилаф булган бер иргә бирмәкче булсалар яки малга кызыгып, яшь кызларын карт кияүгә бирүне теләсәләр, ул вакытта кызның көчләнеп ул адәмгә бармаска хакы бардыр. Әти-әни куйган иргә разый дип, араларында һичбер өлфәт булмаслык иргә бармак мәслихәт түгелдер, чөнки ул ир берлә тереклек кылачак адәм ата-анасы түгел, кыз үзедер. «Гомер өч көнлек түгелдер», – диләр. Кыска гомерне кызык уздыру – гакыллылыктыр.

КЫЗ БИРҮ

Кыз бирүдә иң артык күзәтелә торган нәрсәләр: намус, тәннең тазалыгы, күркәм холык вә нәсел булып, матурлык – иң соңыннан уйлана торган бер эштер. Бер ир матур булыр да, холкы яхшы булмас. Алай булганда гаилә өчен ул ирдән бәхет көтмәк мөмкин түгелдер.

Кыз бирер өчен бөтен байлыкны бетермәк яки әйберләрне сатмак, бурычка батмак кеби эшләр – зур гакылсызлыктыр. Бер кызның җиһазын ата-анасы ун яшеннән башлап яки тагы да элегрәк акрынлап әзерли башласалар, кияүгә биргәнгә кадәр, бер дә сизелми, кулда кирәк кадәрле җиһаз әзерләнгән булыр. Кыз бирү тугрысында һәркем юрганына күрә аягын сузарга тиеш. Артык акчалар бетереп, кирәк булмаган вә тотарга ярамаган артык зиннәтле нәрсәләр лязим түгелдер. Җиһаз бер өйгә, бер гаиләгә җитәрлек иң кирәкле нәрсәләр булмак кирәк. Һәркем өйләнүнең сәгадәтен җиһазда дип түгел, кияү берлә кыз арасындагы мәхәббәттә вә бер-берсенә килешүләрендә булуына канәгать кылырга тиештер.

Бу тугрыда кеше күрсен дип, һич кирәкмәс нәрсәләрне җиһаз арасына тыкканнар, ахырында кулларында һичнәрсәләре калмый, алданган булырлар. Бер мәртәбә кияү өчен әллә ничә йөз тәңкәлекләргә төшкән килен күлмәкләре, тарлыкка төшерерлек кадәр уздырышка эшләнгән кыйммәтле нәрсәләр – начар эшләрдер.

Кызларны кечкенә вакытларында вәгъдәләшеп яки никахлап куймак яхшы түгелдер. Шуның өчен өйләнмәк – һәрбер җәһәттән Мөхәммәд с.г.в. шәригате даирәсендә булмак лязимдер. Ир берлә хатын бер-берсенең кадерен белеп, хатын иренә чын мәхәббәт берлә хезмәт итеп, ир дә хатынына чын күңелдән мәхәббәт итмәк кирәктер.

ИР БЕРЛӘ ХАТЫН

Өйләнүдә максуд булган нәрсә – нәселне арттыру берлә бергә тереклек кылмак вә гаиләнең сәгадәте булганга күрә, ир берлә хатын бу хосусны күзгә алып, һәрвакытта яхшы киченергә тырышмактыр. Моның өчен дә бер-берсенә каршы һәрбер вакытта яхшы эш вә гүзәл хәлдә булулары лязимдер. Бу тугрыда ир берлә хатын арасында иң әүвәл эзләнә торган нәрсә – мәхәббәт вә чын ихластыр. Бер-берсеннән нәфрәт берлә киченмәк һәрвакыт тавыш-гаугага вә гаилә арасында тынычсызлыкка сәбәптер. Һәр ханымга рәфикъ хәятен *(тормыш иптәшен)* камил ихлас берлә сөймәк вә аңа итагать вә хөрмәт кылмак, вә һәр заман махсус ригаядә *(игътибарда)* булып, аның өчен кайгырып, ихласлы юлдаш булмак тиештер.

Һәрбер ир дә рәфикасен шул хис берлә сөеп, ирлеккә муафыйк, инсанияткә лаек сурәттә аңа күркәм мөгамәлә күрсәтмәк тиештер. Кайсы илләрдә күренгән кеби, хатыннарның ирләренә баш булып хөкем итәргә керешүләре, аларны бер хезмәтче кеби хезмәт иттерергә тырышулар һәм гөнаһ һәм дә гаептер.

Ир – хатынның вәлисе *(хуҗасы)*, махсус әмиредер. Хатын да әфәндесенең рәфикаи хәяте, җан юлдашыдыр. Бер хатынның иренә каршы зурайган төсле булып бер кырын каравы да, ул хатынны бик каты шелтәләргә тиешле булган хәлләрдәндер.

Ханымнар үз әфәнделәренә каршы һәрбер вакытта тәгъзыйм *(олылап)* вә хөрмәт итеп, аларга каршы синлебәнле сүзләр әйтүдән сакланып, «син» урынына «сез» диеп сөйләшмәк вә ире

чакырган вакытта «Әфәндем!» диеп йөгермәк, бернәрсә эшләргә кушкан вакытында «Баш өстенә, әфәндем!» кеби татлы сүз вә ыспайлык берлә кушкан йомышны үтәмәк лязимдер.

Бер хатын иренең сөюенә мәгърур булып, кирәк хаклы да булсын, иренә каршы төсен бозса, иренең мәхәббәтен киметүдән вә бара-бара араларында салкынлык хасил булудан башка бер файдасы да юктыр.

Ир берлә хатын арасында төпле бер ышаныч хис урынлашырга вә болар һичбер вакытта бер-берсен алдамаска тиештер. Иренә килә торган кайгыдан хатын да чын күңелдән кайгырып, бер пар күгәрчен кеби, бер-берсенә күркәм мөгамәлә вә ярдәмдә булмак тиештер.

ЯНӘ ИРЛӘР

Ирләр кайсы вакытта тыштагы бер эштән җәфа вә кайгылы булып өйгә кайталар. Ул вакытта алар бик ачулы вә илтифатсыз күренәләр. Аның бу хәлен күреп хатын да үпкәләргә тиеш түгел. Җае берлә генә кайгысының сәбәбен сорап, аны ничек булса да юатырга тырышмак кирәк. Кечкенә генә бер тавышны зурайтмый, мәслихәт берләр төзәтү юлларын белмәк – бер хатын өчен иң кирәкле бер эштер.

Бер дә иренә кирәгеннән вә чигеннән артык нәрсәләр алырга кушып борчымаска, аны артык расходландырмаска тырышмак лязим. Иренең гаепләрен һичбер вакытта йөзенә ормый, аның хакында һичкемгә зарланмаска тиештер.

Бер ир бәгъзе бертөрле тиешсез вә начар эш эшләсә дә, аны хөрмәтсезләрлек дәрәҗәдә булмый, аулакта, кеше юк вакытта гына йомшаклык берлә аның хәлен төзәтерлек сүзләр сөйләргә кирәк.

Иренең рөхсәте булмаган вакытта бер хатынның күршеләренә, хәттә анасының йортына баруы да шәргый дөрес түгелдер. Ирнең хакы бик олугтыр! Ханымнар аның кадерен бик белергә тиеш! Бер ханым иренең чиста киенүенә, киемнәрен чистартырга тырышмак, өй эчендә аның рәхәте өчен лязим булган нәрсәләрнең һәрберен әзерләмәк берлә мөкәлләф *(йөкләнгән)* булганын онытмаска тиеш. Кич берлә арып-талып өенә кайткан ир, хатыны тарафыннан көләч йөз, тәмле сүз берлә каршы алынырга тиеш. Өстен чишендереп, аякларына бирмәк, һәрвакыт кушкан эшенә йөгерергә әзер тормак – хатынның бурычыдыр. Ир дә өенә кайткан вакытта бер бәхетле ояга кайтуына ышанып, бөтен арганлыкларын, бөтен кайгыларын, шул үз оясында бетерергә тиеш. Ир берлә хатын арасындагы сүзләр, киңәшләр вә хәттә бөтен кыланмышлар нәзакәтлек, ягымлылык вә әдәп берлә булырга тиеш. Иренә хаҗәт булган вакытта акча берлә вә башкача ярдәм кылган хатыннар, соңыннан сиңа шуны бирдем, тегене эшләдем, дип, иткән изгелекләрен йөзенә ормак яки башкаларга сөйләмәк кеби тәрбия вә инсаниятән тыш эшләрдән бик сакланмалыдыр. Мондый сүзләр сөйләүчесенең тәрбиясезлегенә дәлилдер. Азгынлыкка сәбәп була торган тиешсез эшләр, тавыш-гаугалар, холыксызлыклар, шәргый сәбәптән башка аерылышулар, шәригать вә инсаният йөзеннән мәмнугътер *(тыелган)*. Кыскасы, ир хатынын вә хатын да ирен бик тирән вә саф бер мәхәббәт илә сөймәк, үзләренең хәлләренә күрә бер тән кеби киченмәк, яшәмәкне, бер-берсенә һәрвакытта ярдәмләшмәкне белеп, шул рәвешле гаиләнең бәхетле булуына тырышмак лязимдер. ■

Әманәт

Мөхәммәт Галләм

«Пәйгамбәребез (ﷺ) Хәйбәр бәрелешләрендә булганда бер көтүче йөзләгән сарыклары белән килде дә болай диде:

– Мин мөселман булырга телим. Бу сарыкларны да Ислам гаскәренә бирергә теләгем бар.

Пәйгамбәребез (ﷺ):

– Мөселман булырсың, безнең кардәшебез дә булырсың. Ләкин бу сарыклар кемнеке?

– Хәйбәр бистәсендәге бер бай кешенеке.

– Син көтүче вазифасын башкарасыңмы?

– Әйе.

– Алай булгач, бу маллар сиңа әманәт ителгәннәр. Әүвәл бу әманәтне алып кит. Сәхибенә тәслим ит. Соңыннан килеп безгә кушыл.

Көтүче нәкъ Пәйгамбәребез (ﷺ) боерганча эшләде...» – диелә бер риваятьтә.

Пәйгамбәребезнең, пәйгамбәрлек килгәнчегә кадәр шәрәфе Мөхәммәд-Әмин була. Бөтен Мәккә аңа бу исем белән эндәшеп, аңардан канәгать кала. Иң кыйммәтле әйберләрен гел аңа тәслим итәләр. Хәтта һиҗрәт якынлашкан вакытта да Пәйгамбәребезнең (ﷺ) янында бик күп әманәтләр була. Мәдинәгә һиҗрәт итү вакыты якынлашкач, хәзрәте Галигә (رضي الله عنه) боларны тапшырып, ияләренә бирүен үтенә.

Әманәтне тиешле җиренә тапшыруны фазыйләт, әманәткә хыянәтне монафикълык галәмәте итеп санаган Пәйгамбәребез (ﷺ) бу мәсьәләдә шулай боера:

«Әманәт әһлиятсез кешегә бирелдеме – кыямәтне көтегез».

Әманәткә тугрылык булмаган бер җәмгыятьтә кешеләр арасында төрле җайсызлыклар, ризасызлык, канәгатьсезлекләр, хаксызлыклар киң таралган булыр.

Һәр мөселман үзенә әманәт ителгәннәргә җаваплыдыр. Вөҗүдебез яки тәнебез – бер әманәттер, бала-чагаларыбыз – әманәттер, мал-байлыкларыбыз да безгә бер әманәттер.

Кешеләрнең бурыч-йөкләмәләренең саклануы өчен бирелгән әйберләр дә әманәттер.

Әманәтләргә тугрылык итүне Бөек Раббыбыз әмер иткән.

Алда әйтелгәнчә, «Ниса» сүрәсенең 58 нче аятендә:

«Сезгә әманәт ителгән малларны ияләренә кайтаруыгызны вә кешеләр арасында хөкем йөрткәндә гаделлек белән эш итүегезне Аллаһ сезгә әмер итте. Менә шулай Аллаһ сезгә гүзәл рәвештә үгет бирә. Хактыр ки, Аллаһ барысын да ишетеп, күреп тора», – диелә.

Ошбу әмерләргә оеп, әманәтләрне саклыйк, әманәткә хыянәт булмасын! ■

ДОГАЛЫ китаплар нәшрияты

Айзирәк Гәрәева

Республикабызда унга якын нәшрият уңышлы гына дини китап нәшер итү белән шөгыльләнә. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты алардан кай ягы белән аерыла соң? Гомумән, бүгенге көндә дини-догалы китапларны бастыру, тарату эше ни рәвешле алып барыла?



«Хозур» күңелләрне рухи яктан баету һәм ислам кыйммәтләрен тарату нияте белән 2013 елда оештырылды. Биредә һәр дини китап Татарстан мөфтиятенең экспертлар шурасы хуплавы белән басыла. Ягъни, басмалар укучылар кулына барып җиткәнче дин белгечләре тикшерүен уза. Дингә кагылышлы мәгълүмат һәм өйрәтүләр күп, шуңа күрә китап чыгарганда аеруча сак булу сорала.

«Хозур»ның, бигрәк тә яшьләрне күз алдында тотып, үзенең интернет сайтларын ачуы, башкалар белән чагыштырганда үзгә ягы булып тора. www.huzur.ru сайтында нәшрият йортының барлык интернет-проектлары, китаплары һәм полиграфия продукциясе тәкъдим ителә. www.darul-kutub.com электрон китапханәсендә исә инкыйлабка кадәр дөнья күргән татар дин әһелләре, шулай ук бүгенге авторлар язган 240 китапның электрон варианты урын алган. Алар арасында Мисыр, Һиндстан, Пакыстан, Япониядә татарчадан гарәпчәгә тәрҗемә итеп басылганнары да, иске татар имлясында дөнья күргәннәре дә бар. Биредә Риза Фәхреддин, Галимҗан Баруди, Әхмәтһади Максуди, Мөхәммәд Әмин бине Габдулла, Әбделкаюм

бине Әбдүнасыйр, Шәйхелислам бине Әсадулла, Муса Бигиев, Габдрахман Карабаш һәм башка дин галимнәре хезмәтләренең электрон нөсхәләрен табарга мөмкин.

Электрон китапханә булдыру ул, рухи мирасны китапханә киштәләреннән, архивларыннан интернет аша өйгә, эш өстәленә китереп куюга тиң. Бу эшне нәшрият КФУ, РИИ китапханәләре белән хезмәттәшлек итеп алып бара. Шулай ук хәзрәтләр чит илләрдәге төрле очрашуларда татар дин галимнәренең инкыйлабка кадәр чыккан, таралган җыентыклары белән даими кызыксына һәм аларны республикага алып кайту җаен карый.

Әлбәттә, рухи мирасны торгызу, иң беренче чиратта, бабаларыбыз китапларын нәшер итүдән һәм хәзерге буынга җиткерүдән гыйбарәт. Бер карага̀нда, бу эшнең авырлыгы юк та кебек – тирән гыйлем тупланган әзер әсәрне бастыр гына! Болай әйтү җиңел, ә чынлыкта бит әле аны иске татар имлясыннан яки гарәпчәдән тәрҗемә итәргә, бүгенге укучы аңлый алырлык телгә күчерергә дә кирәк. Монда, әлбәттә, шушы эшкә махсуслашкан тел белгечләре, тәрҗемәчеләрне табу мөһим. Кызганыч, бүгенге көндә бу өлкә белгечләре бармак белән генә санаулы. Шул ук вакытта иске китапларны компьютерда җыю, яңа китап рәвешенә китерү мәшәкате дә өстәлә. Шуннан соң гына әсәрне бастыру турында сүз барырга мөмкин.

Изге китаплар һәм догалыклар, нигездә, киң катлам укучыга тәкъдим ителсә, дини хезмәтләр арасында исә бары тик тар даирә, ягъни исламны тирәнтен өйрәнүче шәкертләр, мөгаллимнәрне, хәзрәтләрне күз алдында тотып бастырылганнары да бар. Әйтик, кайбер басмалар махсус белгечләрне җәлеп итеп һәм зур чыгымнар түгеп әзерләнә, әмма аларны нәшер итү тиражы 500дән дә артмаска мөмкин, чөнки ул китап әсбап буларак бары тик мәдрәсәләргә генә кирәк. Наширләр исә яхшы белә, кечкенә тираж китапның бастыру чыгымын да, мәшәкатен дә капламый. Шуңа да карамастан, «Хозур» өчен республика мәдрәсәләрен дәреслекләр, уку әсбаплары белән тәэмин итү иң тәүге бурычларның берсе.

«Хозур» нәшрият йортының тагын бер эш юнәлеше – басма матбугат чыгару. Аерым алганда, сүз Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең «Дин вә мәгыйшәт», «Умма» газеталары һәм «Шура» альманахы турында бара. Әлеге газеталар мәчетләрдә, мәдрәсәләрдә бушлай таратыла. 2014 елда Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин мөхәррирлегендә махсус имамнар өчен «Шура» тарихи басмасы янә нәшер ителә башлады. Яңа басманың тәүге санында мөфти Камил хәзрәт журналның хәзерге заманда да кирәклегенә игътибар юнәлтте: *«Татар халкы тарихы, милли үзаңы, татар әдәбияты тарихы, шулай ук башка мөселман төрки халыклары турында сүз барганда бик еш кына «Шура» исемле журнал телгә алына. 2013 елны, күп кенә дини мәсьәләләр яктыртылган «Шура» журналы чыга башлауга 105 ел тулды. Бүгенге көн күзлегеннән карага̀нда, мондый төр басмага ихтыяҗ гаять зур, чөнки ислам дине җәмгыятебезгә көннән-көн ныграк үтеп керүен дәвам итә һәм, шул рәвешле, тормыш-көнкүреш алга киткән саен, дин белгечләре алдына хәл итәсе күп кенә мәсьәләләр килеп баса».*

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан «Шура» дин әһелләре өчен өстәл альманахы бу-

ларак таратылды. Анда бер квартал эчендә укыла торган барлык җомга һәм гает хөтбә-вәгазьләре тәкъдим ителә. Җәлил хәзрәт Фазлыев, Рөстәм хәзрәт Батыр, Илдар хәзрәт Баязитов, Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, Мәхмүт хәзрәт Шәрәфетдинов, Нияз хәзрәт Сабиров һәм башка дин әһелләренең дингә кагылышлы мәсьәләләрне аңлаткан тирән мәгънәле язмалары да укучыларны битараф калдырмый. Танылган татар галимнәренең фәнни мәкаләләре исә татар халкы, ислам тарихын өйрәнүгә зур этәргеч булып тора.

XXI гасырда дини китапларга ихтыяҗ зур. Халык вәгазь, хәдис, дини риваять җыентыкларын, гыйбадәтләрне башкаруны өйрәткән китапларны сорый. Самара, Төмән кебек шәһәрләрдән дә татарча китап эзләп мөрәҗәгать итәләр, имамнары исә «Шура» журналын Россия күләмендә таратуны сорый. Хәтта республикабызның авылларына да мөселман китаплары килеп җитми. Менә шушы ихтыяҗны күздә тотып, нәзарәт тарафыннан мөхтәсибәт мәчетләрендә «Хозур» китап киштәләрен булдыру турында карар кылынды.

Шулай ук меңләгән милләттәшебез җыелган Болгар җыены кебек олуг чарада да дини китап ярминкәсен үткәрү тормышка ашырыла башлады. Гадәттә, дини китаплар сату оештырылган чатырдан, иртәннән алып, җыен тәмамланганчыга кадәр, халык өзелми. Дини китап ярминкәсе бабаларыбыз ислам динен рәсми кабул итүгә багышлап үткәрелә торган җыенны рухи яктан тагын да баета, дип әйтергә мөмкин. Россиянең төрле төбәкләреннән килгән имамнарның Болгардан Мәрҗани, Ялчыгол кебек бөек татар дин галимнәре китапларын алып китүләре үзе бер күңелле вакыйга. Быел да «Хозур» нәшрият йорты май аенда уздырылачак Болгар җыенында өченче мәртәбә Россиякүләм дини китаплар ярминкәсен оештырыр дип көтелә. ■

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

Кутадгу билик

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

Юк. Кирәкми, булмыйм мин моңа даир[1]:
Дәүләт куласасы минсез әйләнер.

Тагатьле көннәрем миңа куаныч,
Ходай әмре үзе бер зур юаныч.

Сөю-сөекләләр, җиңүләр нигә?
Гыйбадәтемдә мин шәйтанны җиңәм.

Теләгем Тәңредән, өметем аннан,
Ходай аермасын гына иманнан.

Киемем куй җөне, ашыйм арпа аш,
Үәм дөньям түгәрәк минем, и, кардәш.

Миһербанлы берәү бар, яши гарда,
Ишет сүзен, лаектыр игътибарга:

— Кибәк ашыйм вә йон чикмән иңемдә,
Ләкин патшага тиң мин үз өнемдә.

Кибәк бутка миңа шикәрдәй татлы,
Тупас үрмәк[2] исә ефәк сыйфатлы,

Карынны туйдырса ашам-эчемлек,
Кирәк арпа, кирәк бүтән үсемлек.

Барча ашлык — аша күҗә пешереп,
Сыерча ашама — сакла эчеңне.

Ашамлыкның таты — азабы каты,
Тәм-том өчен түләү — китәрсең батып.

Сөчек тәм-том ашап яшәү күңелле,
Ләкин ашау куган — кеше түгел ул.

Кеше асыл ефәк киеп, тун кисен,
Ләкин тәне-җаны шуңа тап килсен.

Бер туенсаң ике көнгә җитә ул,
Яңа кием ике елга тотә[3] ул.

Җидешәр катлы күк һәм җир астында
Моң-гамь бар Адәмнең һәр баласында.

Азатсыз-гамьсез тик Тәңре генә ул,
Ләкин барчасының хәлен белә ул.

Тик Аның каршында тезләнәмен мин,
Теләнсәм дә, аннан теләнәм инде.

Әзер миңа шиксез бөтен кирәгем,
Күңелгә хуш җир-су монда җитәрлек,

Барлыгын беләм һәм эзлим йокысыз.
Тик каян табарга — юк бу хакта сүз.

«Тәңрем!» димен, күзгә йокы да керми,
Тап булам бер эзгә — үзе күренми.

Кеше асыл ефәк киеп, тун кисен,
Ләкин тәне-җаны шуңа тап килсен.

---

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы саныннан басылып килә.
[1] Даир – даирәгә керүче, катнашучы.
[2] Үрмәк – «үреп эшләнгән йон тукыма» (әрмәк сүзе дә шуннан).
[3] Тотү – житү, җитәрлек булу.

Теләгеңә ireш, йоклама, тынма,
«Юлы табылмый», дип тукталып торма.

Тик һаман да тынма – кыдырып эзлә,
«Эзләдем, эзләдем – тапмадым», димә.

Эзләүче тынмасын – эзләсен һаман,
Соң бит тик ятучы тапмас һич заман.

Хәтта син – эзләүче таба алмасаң,
Тик яткан бәндәләр тапмас һичкайчан.

Ул мине теләде – бар итте сөеп,
Мин аны телимен «кайда син», диеп.

Мине ул ярaлтты – үзе мәңгелек,
Хәзер эзлим аны төп-төгәл белеп.

Соң, шундый ияне ничек сөймәссең,
Ничек табыйм аны, дип өзелмәссең?

Каза-кайгыда ул ярдәмгә килә,
Моңым – ялгызлыгым өчен дә кирәк.

Тагатьчелеккә ул мине сайлады,
Табыйм, дип күңелен тырышыйм аның.

Теләгеңә ireш, йоклама, тынма,
«Юлы табылмый», дип тукталып торма.

Түрәтте ул мине – будыр чын сүзем,
Мине ул үстерде һәм үстем үзем.

Сыгынам тик аңар, дүндем халыктан,
Химаяли мине ул төрле яктан.

Ышанган, сыгынган, таянган терәк,
Ачым-тугым шуннан һәм ул бер генә.

Ялгызлыкта тәңре хәтере иптәш,
Сөйләшергә Алла исеме житә.

Ни ди, ишет, әнә күңле пакь кеше,
Хак белән арасы ачык, саф кеше:

«Күңел серләремне ачамын сиңа,
Теләкләрем белән очамын сиңа,
Ышанган, табынган сыгынган иям,
Һәр араны өзеп, качамын сиңа».

Теге дөнья өчен бу дөнья капка,
Бу дөньядан үтми аны кем тапкан?

Башың күккә тисә бөеклегеңнән,
Барып ятыр урның туфрактан түбән.

Һәм дөнья хәстәрен кылмастан, кеше
Эшли алмас төп дүрт гыйбадәт эшен.

Йөз чөереп һәм кул селтәп китәрәк,
Ахирәт нурына ирешү кирәк.

Бу фани дөньяга ябешеп ятып
Ничек мөмкин мәңге яшәүгә җиту?

Хәтәр дөнья: монда һәр йотым – агу.
Ару-саф эчемлек кирәктер табу.

Ташла бу дөньяның теләк-арзусын,
Ахирәттә якты урын алырсың.

Хакыйкать шул дип бел, и, Үгделмешем,
Әйткәннәрем сиңа – барча белмешем.

Бу дөнья эшләрен куймыйча тәмам,
Ахирәт эшенә кул җитмәс, туган.

Кешеләрдән ерак китмәгән хәлдә
Гыйбадәткә вакыт тапмассың, кардәш.

Нәфес-һәвәс муенын сындырмый торып,
Табылмас Тәңрегә тирән тугрылык.

Күңелдән чыгарсаң барча дөньяны,
Ходай мәхәббәтен табарсың аны,

Дөнья – кәрвансарай мөселманнарга,
Кәрвансарайда кем тынлык табалган.

Нәфесеңә өмет бирмә – каты бул,
Тик шулай үтәрсең – алда олы юл.

Зая кылма үтеп барган көнеңне,
Һәрбер үткән төнең – ул кайтмас инде.

Зая үтсә көнең – үкенәчәксең,
Зая үтсә гомрең – син киләчәксез.

Ни ди, ишет, әнә беләме диңгез,
Укымышлы, ипле, күңеле идез:

«Җәйләүдән җәйләүгә күченгән кеше
Күчне алдан куса, дөресрәк эшли.
Ягъни күч җибәрсә күчүдән элек,
Күз ярытыр[4], һәйбәт эшли ул, белеп».

Кирәк, җибәр күчне, кирәк, җибәрмә,
Үзең бер күчәсең, тик гафил йөрмә.

Кирәк бай бул, кирәк мескен генә кол,
Качып калалмассың – үлем тота ул.

Кирәк бай бул, кирәк юксыл бер чыгай[5]
Гомереңне ашый һәрбер көн, ел, ай.

Башың күккә тисә бөеклегеңнән,
Барып ятыр урның туфрактан түбән.

Гомерен уздырса кеше заяга,
Ул үз-үзен утка аткан бер хайван.

Исән-сау ир зая үткәрсә гомрен,
Күрексез тереклек ич бу, кадерлем.

Минем кайгым илә борчылма кардәш,
Үз кайгыңны кайгыр, түгеп күздән яшь.

Бу дөнья эшләре ныклы тозактыр,
Тозакка эләкмә – аннан ерак тор.

Бүгенге дәүләтең бик һәйбәт килгән,
Куанма тик аңар – үтәр ул тиздән.

Гафил булма – үлем тора поскында,
Көтмәгәндә аның угы ычкына.

Гафилләрне үлем хәтсез баскандыр,
Җыелган мөлкәтне хәтсез чәчкәндер.

---

[4] Күз ярыту – күп телләрдә, шулай ук Себер татарларында таралган фразеологизм, «шатландыру».
[5] Чыгай – иң ярлы күчмәнче (бу сүздән чегән – чиган сүзе дә килә).

Ни ди, ишет, күңле уяу инсаннар,
«Үлем галәмәте килер дә чыгар».

Күпме халаекны таркаткан үлем,
Шуны уйласам шул – яшьләнә күзем.

Ни мәгърур бәндәләр, берсе калмады.
Корал һәм гаскәрләр файда кылмады.

Бел, яшәү ташкыны тиз өерелә,
Кабатланып кайтмый узган гомерләр.

Мавыкма ләззәткә – көн үтәр зая,
Куанма дәүләткә – түбән ул, тайгак.

Бөекмен, дигәннәр түбән яттылар,
Олугмын, дигәннәр туфрак астында.

Азмы үлем бозган шәһәр-авыллар,
Сәрайлар хәрабә булып калдылар.

Ничә мең яшәгән һәм күмелгәннәр
Көтеп торалардыр без дә килгәнне.

Кара хәрабәгә – үткәр күзеңнән:
Кол ятамы, бийме кабер эзендә.

Олуглык үлемнән им-дару булмас,
Үлем елгасыннан кичү табылмас.

Бөек сәүчеләрне үлем ләктерде,
Бүтән кемнәр генә котылыр инде.

Инанычсыз дөнья – җәфачы нәрсә,
Кырыкка кылтая – кылыгы исәр.

Ниләр кичерсәң дә ул үтте-китте,
Яман-яхшы, кәкре-төз үлде-китте.

Гомер үтә – кирәк тук бул, кирәк ач,
Бай-кол йә ярлы-бай дип, бик аермас.

Рәхәте сузылмый, михнәте уза,
Нигә чумыйм икән шундый мондызга[6]?

Уңышлардан бәндә онытыр үзен,
Зәңгәр күктән биек йөретер сүзен.

Ни шәп әйткән элек белеме киң зат –
Белеменә холкы, күңеле тиң ирзат:

Уңышлардан бәндә онытыр үзен,
Зәңгәр күктән биек йөретер сүзен.

Ни шөһрәтле, горур кемсәләрне дә,
Үлем зая итте, сукты-бәрде дә.

Бу сүзләрем сиңа мәхәббәтемнән,
Сине олы җанлы кеше дип беләм.

Мин әйткәннәрне чын белгән кемсәләр,
Дөнья шау-шуыннан ерак китәләр.

Егет чагым узды, җитте яшем дә.
Җофар исе бетте, акбур башымда.

Үлемгә әзерлек күрү моннан соң
Минем бурычымдыр, и, шәп туганым.

Килде үлем гаме, китте сөенеч,
Үлемнән соң хәлем бик билгесез ич.

Шундый кайгы башка төшкән көнемдә
Ник илбиклек касты булсын, ди, миндә.

Һәм илбиккә миннән булмастыр файдам.
Кылыйм, дисәм ярдәм – ни эшли алам?

Ул мине теләсә дөньялык өчен,
«Күргән кебек булдым мин аны», дисен.

Адәм баласына ирек бирелгән
Китәргә, дип ике юлның береннән:

Тәмуглы йә оҗмах бәге булырга,
Рухи олуглык йә пислек кылырга.

Дәвамы бар ■

[6] Мондыз – татар сөйләшләрендә очрый – «пычрак ташкын, сил».

ИСХАК МОСУЛИ
ҺӘМ КӘРҖИНЛЕ САРАЙ ХИКӘЯТЕ



Хикәяттә китерделәр: мөселманнарның әмире Һарун әр-Рәшиднең төрле һөнәр һәм сәнгать белән бизәүле бер надиме, ягъни хезмәткәре бар иде, хезмәтчеләрнең хуҗасы иде, аты Исхак Мосули иде. Һарун аны башка хезмәткәрләреннән артык сөяр иде, аулак вакытының күбесен аның белән үткәрер иде. Шулхәтле сөяр иде – йокы вакытына тикле җибәрмәс иде…

Исхак бер кичә хәлифә белән аулакта утырудан кайтып килгәндә очраклы рәвештә шундый вакыйгага юлыкты:

Өенә кайтып барганда, кысталып, йомышына утырган иде. Шулвакыт күрде: патшаларча киенгән берәү йөгереп бер сарай төбенә барды. Карады, бер бау асылынып

тора. Баудан тартуга кәнизәкләр, хезмәтчеләр түбә өстенә чыктылар. Ул бауның очына бер олы кәрҗин бәйләп, түбән төшерделәр. Ул шәхес кәрҗингә керде, бауны тарттылар, югары мендерделәр.

Исхак бу хәлне күрде, үз юлы белән китте, өенә кайтты, әмма бу хакта уйлаудан туктамады. Иртә торып хәлифә янына баргач, аңа сөйләде.

Хәлифә:

– Ул сарайның кайда икәнен беләсеңме соң? – дип сорады.

Исхак:

– Беләм, – диде.

Менә кич булды, караңгы төште. Шул урынга барырга теләде. Килсә – бау асылынып тора. Тартты, шундук кәнизәкләр килделәр, кәрҗинне бәйләделәр, аска төшерделәр. Исхак кәрҗингә керде, югары тартып алдылар. Күрделәр: бөтенләй ят адәм. Исхакны ташладылар, үзләре качтылар. Исхак каты курыкты:

– Ни кызганыч! Килерләр, мине үтерерләр, – диде. Шул уйда торганда, кәнизәкләр барып йорт иясенә әйттеләр, егерме-утыз карабаш, ягъни хезмәтче кызлар белән бу килгән кешене күрергә килделәр. Исхак олы хәүфкә төште:

– Ай-вай! Юкка монда килдем, бу караңгы төндә бу вакытта миңа кем ярдәм итәр?! – диде.

Шул фикердә торганда боларның банулары килде. Бер гаҗәп кыяфәтле, йолдыз кебек кыз икән, башыннан аягынача алтын-көмешкә чумган. Көлә-көлә килде. Аны күргәч, Исхакның хәле китте, кул-аягы тетрәде, чак түзеп торды. Ул кызның сөйкемлелегеннән, ымсындыргыч, күңел кузгаткыч матурлыгыннан шаккатып, хәйран калды. Кыз аны күргәч:

– Мәрхәба! Хуш килдең, әй, аягыннан тотылган! – диде.

Исхак җир үпте. Кыз Исхакны алып сарайга керде. Үзе тәхет өстенә утырды. Исхакка алтын көрси, ягъни урындык куйдылар, утырдылар. Шундук ширбәт китерделәр, мәҗлес әсбапларын алып килеп, күңел ачтылар. Кыз боерды, шиштар[1] дигән саз китерделәр, шундый көйләр уйнадылар – Исхак сихерләнеп, гаҗәпләнеп һуштан язар дәрәҗәгә җитте. Әйтте:

– Йа Хода! Йа ханым-әфәндем! Түземем төкәнде, рөхсәт ит, аягыңны үбим, аяк эзләреңә баш куйыйм! – диде. Кыз бер җариягә ишарәт итте, ул җария аның башын кысып тотты, башкалары берәр мәртәбә яңагына чалтыраттылар. Кыз һәм кәнизәкләрнең көлә-көлә хәлләре бетте.

Аннан соң ул кыз, саз чалучы кәнизәкләр янына утырып, хуш аваз, хуш аһәң белән җырлады, шушы бәйтләрне әйтте:

– И дуст, хата кылдым, бисйар җәфа кылдым,
Силли бәкафа кылдым, белдем ки җәбран кылдым.
Арканы дута кылдым, гәрчә базәза кылдым,
Хак ки хата кылдым, эрүме һава кылдым.
(И дус, хата кылдым, бик күп җәфа кылдым,
Башыңа суккаладым, белдем ки җәбер кылдым.
Арканны бөкере кылдым, гәрчә, тиешлесен кылдым,
Дөресе: хата кылдым, эреләндем, һаваландым.)

Аннан әйтте:

---

[1] Шиштар – алты кыллы музыка инструменты.

– Исхакның чарасын менә бу җария белер, килсен, күрсәтсен, – диде. Кызның ишарәте белән җария килеп, Исхакның яңагына бик каты сугып җибәрде. Исхакның күңеле сүрелде, эченнән әйтте:

– Чыгам, үземне түбәдән түбәнгә ташлыйм, бу кыенлык, бу кайгы кулыннан котылам, – диде.

Исхак бу фикердә торганда, кыз коралын кырыйга куйды, көлеп-елмаеп ул кәнизәкләргә кычкырды:

– Әй, явызлар! Читтән килгән олы кеше бу кичә кунагыгыз булды, ни өчен болай дошманлык итәсез?! – диде һәм чыгып китте. Кәнизәкләр дә артыннан чыгып киттеләр, төзелгән мәҗлес, эчемлек-ашамлык һәм уен кораллары ул җирдә шул килеш калды.

Исхак, аулак калгач, уен коралларыннан бәрбатны[2] кулына алды, колакларын борды, чалды, җырлады, төрле көйләр башкарды. Бу вакытта кыз баягыдан да артык тәкәллеф белән килеп керде.

– Йа Хода! Син чынлап та Исхакмы әллә?! – дип сорады.

Исхак:

– Әйе, – дип җавап бирде.

Кыз сөенде:

– Күптәннән бирле исемеңне ишетә идем, «ни булыр иде – беркөн күрсәм иде», дияр идем, инде сине күрүем яхшы булды, – диде. Моңынчы булган хәрәкәтләр өчен үкенеч белдерде, гафу үтенде. Шундук падишаһларча киемнәр китерделәр, Исхакка кидерде, тәхет өстендә бергә утырдылар. Аннан кыз кулын Исхак кулларына сузды, бәрбатны уйнатты, Исхакның күңелен күрергә тырышты, хезмәтләр итте.

Төннең яртысы җитте, Исхак китәргә рөхсәт сорады.

Кыз ант эчте:

– Сине туйганчы күрмичә, сиңа китү булмас, – диде.

Аннан соң яңадан бераз утырдылар, сөйләштеләр, серләштеләр. Кыз китмәде, Исхакка парча урын-җир, җәймәләр түшәделәр. Исхак йокларга ятты. Таң атканда, Исхак әле йоклап ятканда, кыз баш өстенә килде, якынлык теләде. Никадәр чигенсә дә, ирек куймады, башка чара булмады...

Шулай итеп, вакытның ничек үткәне сизелми дә калды.

Исхак:

– Инде өч төн, өч көн янында булдым, моңа һич кайгырмыйм, әмма мөэминнәрнең әмире мине эзләр, бик кайгырыр, кайдалыгымны һичкем белмәс, өемдә шулай ук мине «үлде» дип уйлап, матәм тотарлар. Боерсагыз, мин кайтыр идем, хәлемне белдерер идем. Аннан соң теләсәң кайчан хезмәтеңә килер идем, – диде.

Кыз Исхакка бер янчык алтын, егерме кисәк алтын җепләр белән тукылган төрле төстәге тукымалар бирде. Кәрҗингә куеп, түбән төшерделәр, өенә күндерделәр.

Исхак өенә кайтты. Күрде: матәм тотканнар, кайгырышырлар, елашырлар. Еларлар икән – көлделәр, сөенделәр. Алтынны һәм тукымаларны күреп, куандылар.

Бу төн Исхак өендә йоклады. Иртән хәлифәдән кеше килеп, сарайга килүен үтенде. Исхак барып, тәмам вакыйганы сөйләде. Анда булган хәлләрне шундый итеп сурәтләп бирде ки – Һарун кызыкты, анда барырга теләде.

[2] Бәрбат – кыллы музыка коралы, лютня.

Исхакка:

– Әлбәттә, синең белән шулай мин дә барам, – диде.

Моны ишетеп, Исхак кайгырды:

– Әй әмире-л-мөэминин! Ни диим? Сине анда ничек итеп таныштырыйм? – диде. Хәлифә уйга төште:

– Ярар, берәр җаен табарбыз, – диде. Аннан соң Һарун вәзирләр янына чыкты.

Исхак өенә кайтты, кайгырып утырды. Кинәт бер хатын килеп керде, кулындагы сернамәсен, ягъни яшерен язуны Исхак кулына салды, үзе китте. Исхак сернамәнең мөһерен куптарды, укыды. Язылган: «Кичәге мәҗлестәшләр сезгә сәлам күндерәләр, кулыгызны үбәләр, бу кичә, кунакка рәхим итәрсез, – дип өмет итәләр». Исхак нишләргә дә белмәде, хәлифәгә барып, язуны күрсәтте. Хәлифә хатның эчтәлеген белде, әйтте:

– Әлбәттә, мин дә барам, – диде.

Исхак:

– Мин сине анда нинди сылтау белән кертермен икән? – диде.

Хәлифә:

– Хезмәтче сыйфатында булырмын, син керерсең, мин калып торырмын. Кергәч: «Карабаш кызларыгыздан курыктым, теге көнне каты суктылар, бүген менә бер хезмәтче белән килдем, боерсагыз, керсен, хезмәтемдә булсын», – диярсең. Ул үзе рөхсәт итәр, мине югары мендерерләр. Керермен, бер почмакта тамаша итеп, карап утырырмын, – диде. Бу фикерне яхшы табып, шуны карар иттеләр.

Исхак белән бергәләп шул урынга бардылар. Бау асылынып тора иде, тарттылар. Исхакны югары мендерделәр. Кыз хөрмәт күрсәтеп, каршы алды. Исхак җир үпте, әйтте:

– И ханым! Бу җарияләрегездән куркам, чөнки һәр эшне аларга боерам, исереклек һәм аеклык бар, ни булмас. Менә бер хезмәтчемне алып килдем, рөхсәт булса, керсен, – диде.

Кыз:

– Ярар! – диде. Шундук кәнизәкләр голәмне югары мендерделәр, Исхак аларга ярдәм итте. Хәлифә хезмәткә килде, голәм урынында калды, башын иеп, түбәнчелек белән торды.

Кыз әйтте:

– Хуш килдең, әй, аягы белән тотылганның таягы! – диде.

Аннан соң ризык килде, ашарга керештеләр.

Кыз Исхакка:

– Голәмеңә монда килергә рөхсәт ит, хәтере калмасын, – диде.

Шуннан соң Исхак хәлифәгә:

– Әй, голәм! Ханым боера: безнең белән ризыктан җитеш, – диде.

Голәм хезмәт итте, әдәп белән тезләнеп утырды, бер-ике тапкыр табынга сузылды, аннары пәкесен чыгарды, ризыкларны кискәләде, барысына да ярарга тырышты. Ашаганнан соң шәрабтан авыз иттеләр.

Бераз вакыт үтте, тын алырга, ял итәргә утырдылар. Шулвакыт кыз әйтте:

– Әй, Исхак! Бу голәмне бик әдәпле итеп тәрбияләгәнсең, һичбер хәрәкәтендә кимчелек күрмәдем, һәрберсе тиешенчә. Боер, безгә хезмәт кылсын, минем аңа күңелем мәел вә мәхәббәтем бардыр, – диде.

Исхак әйтте:

– Әй, ханым! Мин һәм голәм – икебез дә сиңа колларбыз, без коллар синең

игътибарыңа лаеклы икән? Голәм исә синең җарияләрең өчен дә җанын фида итәр, – диде.

Шундук барып кызның кулын үпте, ягъни «колың булдым!» диде. Кыз бу хәрәкәтне бик ошатты, аннан соң әйтте:

– Әй, Исхак! Бу голәмнең эшен карарсың, җиренә җиткерерсең, әмма аны кире сиңа әманәт итеп бирдем, миңа килгәнеңдә моны да ала кил. Әгәр бу голәмне өйдә калдырсам – голәмең халык эчендә билгеле һәм мәшһүрдер, аның үченнән миңа зыян килер, канэчкеч дошманнар бар, йә һөҗүм итәрләр, – диде.

Исхак:

– Фәрман синеке, үзең беләсең, – диде. Аннан соң кыз бәрбатны Исхак кулына бирде:

– Шул көйне уйна – мөэминнәр әмиренә хуш килгән көй булсын! – диде.

Исхак әйтте:

– Көйләр күп, әмма синең әйткәнең кайсы көй, каян белим? – диде.

Кыз әйтте:

– Фәлән кичәдә, фәлән кәнизәк белән аулакта хәлифә янында шәраб эчеп утырганда уйнаган көеңне уйна. Хәлифә шул көйне тыңларга теләде, син чалдың, кәнизәк биеде, – диде.

Исхак:

– Минем бу эштән хәбәрем юктыр, – диде.

Хәлифә кызарды, тынычсызланды. Исхак бик каты курыкты: «Ходай кушмасын, хәлифәнең күңелеңнән «мин әйткән» дигән уй кичә күрмәсен», – дип уйлады. «Мондый эшнең һич булганы юк!» – дип ант эчте.

Кыз әйтте:

– Юк, барыбер уйнамый булмас!

Аннан голәмгә карады:

– Хуҗаңа әйт, безне затсызлардан санамасын, ул көйне безгә ишеттерсен! – диде. Голәм әйтте:

– Әй, хуҗам! Моннан хөрмәтле урын вә моннан яхшы падишаһ кайда бар? Һәрни боерсалар да шуны тотарга кирәк. «Бу эшне хәлифә ишетер», дип уйлама, ул фикереңне башыңнан чыгар, китсен. Ә инде кайда хәлифә бар, аңда күп сөйләмә, сакалыннан көлмә, өеңне яман көнгә салма, – диде.

Кыз бу сүзләрне ишеткәч, кычкырып көлде:

– Йөз-мең афәрин бу голәмгә, чиста күңел, чын буйсыну шулай булыр, – диде. Исхак голәмгә:

– Гомереңдә моның кебек оятлы булганың юк иде, – диде.

Голәм әйтте:

– Ул сүзне сөйләргә лаек түгел идем синеке булган чагымда, әмма бу мизгелдә ханымныкымын, синнән ул һич ким түгелдер, инде хәлифә бакчасында йөрмә, ханым боерыгын тот, – диде.

Ханым янә елмаеп куйды. Аннан Исхак шиштарны кулына алды, ул теләгән авазларны чыгарды, кыз сокланып тыңлап торды, күңеле булды, шәраб касәсен хуш исле гөләп белән тутырды, голәмгә сузды:

[3] Җам – касә, пыяла.

– Безнең күңелебез өчен бу җамны[3] тотып куегыз, – диде. Голәм ханымның кулын үпте, бу сөйкемлелек, бу матурлык, бу хуш сүзләр хәлифәнең күңеленә хуш килде.

Бераз вакыт үтте, хәлифәне шәраб алды, исерде. Бу урынның нинди урын икәне хәтереннән чыкты, гадәтенчә, Исхак янына килеп, тавышын күтәреп сөйләшә башлады. Исхак коллык күрсәтте, тешен кысып:

– Һай, шыпырт бул, аның җире түгелдер, – дип әйтте, булмады. Кыз бу хәлне күрде, белде: голәм – голәм түгелдер, хәлифәнең үзедер. Шундук урыныннан торды, башын каплады, карабашларына:

– Әдәп белән торыгыз, үземне үз кулым белән һәлак иттем, бу голәм түгел, хәлифәнең үзедер, – диде. Аннан аягөсте торып, әдәп белән хезмәт итте.

Хәлифә әйтте:

– И, ханым! Мин синең голәмең, шул тиеш иде: синең коллыгыңда торсам, әмма олылыгыңнан миңа утырырга рөхсәт иттең, шуның өчен утырдым, – диде. Ханым бу сүзне ишеткәч, елады:

– Йа әмире-л-мөэминин! Мин бичара гаурәткә син рәхим кыл, әдәпсезлегемне гафу ит, – диде. Хәлифә кызның аны таныганлыгын белде, кызны юатты, ягымлылык күрсәтте.

Аннары үз каршында Исхакны, кызны янында утыртып сөйләштеләр, гәпләштеләр, уен-көлке, шаярулар белән мәшгуль булдылар. Кыз һәрвакыт хәлифә иңенә баш куяр иде, хәлифә аны иркәләр иде.

Утырышу тәмам булгач, кыз ун данә эре энҗене бер күркәм рум[4] җариясенең муенына тагып, хәлифәгә бүләк итте…

– Әй, хөкемдар! Яшерен генә туры юлдан китегез, – диде.

– Мине монда ничек керттеләр, шулай чыгарсыннар, – диде Хәлифә көлеп.

Иртә белән хәлифә Исхакны чакыртты, килгәч, җариядән сорадылар:

– Ул өй нинди өй, ул-кыз нинди кыз, кемнең кызыдыр?

Җария әйтеп бирде. Белделәр, асылзат нәселдән икән, мәлик кызы икән. Шулвакыт хәлифә кызның иленә хәбәр күндерде. Кызны никах килешүе төзеп, алдылар, тиз арада сарайга китерделәр. Ул гөл йөзле кызның гүзәл чырае белән хәлифәнең күңеле хуш булды, шатланды. Ул кызның хисапсыз малы бар иде, тәмамын хәлифә өенә китерделәр.

Боларның соңында ул кыз Исхак Мосулине чакыртып алды:

– Синең минем өстемдә күп хакың бар, гомерем буенча һәркөн сиңа дөнья кадәр яхшылык кылсам да, күптән азык, меңнән берен итә алмам, мине мөэминнәрнең әмиренә, хезмәткә ирештерүгә сәбәпче син булдың, – диде. Боерды, Исхакка ун янчык кызыл алтын, ун кисәк парча, ун баш ат, ун баш качыр, ун баш җария, ун баш голәм бирде, «гафу ит», диде.

Хәлифә дә:

– Минем бу кәрәмәткә ирешүемә син сәбәпче, – дип, шулкадәр бүләкләр бирде ки – чиге юк. Ул ун данә энҗеләр белән бизәлгән рум җариясен дә аңа багышлады.

Күп заманнар бу дөньяны хуш кичтеләр, ахырда бу йорттан күчтеләр һәм бу хикәятне ядкяр итеп калдырдылар.

Хикәятне иҗат итүчегә, күчереп язучыга, укучыга вә тыңлаучыга афәрин булсын!

*Язманы **Нәҗип Нәккаш** әзерләде.* ■

---

[4] Рум — Византия.

Шагыйрә Газизә Бәһаветдин кызы Сәмидова

Җәвад Алмаз

Бу чактагы хәлен ул болай дип тасвирлый:

...Сач бауларын кабып, үкереп елый,
Буйкыз баралмаган тиңенә.
Еламачы, буйкыз, ябылып,
Кыз гомерләреңне сагынып.

Җилгә каршы болыт явалмый.
Буйкыз сәүгәненә баралмый.
Үсә-үсә кызлар зур була,
Үз тиңенә бармый хур була.

Шул ук 1882 елда Газизәнең бер кайгысы икегә әйләнә. Аның иң якын күргән ахирәт дусты – авылдашы Чилбикәне башка авылга иргә биреп җибәрәләр. Газизә Чилбикә дустын түбәндәге шигырь белән озатып кала:

Кил, дустым, таяныйм җилкәңә,
Син инде булмассың иртәгә.
Кызлар уйнап гомер итәдер,
Ят кулына елап китәдер.
Ел тик тоеладыр айлары,
Сыза йөрәгемнең майлары.
Сагынып, саргаеп бетәрмен,
Кайчан киләсеңне көтәрмен.

Янадыр йөрәгем ут кебек,
Йөримен акылым юк кебек, –

дип яза ул, ялгызлыгына хәсрәтләнеп.

Җан сөймәгән кеше белән яши торган гомернең авыр көннәре акрынлап үтеп тора. Аларның саны күбәйгән саен Газизә борынгы әдәби телгә ешрак мөрәҗәгать итә. Ул телнең бик борыннан эшкәртелеп килгән калыпларына, Ходайга сыгына башлый:

Илаһи, сән ганисән, бән фәкыйрәм.
Капуңда өлләре баглу әсирәм.

Башы журналның 3 нче санында.

Әстерхан өлкәсенең Ташлыяр авылында. Газизә Сәмитованың тууына 130 ел тулу уңаеннан Татарстаннан язучылар килгәч. Сулдан уңга: Зиннур Мансуров, Әхмәт Гадел һәм Хәбир Ибраһим. 1992 ел

Ягъни, «и Алла, син бай, мин ярлы, ишегең төбендә куллары бәйләнеп ташланган әсир мин», дип, үзен куллары бәйләнеп ташланган әсиргә охшата һәм ярдәм сорап Аллага ялына:

Гыймарәт әйдәгел күңлем сараен,
(күңелем сараен төзәт, ягъни туры юлга күндер, дигән сүз),
Эчергел җаныма хикмәт шәрабен.
Илаһи бән фәкыйрең кыйлма мәхрүм.
Рәхима! Рәхмәтеңдин әйлә мәрхүм
(рәхимле Алла, рәхмәтеңә ирештер, дигән сүз).

Бәнем кәби мәдәтсез бинәваи
Исеркәп, дәрдинә кыйлгыл дәваи
(Мин ярдәмчесез фәкыйрьне кызганып, дәртемә дару бир, дигән мәгънәдә).

Шагыйрә үзенең авыр хәленнән качарга урын эзли, ләкин таба алмый. Моны ул үзенең «гөнаһлары» күплегеннән күреп, тагын Аллага ялварырга тотына:

Гөнаһым күп, гөнаһымдин нитәем.
Гөнаһымдин качып кая китәем?
Качар ирдем, качарга җир табылмас.
Сәнең рәхмәт ишегең һич ябылмас.

Шул рәвешчә, Газизә берничә еллар буе Алладан ярдәм көтә. Ләкин көтелгән ярдәм килмәгәч, шагыйрә:

Икенде, ахшам, кичара
Морадын сорый бичара.
Морадын бирмәсә Алла,
Бичара колга ни кала? –

дип өметсезлеккә төшә. Хәзер инде ул җылый да алмаслык хәлгә килә. Шигырьләрендә булса суфизм үрнәге булган «Бакырган» китабының тәэсире сизелә башлый:

Кеме еглар, түгәр күз йаш,
Кеме гизлү, кемеси фаш.

Бәнем бәгърем улыпдур таш
Шәфәгать, йә рәсүлулла... –

юллары моңа мисал була ала. Газизә тагын бераз шул тормышында яшәсә, суфизм тәэсиренә төшәчәк, дөньядан ваз кичү юлына аяк басачак иде.

Татлы, дирләр вәхдәт йимеше
Ходаның нурыйлә пешкәнгә
(Алланы бер дип тану
җимешен татлы, диләр
Ходаның /үз/ нуры белән пешкәнгә), –

дигән юллар шагыйрә аңында моңа зәмин әзерләнә башлаганын белдерә. Ләкин иреккә омтылудагы көчле ихтыяр шагыйрәне бу бәхетсезлектән коткарып кала. Газизә аның өчен газапка әйләнгән гаиләви тормыштан котылыр өчен актык көчен җыеп, каһарманнарча бер талпына да, йөз еллар буе изге саналып килгән гадәт-йолага каршы баш күтәрә. Аңача татар дөньясында күренмәгән диярлек эшкә җөрьәт итеп, иреннән аерылуны таләп итә.

Ләкин ул чордагы шартлар моңа юл куймыйлар. Хатын-кызның теләгән кешесенә томышка чыгарга хакы булмаган шикелле, ирдән аерылырга да хокукы булмый. Ир хатынын теләсә аера, теләмәсә юк. Хатын аның колы. «Ир хакы – тәңре хакы», ди борынгы татар йоласы. Патша законы да шуны яклый. «Үтермим дә, төргезмим дә, аермыйм да, кеше дә итмим!» – диләр мондый чакларда хатыннарының үзләре белән тиң хокукка омтылуларына ачуланган усал ирләр. Шуңа күрә дә Газизәгә аерылуны таләп итү җиңел булмый. Бу кыю адымны ясарга Газизәне нәрсә мәҗбүр иткәне түбәндәге юллардан бик ачык күренә:

Ходавәндә, ходавәндә!
Бу гарип гамдә (кайгыда) һәркөндә.
Күземдә уйку (йокы) юк төндә.
Сабырлык бир, гани (бай) алла...
Бу яшь гомер зая үтте,
Сахрада искән җил кебек.
Бу хәсрәтә (хәсрәткә) бән саргайдым,
Сабындыйн сынган гөл кебек...

Мәңге шул хәлдә яшәргә кемнең түземе җитәр соң! Газизә унөч ел буена чыдый, ләкин һәрнәрсәнең чиге бар. Газизәнең дә сабырлыгы югала:

Авыр булса да күп түзем,
Йөрәгем бәгърен яндырдым.
Кеше хәтерләрен күреп,
Үз хәтеремне калдырдым... –

дип яза икенче шигырендә, чыдауның соңгы чигенә җиткән Газизә.

Аның әтисенә язган хаты кулъязмалар эчендә юк. Ул нинди формада язылгандыр – билгесез. Шунысы ачык, Газизәнең әтисе дә, әнисе дә бу көтелмәгән хәлдән башта аптырашта калалар. Ләкин Газизәнең хаты шулкадәр көчле, ышандыргыч, аерылу хакындагы таләп исә шуның кискен булган, күрәсең, ата кызын аерып алырга мәҗбүр була. Ләкин бу Газизә өлешенә генә тигән очраклы бер бәхет. Ул чорда Газизә хәленә төшкән татар хатыннары үлгәнче кайгы-хәсрәт эчендә изелеп яшиләр.

Ни булса да була, бу юлы Газизә җиңеп чыга. 1894 елда була бу хәл. Һәм башта ул Газизәнең тормышына шактый уңай тәэсир ясый. Зур кыенлыклар белән яулап алган иркеннән тулысынча файаланып калырга теләгәндәй, Газизә табигать кочагына ташлана: җәй көннәре пароход белән Идел буенда сәяхәттә йөрергә тотына. Пароходта барганда Кандалыйдан файдаланып язылган булса да, Дәрдемәнд шигырьләрен хәтерләтә торган:

Күңелдән китәрер өч нәрсә кайгу
Яшел чирәм, гүзәл хатын, агар су, –

дигән икелеге Газизәнең бу сәяхәтләрдән булган максатын күрсәтә. Табигать кочагында ул унөч ел буена туктаусыз канланып торган йөрәк яраларын төзәтергә тели. Кайгыларын таратыр өчен күп җирләргә бара, күп нәрсәләрне тамаша итә. Аның Шәһре-Болгар харәбәләрен барып күрүе һәм бу хакта калдырган кызыклы мәгълүматы шул чорга карый.

Шәхси иркенлек, сәяхәттә йөрү, аерата көрәштә җиңеп чыгу хисе Газизәнең рухын күтәрә, аны элекке хәленә китерә яза. Бу аның телендә дә сизелә. Шагыйрә борынгы төрки тел нормаларын ташлый һәм иҗатының башлангыч чалымга кайтып, халык җырлары калыбында язарга тотына. Шигырьләрендә исә шатлык аһәңе яңгырый башлый. Бер мисал:

Ишектән инәр үзе,
Коелыр кашы-күзе.
Нә галим егет үзе,
Бал, шәкәрдин татлы сүзе...

Бу шигырендә Газизә элекке туйларда җырлана торган халык җырларын җыеп, эшкәртә, аларны бер җепкә тезеп, яңа төсмердәге сюжет китереп чыгара да аңа «Туй бәете» дигән исемне бирә. Шигырь Газизәнең ул чактагы шатлыклы рухи хәлен көзгедәй күрсәтеп тора.

Газаплы тормыштан котылу шагыйрәгә җәмгыятьтәге башка күренешләргә дикъкать итәргә мөмкинлек ача, аның иҗат темасы да төрләнә башлый. Моңа түбәндә китереләчәк «Гыйлемнең кирәклеге», «Каләм» һәм сугышка багышланган шигырьләре мисал була ала.

Газизәнең күңел яралары уңалу белән бергә яшьлек хисләре дә кузгала. Ул үзенең җәберләнгән, хурланган яшьлеген онытырга, аны үзе теләгәнчә кичерергә омтылып карый. Аның түбәндәге җырлары шул хакта сөйлиләр:

Кызарып та кояш чыкканда
Кошлар талпынадыр очарга.
Сыйфатыңны ясап алыр идем,
Бик сагынган чакта кочарга.
Шәһре-Болгар дигән бер шәһәр бар
Илчеләре йөри тукталмый.
Мөбарак йөзләрен төштә күрдем,
Төннәр уртасында йокалмый, –

дип, Газизә яшьләрчә мәхәббәт ялкынында яна башлый.

Чәйләр яхшы шикәр, бал белән,
Йокы татлы сүгән яр белән, –

дигән юллар исә Газизәнең бу вакыттагы йөрәк омтылышын ачык күрсәтәләр. Ул үзенең сөйгәненә – беренче мәхәббәтенә ирешүдән әле һаман өметен өзми:

«Йосыф белән Зөләйха да
кавышканнар Мисырда.
Без дә шулай кавышырбыз,
икәү булсак бер сердә», –

дип, морадына ирешү юлында Зөләйха күргән кыенлыкларны кичерергә дә әзер тора.

Ахыры бар ■

ФАТИХ КӘРИМ: *әсәр, чор, язмыш*

Ренат Харис

Әдәби әсәр – язучы өчен Мактау тактасы да, хөкем карары да. Талантлы әсәр авторны йә үлемсез итә, йә заман, аның каршылыклы хәрәкәте, сәясәте йогынтысында авторына карата «павлик-морозов»ка әверелә. Моңа мисаллар дөнья әдәбияты тарихында байтак. «Павлик-морозов»ка әверелгән әсәрләр татар әдәбияты тарихында да бар. Кичә-өченче көн генә бернинди сәяси куркыныч тудырмаган әсәр вульгар социологизм шаукымы астында кинәт кенә үзенең «ата-аналарына» хәтәр ярлыклар тагарга, аларны хәтта ГУЛАГларга, гүргә илтеп тыгарга сәбәпче булган. Бу тенденция илебездә 1937-40 нчы елларга туры килгән репрессия чорыннан соң да дәвам иткән.

Мисал өчен 70 нче елларда Салих Баттал әсәрләрендә антипартиялелек, Хәсән Туфан (Искәндәр Рушан) шигырьләрендә антипатриотлык, Әмирхан Еникине патриархальлекне сагынуда гаепләргә тырышу очракларын искә төшерү дә җитә. Бәлки, бүген дә ул куркыныч бацилла, сәяси чүплектә күмелеп, кабат терелергә җай-уңай көтеп ятадыр. Ләкин бу бацилланың, үзеннән дә бигрәк, аны кузгатып җибәрә торган шартларга игътибар бирмәү куркынычрак. Бәгъзе бер сәяси-психологик шартларда усак яфрагын да селкетмәгән җил икенче шартларда агачларны тамырлары белән каерып ата торган давылга әверелүе ихтимал. Мондый үзгәреш-метаморфозалар сәясәтнең кискен борылыш ясаган, йә булмаса, чатнаган чакларына туры килә. Шуның өчен дә әдәбиятны, сәнгатьнең, кешегә каршы коралга әверелмәве өчен, асылда, сәясәттән өстен булуы хәерле.

Әсәрне автор өчен хөкем карарына әверелдерү ысуллары бик гади, һәм моңа татар әдәбиятындагы иң ачык мисал – Фатих Кәрим иҗаты һәм аның язмышы.

1929-30 елларда Фатих Кәрим 4 эпиграмма яза. Менә алар:

***

Хискә буаз,
Көйсез җырлар язып,
Мәгънәсен кысыр калдырып,
Демьян Фәтхи,
Ялгыз, Бишбалтада
Тальян уйнап йөри, каңгырып.

***

Фатих Хөсни безнең...
бик инсафлы,
Көче җитмәс җиргә үрелми,
Туган көннән бирле
Пыскып яна,
Төтен чыга, уты күренми.

***

Сирин шигрендәге
Энәләр
«Аришиннан мин», – дип киләләр,
Сирин, сизен,
Алай чәлдермә,
Барыбер, дим,

«...Аны суд гаепсез дип таба, азат итә. Шагыйрь Бөек Ватан сугышына тулы хокуклы гражданин буларак китә, взвод командиры була».

Беләләр...
Беләләр...
Беләләр!

***

Нур Баян, син
Мескен тавыкларны
Күп аунаттың инде чүплектә,
Язган шигрең элеп
Җилдә киптер,
Корсак күбә суы күплектән.

Фатих Кәрим бу эпиграммаларга дусларча тәнкыйть дип караган, һәм, дөрестән дә, алар шундый. 1937 елга кадәр бу «шаярулар» 7-8 ел буена беркемне дә борчымаганнар һәм онытыла язганнар. Ләкин репрессияләр башлангач, эпиграммаларның иҗтимагый-сәяси статуслары үзгәрә, һәм аларның берсе тора-бара Ф.Кәримнең әсәрләрен авторына карата «павлик-морозов» итәргә булыша.

Репрессиягә эләккән язучыларның төп гаепләре, гадәттә, төрле контрреволюцион оешмалар эшендә катнашу булса, Фатих Кәримне конкрет 3 әсәре өчен гаеплиләр. Менә 1939 елның 13-14 мартында булган суд карарыннан өзек: *«...Обвиняемый Каримов, будучи ещё в 1931 году сотрудником редакции газеты «Кзыл-Армеец» ... использовал советскую печать, оборонную литературу на пропаганду контрреволюционного национализма и восхвалению врагов народа: в одном из своих очерков он восхвалял врага народа Имангулова. (Сүз Беренче Татар полкы комиссары, Кызыл Байрак ордены кавалеры турында бара.)*

В 1929 году обв. Каримов написал произведение под названием «Кысыр Чячаклар» («Бесплодные цветы»), в котором наносит контрреволюционную клевету на Советскую власть и на комсомол и в другом произведении под названием «Аникин» клевещет на Красную Армию и её действительность...»

Фатих Кәрим «Кысыр чәчәкләр» поэмасының җитешмәгән якларын үзе

дә таный һәм моны башлап язучының иҗади тәҗрибәсезлеге белән аңлата, ләкин үзенең идеологик позициясен дөрес дип саный. Ә гаепләүнең үзәгендә 1936 елда язылган «Аникин» поэмасы була. Бу әсәргә сәяси һәм әхлаки бәя бирдертү өчен Татгосиздаттан Рахман Ильяс, Наркомпростан Гариф Гобәй, Язучылар союзыннан Нур Баян кергән комиссия төзелә. Комиссия мондый нәтиҗәгә килә: *«...поэма «Аникин» безусловно является антисоветской поэмой, т.к. она искажает социалистическую действительность и жизнь Красной Армии и клевещет на Красную Армию. По технической и художественной обработке своей она не отвечает требованиям советских читателей».* Судта хәлиткеч роль уйнаган бу документка Гариф Гобәй һәм Нур Баян кул куйган, ә Рахман Ильяс имза салмаган. Нур Баян 1938 елның 7 апрелендә сорау алу барышында тагын бер компромат өсти: *«Каримов, будучи редактором юношеской литературы Татгосиздата, выпустил детскую книгу «Ант» писателя Алиша с фашистской свастикой. А во втором издании – с двумя свастиками».* Гади иллюстрация китапның редакторын «халык дошманына» әверелдерә торган үтергеч дәлилгә әйләнә.

Экспертиза документының гыйбрәтле ягы – аның авторларының үз фикерләрен иезуитларча исбатлау ысуллары. Экспертлар

Карый Лиза,
Өй алдында бакча,
Бакчадагы сирень куагын
Җил селкетә, яфраклары шаулый,
Ул яфраклар көзен югалыр.
Югалырлар алар көзге җилдә,
Кошлар кебек ерак очарлар,
Кошлар кебек ерак очарлар,
Лиза калыр һаман бу илдә... –

дигән өзекне китерәләр дә, мондый нәтиҗә ясыйлар: *«Жена Аникина Лиза и их ребёнок живут ... одинокими, унывая и горюя. Из глаз Лизы беспрестанно текут слёзы, даже она сожалеет, что вынуждена жить в этой (советской) стране».*

Ә менә бу мисал тагы да гыйбрәтлерәк:

«Бер шигырь бар газетада:
«Соңгы теләгем –
Үлсәм, коммунист санагыз!» –
Дип язган Галим», –

дигән строфадан экспертлар мондый нәтиҗәгә киләләр: *«И в этих строках ясно писсимизм, запугивание молодёжи от пограничной службы, стремление обрисовать бойцов Красной Армии способными только на бесславную смерть...»* Менә тагын бер мисал:

«Урман тынган... тынган!
Тукран кунган... кунган!
Шакый, шакый да муенын сузып
Аска карый... карый!
Тукран күрә, агач төбендә
Кеше барын... барын!» –

дигән строфа экспертларга: *«Эти строки ясно показывают, что поэма сильно заражена формализмом, т.е. она далека от метода советской художественной литературы – от социалистического реализма»,* – дигән сәяси бәя бирергә нигез була. Әлбәттә, мондый «уяулыкның аргы ягына чыккан» бәяләрнең чын авторы Гариф Гобәй һәм Нур Баян түгел, ә репрессияләр психозы. Шуның өчен дә ул чорда төрле гаепләү документларына кул куйган кешеләр эзәрлекләнмәскә тиешләр. Ләкин шул ук вакытта шәхси факторны да инкарь итеп булмый. Шәхси фактор

Казан шәһәренең Совет районы хәрби комиссары полковник А.М.Груданов, 21 елдан соң, әлеге орденны шагыйрьнең хатыны Кадрия ханымга тапшыра. Тукай клубы. 11 май, 1966 ел

– һәр очракта да, һәр чорда да, хәтта бүген дә – көчен югалтмый торган психологик корал. Үлемнән курку, гомерен саклау – барлык җан иясенең табигый инстинкты. Ләкин кешене кеше иткән, аны хайванлык дәрәҗәсеннән адәми зат биеклегенә күтәргән намус, гөнаһ дигән субстанцияләр дә бар бит әле. Репрессияләр психозы ул елларда кайбер кешеләрдә хайвани инстинктны кузгаткан. Әнә шундый психоз ба-

Ф.Кәрим 1945 елның 19 февралендә Көнчыгыш Пруссиядәге соңгы сугышларның берсендә дошман пулясыннан һәлак була. Шул ук елның мартында аны I дәрәҗә Ватан Сугышы ордены белән бүләкләү карары чыга.

Фатих Кәримнең гыйбрәтле язмышы бүген дә безне – язучыларны да, галимнәрне дә, сәясәтчеләрне дә, хокук сакчыларын да – бер-беребезгә үтә дә сак булырга чакыра.

сымы астында хәтта әдәп сагында торырга тиешле әдипләр дә, Һарут һәм Марут фәрештәләр сыман, җәмгыять кереп баткан сәяси сазлыкка батарга, шуның пычрагына буялырга мәҗбүр булганнар. Моңа да конкрет мисаллар җитәрлек. Әйтик, Н.Исәнбәтнең үз теләге белән СССР Язучылар союзы секретаре В.Ставскийга 1937 елда язган хаты... (Ул хат «Гасырлар авазы» һәм «Татарстан» журналларында басылды).

Фатих Кәрим 1933-34 елларда Татгосиздатның яшьләр секторы редакторы булып эшләгәндә Ләбиб Гыйльминең «Чын мәхәббәт» дигән повестен редакцияләүдән баш тарта.

Һәм 1937 елның 29 мартында «Кызыл Татарстан» да һәм 2 апрельдә «Красная Татария»дә Ләбиб Гыйльминең мәкаләсе басылып чыга. Анда Фатих Кәрим *«пройдоха, подхалим, чужак, организатор групповых попоек, ярый защитник троцкиста Гумера Галиева, распространитель среди молодых писателей и поэтов антипартийных контрреволюционных идей...»* булуда, күренекле рус шагыйре, «троцкист» Павел Васильев белән дуслыкта гаепләнә. Ләбиб Гыйльми мәкаләсеннән соң, нидер сизенеп һәм үзен яклауны үтенеп, Ф.Кәрим Татарстан прокурорына гариза язарга мәҗбүр була. Ул газеталардагы гаепләүләрнең тузга язмаган абсурд булуларын прокурор да таныр, дип уйлый һәм гаризасын абсурд нәтиҗә чыгарып төгәлли: *«Значит, я враг народа и должен караться законом...»* Ләкин прокурор да сәяси психоз йогынтысында булып чыга: 1937 елның 30 декабрендә Фатих Кәрим, «халык дошманы» дигән ярлык тагылып, кулга алына.

Шагыйрьнең 1939 елның 12 июнендә Беренче номерлы Казан төрмәсеннән СССР Верховный прокурорына язган шикаятендә мондый аңлатма бар: *«Гильманов имел со мной личные счёты, а именно за то, что я не раз выступал на собраниях писателей, критикуя его ленивость, что он малограмотен не только литературно, но и элементарно, исправление своих произведений всегда сваливает на плечи работников редакции... Это может подтвердить любой татарский писатель. Я, будучи редактором юношеского сектора Таткнигоиздата, отказался от редактирования его повести «Искренняя любовь» и поставил вопрос, чтобы не издавать эту халтуру-плагиат... Эту книгу Гильманова писательская общественность оценила так же как и я, и книгу изъяли»*. Бу әсәр 1936 елда, нык төзәтелеп, нәшер ителә, ләкин үпкә басылмый.

Суд документларында сәяси психозның башка яклары да ачык күренә: язучылар бер-берләреннән читләшкәннәр, аларны куркыну, шикләнү киртәсе аерып куйган, көнләшү, форсаттан файдаланып, үч алырга тырышу намустан, әхлак нормаларыннан өскәрәк чыккан. Берәү Ф.Кәримне «писал с вредной целью» (И.Гази), дип бәяләгән, икенчесе «Ф.Карим был связан в Ленинграде с каким-то Корниловым, который враг народа», «Павел Васильев обещал перевести стихи Ф.Карима на русский язык» (Х.Туфан),

дип өстәгән, өченчесе шагыйрьне язучылар арасында «в Советском Союзе без партбилета таланта не проявишь» (Л.Гыйльми) дигән гайбәт таратуда гаепләп, бата башлаган иң талантлы каләмдәшләрен тирәнрәк батырышканнар. Шулай итеп, бер-береңне күрә алмау, көнләшү сәяси психоз чорында үч алу коралына әверелгән һәм милли мәдәниятебезгә, әдәбиятыбызга коточкыч зыян салган.

Сәяси психоз синдромы үткән гасырның туксанынчы еллары башында, Советлар Союзы таркалган вакытта, «суверенитетлар парады» дигән чорда да үзен тагын бер мәртәбә сиздереп алды, вульгар социологизм бациллаларына җан өрергә тырышты: Ленинга, партиягә, коммунизмга багышланган әсәрләрне һәм аларның авторларын барлау башланды, Россиянең, СССРның мактаулы исемнәрен йөрткән кешеләргә кырынрак карау, аларны күрмәмешкә салышу, элек ак булганны кара итеп, ә караны сөттән дә пакъ итеп күрсәтү очраклары барлыкка килде. Хәтта төс-буяуларны идеологияләштерүләр, динне, татар телен кешене бәяләүнең иң мөһим бизмәне итәргә омтылулар да булмады түгел. Ләкин, бәхеткә, вульгар социологизм куәт җыя алмады, һәм бу омтылышлар афәткә әверелми калдылар.

Бүген дә, бөтендөнья икътисади кризисына бәйле рәвештә, сәясәт кискен хәрәкәтләр ясый. Без аның авыр адымнарын күрәбез, нәрсәләр сытылганын ишетәбез, йөрәгебезгә шик-шөбһә урнашуын сизенәбез. Әдәбият-сәнгать әһелләренең матди хәлләре дә, рухи хәлләре мактанырлык түгел. Төшенкелеккә, өмет өзелүгә дә ерак калмады булса кирәк. Шәхси факторның кабат әхлак чикләрен җимерүе ихтимал. Ләкин бу киеренкелек сәяси психозга әверелмәс дип ышанасы килә.

Кыскасы, Фатих Кәримнең гыйбрәтле язмышы бүген дә безне – язучыларны да, галимнәрне дә, сәясәтчеләрне дә, хокук сакчыларын да – бер беребезгә үтә дә сак булырга чакыра.

***

Матбугатта Ф.Кәрим сугыш вакытында штрафбатта була, дигән ялган фикер очрый башлады. Х.Туфанга багышланган документаль телевизион тапшыруда Роберт Мөхлисович Батулла да шушы фикерне кабатлады. Штрафбатта булу – суд тарафыннан акланмаган җинаятьче-уголовник дигән сүз. Штрафной батальоннарга уголовникларны гына җибәргәннәр. Ә Ф.Кәрим – сәяси тоткын була һәм аны суд гаепсез дип таба, азат итә. Шагыйрь Бөек Ватан сугышына тулы хокуклы гражданин буларак китә, взвод командиры була. Әлбәттә, Р.Батулла бу фикерне Ф.Кәримнең язмышын тагы да драматиклаштыру өчен әйткән булса кирәк. Ләкин мондый һәм моңа охшашлы төгәлсезлекләр, абруйлы язучы тарафыннан сөйләнсә – бигрәк тә, сугышчы шагыйрь рухын кимсетә, аның җәмгыяви образын боза. Бу дөреслеккә туры килмәгән ялган яңалык, һичшиксез, Ф.Кәримгә карата саксызлык мисалы булып саналырга тиештер.

Редакциядән: *Күренекле шагыйрь, публицист, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Ренат Мәгъсүм улы ХАРИСОВка (Ренат Харис) 6 майда 75 яшь тула. Аны шушы күркәм гомер бәйрәме белән ихлас котлыйбыз, сәламәтлек, иҗади уңышлар телибез.* ■

ҮТКӘННӘН ХАТЛАР

ГАРИФ АХУНОВТАН – АФЗАЛ ШАМОВКА

«Исәнмесез, Афзал абый!

Сезгә Әлмәттә яшәүче әдипләрдән сагынычлы кайнар сәлам. Язган хатыгыз һәм командировка өчен дип җибәрткән акчагыз өчен бик зур рәхмәт. Мин инде, Союзның җае булмады бугай ахрысы, дип, газеталар өчен кечерәк парчалар язарга утырган идем. Шул сәбәпле роман (сүз «Хәзинә» турында бара, ахрысы. *– Л.Л.) бераз туктап торган иде. Сездән акча килүгә, шатланып, тагын шуңа тотындым. Инде менә машинкада яртысын басып та бетердем. Июль ахырына бөтенләе белән басып бетереп, Казанга алып барам. Анда ничегрәк булыр икән? Проза секциясенең берәр кешесе өйдәме, әллә барысы ялга китеп беттеләрме? Мин Казанда торган чакта җәен язучылар ялга китеп бетә торган иде.*

Исәнмесез, Афзал абый!
... яшәүче әдипләрдән сагынычлы сәлам. Язган хаты-
...дировка өчен дип җибәрткән акчагыз өчен бик зур
...нде, Союзның җае булмады бугай ахрысы, дип, га-
...кечрәк парчалар язарга утырган ...

-2 -
...әр өскә калкып чыкты? Язучылар Союзы ...
...елыш үткәрдеме, үткәрергә җыенамы? ...
...н сөйләшүнең стенаграммасын укырга ...
...тиянең артта калуы турында шактый хәв...
... матбугатта. Киңәшмәдән соң Идарә драм...
...енча нindирәк чаралар күрә?
...р безне борчып тора.
...и берләшмәсе- Язучылар Союзының аерыл...
... Берләшмәнең эшен тагын да җанлырак,
Союзның нинди киңәшләре, күрсәтмәләре ...
...хушыгыз. Эшегездә уңышлар,
... сәламәтлек телим:

Гариф Ахунов

...барлык иптәшләргә сәлам әйтегез.

5.VII.1961
Әлмәт.

Афзал Шамов

Минем килеп йөрүем файдалы булырмы, юкмы, шуны әйтеп язып языгыз әле, зинһар.

Беләсе килгән тагын башка нәрсәләр дә бар. Партия өлкә комитетында язучылар белән киңәшмә үткәрелгән икән. Прозаиклар белән шагыйрьләрне чакырганнар, дип ишеттек. Моннан берәр ай элек драматургларны чакырулары турында, «Бүгенге көн һәм поэзия» дигән темага сөйләшү үткәрелүе турында хәбәр булган иде. Газеталарда язуларына һәм шул киңәшмәләрдә катнашкан иптәшләрнең бер-ике сүз белән хәбәр итүләренә караганда, киңәшмәләрнең һәркайсы бик кызыклы үткән икән.

Үзегезгә мәгълүм булганча, безнең нефть районнарында актив эшләүче йөзгә якын яшь язучы бар бит инде. Әнә шул яшьләр Әдәби берләшмә бюросыннан, ягъни Әдиптән, Рафаилдан һәм миннән сорыйлар:

– Язучылар союзы идарәсе иптәш Хрущев мәкаләсеннән соң нинди конкрет чаралар билгеләде? Нишләп безгә шуны аңлатмыйсыз? – диләр. Әнә шул чаралар белән якыннан таныш булмаганлыктан, без аларга җавап бирергә кыенсыныбрак калдык.

Афзал абый, сөйләшү нәтиҗәсендә бүген эшләнәсе, кичектергесез нинди эшләр өскә калкып чыкты? Язучылар союзы моның буенча зуррак җыелыш үткәрдеме, үткәрергә җыенамы? Өлкә комитетында булган сөйләшүнең стенограммасын укырга мөмкин түгелме? Драматургиянең артта калуы турында шактый хәвефле хәбәрләр әйтелә матбугатта. Киңәшмәдән соң Идарә драматургияне үстерү буенча ниндирәк чаралар күрә?

Бу сораулар безне борчып тора.

Әлмәт әдәби берләшмәсе – Язучылар союзының аерылгысыз кисәге бит инде. Берләшмәнең эшен тагын да җанлырак, файдалырак итү өчен Союзның нинди киңәшләре, күрсәтмәләре булыр.

Хәзергә хушыгыз.Эшегездә уңышлар, Үзегезгә сәламәтлек телим: Гариф Ахунов.

R.S. *Безне сораган барлык иптәшләргә сәлам әйтегез.*

5 июль, 1961 ел.»

Искәрмә: ахырдан кемдер «Җавап язылды.10.07.61» дип язып, имза куйган.

*Хатны **Ләбиб Лерон** укыды.* ■

Язгы хатирәләр

Клара Булатова
(Көндәлектән)

7 март, 1993 ел, якшәмбе

Кичәге көннән бирле хатын-кызлар бәйрәме бара. Хәер, ул бәйрәм өченче көн үк башланды.

5 мартта гимназиядә иртән шәкертләр котлавы булды. Аларга котлау сценариен үзем язып биргән идем. Рәхмәт аларга!

Көндезгә сәгать уникедә Язучылар бүлеге бәйрәм итте: бер бөртек хатын-кыз язучылары янына бүлектә эшләүче Гөлнара белән Нәфисәне дә кушып. Бәйрәм тантанасына элек бүлектә бухгалтер һәм секретарь вазифасын алып барган Сабира, җыештыручы булып эшләгән Якут апа һәм Үзбәк Саттаровның тол хатыны Извилия дә чакырылган иде.

Кичен драмтеатр бинасында район-шәһәр күләмендә зур тантана уздырылды. Андагы тәбрикләү өлешендә безнең гимназия шәкертләре дә чыгыш ясады. Башта түбәтәйле җиде малай шигъри кереш сүз әйтте. Аннан соң безнең 14 кыз баладан торган «Күбәләк ансамбле «Мин кояшны яратам» дигән җыр башкарды:

Бүген бәйрәм – сезнең бәйрәм,
Сезгә җырлый кошлар да.
Без дә килдек сезне язгы
Бәйрәм белән котларга...

Композитор Роберт Андреев минем сүзләргә язган бер яңа җырын – «Су буенда кыяк үлән»не җырлады. «Татнефть»нең генераль директоры да котлау чыгышында мине мактап телгә алды, рәхмәт төшкере. Тантаналы өлештән соң «Дүрт әби һәм Әхмәди» дигән спектакль күрсәтелергә тиеш иде дә, анысына кала алмадым. «Җомга»да Кичүчатны чыгарырга тиеш идек, шуны карарга дип, кайтып китәргә туры килде.

12 март, җомга

Өченче көн 10 нчы мәктәптә укучылар белән очрашуда булган идек. Язучылардан, миннән кала, Нур Әхмәдиев, Фәрит Гыйльми һәм Илдар Хөсни катнашты. Мәктәптә бик нык әзерләнгәннәр. Венера Виккулова (Тәгъзимә апа кызы) зур тырышлык куйган. Афәрин!

Кичә үземнең «Шигърият» түгәрәгенең чыгышын радиога яздырып кайттым. Бүген эфирга чыгарга тиеш. Тыңлаучылар ничек бәяләр, болай матур әйбер үзе. Ринат Мөхәммәдиевкә хат яздым, машина турында. Ни дә булса хәл итәргә тиешләрдер бит инде, йа Рабби!

15 март, дүшәмбе

Иртәгә 2 нче китапханәдә милли китапханә ачылу бәйрәме булырга тиеш. Тамара Халитова (китапханәләрнең шәһәркүләм хуҗабикәсе) шылтыратты, шул бәйрәмгә чакырды. Ай-һай, барулары ничек булыр? Авырып торам. Грипп әйләнеп килде. Марс улым үзебезнең «Әлмәт таңнары»на Нәүрүзгә багышланган шигыремне илтеп кайтты. Инде мөгаен, утыз еллык уңаеннан, хатирәләр язарга тотынырга дыр?! Өлкәм матбугатына соңардым бугай инде. Әлмәтнекенә, бәлки, өлгертермен.

27 март, шимбә

Узган атна бик тыгыз булды.

«Казан утлары»ның 3 нче саны Әлмәт язучылары иҗатына багышланган. Юбилей уңаеннан инде. Юбилейга Гариф Ахунов, Марсель Галиев, Гәрәй Рәхим, Мансур Шиһапов, Әхәт Гаффар, Флёра Гыйззәтуллина килгән иде. Җәүдәт Дәрзаман, Рәшит Әхмәтҗаннар күренмәде.

Бер күрәсе килгән иде шуны:

«Әлмәт, синең җирең иде ул...»
Ник кайтмады икән, дияр идем,
Ул шул Рәшит түгел инде ул.
Ясмин куаклары арасында
Мине көткән шагыйрь юктыр шул.
Сүзләре дә хәзер салкын инде,
Карашы да авыр, ныктыр шул... ■

Үтеруче

З.Ишаев

Бик күп заманнан бирле инде, хәтта ак сакаллы картлар да «Т» авылында урлау булганын ишеткәннәре юк иде. Күрше авылларда аз булса да бу гөнаһ була, ә «Т» авылы халкы бөтенләй урлауның нәрсә икәнен белми, хәтта келәтләрне бикләргә хаҗәт төшмәгәнгә, йозакларның да кайда сатылганын белми иде.

Менә бервакыт шул «Т» авылында моңа кадәр ишетелмәгән бер хәбәр тарала: бер йортта төнлә бер тавык, икенче йортта ике тавык, тагы кемнеңдер өч тавыгы югалган.

Хатыннар тәмам шашалар, ирләренә баш оралар. Ирләренең анда эшләре дә юк: «Тавык зур нәрсәмени? Бәлки үзләре качып киткәннәрдер», – диләр. Югалу моның белән генә туктамый. Көннән көн абыстайларның, яшь килен, карткорыларның тавыклары кими бара.

Хатыннар түзмиләр, беркөнне авылларына старшина килгәч, старшинага баш оралар.

– Кемнән шикләнәсез? Әйтегез! Үземнең туганым булса да, кызганачак түгелмен. Тик тугрысын гына әйтегез, – ди старшина.

Халык колагын торгыза. Угрыны табарга тырышалар. Ләкин бер файда да чыгара алмыйлар. Тавыклар һаман югала. Эзен һич табарга мөмкин түгел. Күрәсең, бик оста кеше урлый торгандыр. Бер-ике елдан соң тавыклар гына түгел, абзардан сарыклар да югала башлый. Бераздан соң хәбәрләр тагы күбәя: фәлән йорттан ат урланган, фәләннең бер үгезе, икенче кешенең бер сыеры юк. Әллә ничек югалалар? Бары йорттан гына чыгып өлгерсен, аннан соң мәңге дә таба алмассың.

Югалган мал хуҗалары төрле җиргә барып карыйлар, сораштыралар. Юк та юк. Әллә кая, гүя суга батканнар.

Авылда тагын бер кешедән дә шикләнерлек түгел. Һәммәсе дә тугры, эшчән халык.

Күрәзәләргә дә барып карыйлар. Алар да: «Читтән килеп урлыйлар, җирән кеше икән. Башта ул кеше һәммәңезне дә йоклата да, аннан соң теләгәнчә эш эшли», – диләр.

Билгеле инде, мондый кешене бернәрсә дә эшләтеп булмый. Бары бер нәрсә генә кала – кайгыру да, тик тору.

Һәм халык эндәшми. Ләкин анда карак үз эшен һаман эшли. Ә Сабир агай бөтенләй бөлде: актык үгезләрен алып киттеләр. Анда Сәйфи агай бердәнбер алашасыннан мәхрүм булып кала. Бервакыт, Вәли агайның бөтен кошларын кетәктән алып киткәннәр, дигән хәбәр тарала. Явызлар астан казып кергәннәр дә, кошларның һәммәсен дә алып киткәннәр. Ичмасам, нәсел өчен дә калдырмаганнар.

Авыл халкы мир җыенына җыела. Ләкин ни эшләсеннәр? Һәркем көн

З.Ишаев. Үтеруче. Хикәя (русчадан үзгәртелде). Нашире: Г.Гобәйдулла. – Казань: Электро-Тип. «МААРИФЪ», 1914. – 36 б.

саен үзенә көтелмәгән кунакның килүен көтеп кенә тора. Аңар каршы бер чара да эшләрлек түгел. Бу тугрыда староста-лар түгел, атна саен килеп китә торган старшина да тәмам аптырый: «Миңа каракны гына тотып бирегез! Мин аны... Мин аны... Ул минем аркада төрмәдә черер», – ди.

Халык: «Шулаен шулай... Аның кем икәнен белсәк, без тотар идек тә... Ләкин аны кайдан табасың соң?», – ди.

Менә бервакыт халык арасыннан Каюм исемле бер егет чыга да:

– Әгәр рөхсәт итсәләр, бөтен йортларны тентеп чыгар идек. Монда чит кеше эше түгел икәнлеге үзеннән-үзе күренеп тора. Безнең үземездән кем булса да бу эшне эшлидер, – ди.

Халык:

– Чыннан да, ул бит бик дөрестен әйтә. Старшина хәзрәтләре! Рөхсәт итегез йортларны тентергә! Бу эшне үз өстегезгә алсагыз, бигрәк яхшы.

Старшина:

– Бу эшне эшләр өчен Каюмның үзеннән артык кеше табылмас. Ул уйлап чыгарды һәм үзе эшләсен дә. Үзенә иптәшкә берничә кешене алсын да, тентесен!

Каюм:

– Бәлки миңа ышанмаслар...

Халык (беравыздан):

– Ничек алай сиңа ышанмаска? Сиңа ышанмасак, кемгә генә ышанырга кала?

Чынлап та, Каюмга ышанмаслыкмы соң? Каюм соң нинди егет! Дөрест, ул

ятим, аның атасы юк. Ләкин ул малай гына иде әле, шулай да аңардан башлы кеше чыгачагы күренеп тора иде. Ул, киенеп, авыл буенча йөри башласа, һәммә кешенең исен җибәрә иде.

Ул һәрвакыт акчалы, һәрвакыт шәһәрдән төрле бүләкләр, кесә тулы акча алып кайта, тәмам бояр төсле киенә иде. Үзенең карт анасына да һәрвакыт күчтәнәч, бүләкләр алып кайта, һәрвакыт анасын хөрмәтли иде. Үткерлек, тапкырлык, сүзгә осталык дисәң, аңардан да артыкны табу мөмкин түгел иде. Кичке җыелышларда, йөрешләрдә дисеңме, ул беренче урында тора, үзе бернәрсәдән дә курыкмый, җиде төн уртасында зиратка бара иде. Аның иң курыккан нәрсәсе – бары этләр генә иде. Әмма соң ул этләрне яратмый да иде. Авылда бер усал эт күрде исә, күпме акча сорасалар да, аны асмыйча куймый иде. «Нигә алай итәсең?» – дияләр. «Юк, мин этләрне яратмыйм, минем аларны күрәсем дә килми. Күрәсең, минем гадәт шундыйдыр...» – ди торган иде.

Гакыл җәһәтеннән Каюмнан да артык кеше юк, авылдагы иң картлар, нинди башлы кешеләр дә, аның белән җиңешә алмыйлар иде. Кайвакыт ул мир җыенына да килә, инде мир җыенына кергәч тә, халык кычкырышкан вакытта бер сүз яисә бер киңәш бирсә, һәммә халыкның исе китә, аның сүзе кабул ителә, халык та аптырашып ни әйтергә белмичә: «Менә безгә кем старшина булырга тиеш!» – диләр иде.

Шулай булгач, Каюмга ничек ышанмаска? Ничек аңарга тентү эшен тапшырмаска? Ул тугрыда уйлап та торасы юк. Шуның өчен халык беравыздан Каюмнан бу эшне үз өстенә алуын, үзенә иптәшкә берничә ышанычлы егет сайлавын һәм бөтен йортны тентеп чыгуын үтенделәр. Каюм риза булды. Үзенә ярдәмчеләр алып:

– Әйдәңез, минем йорттан башлыйк! – диеп эшкә башлады.

Егетләр:

– Ничек алай синең йорттан? Синнән болай да бер кеше дә шикләнми!

Каюм:

– Юк, иптәшләр, монда мин генә калырга тиеш түгел, тентергә булгач, тентергә... Бер йорт та калмасын. Мине генә калдырырга, мин бит бер падишаһ түгел. Караңыз, тентеңез! Бәлки берәр нәрсә табарсыз, – диде. Үзе башындагы карпу бүреген кырын салып, бөеренә таянып, бик эре генә теш арасыннан төкерде.

Егетләр Каюм артыннан аның йортын тентергә киттеләр. Аның йортын тентеп тә, бернәрсә дә тапмагач, икенче йортларга керделәр. Каюм бер җирне дә калдырмый: өй, сарай, лапас, келәт дисеңме, кар базы дисеңме, барысын да карый, бары җиде кат җир астына гына керә алмый, керә алса, аны да тентер иде.

Каюмның үз йортында бернәрсә дә табылмаса да, башка йортларда алай булмады. Бер йортның чардагында бер билбау табылды. Каюм билбауны шунда торучы бер агайга күрсәткән иде, агай: «Менә сиңа кирәк булса, бу бит минем билбау, минем генә түгел әле, атамнан калган билбау», – диеп, шатланып, Каюмнан тагы ныграк тентүен үтенде. Тентү алга барган саен урланган нәрсәләр күп табыла башлады һәм һәрвакыт ул нәрсәләрне Каюм үзе таба иде. Ул урланган нәрсәләр табылган һәр йортта шул йортның хуҗасын, хатыны, бала-чагасын каравылга алырга куша бара иде.

Тентү тәмам булгач, каравылга алынган кешеләрдән сорау башланды. Ләкин тотылганнарның һәркаюсы: «Белмимез дә, ишеткәнемез дә юк. Ул вакыт минем өйдә юклыкны һәммәңез дә белә иде бит. Әлхәмделилла, туганнан бирле андый начар эш белән маташканым юк», – диделәр.

Каюм аларның сүзенә каршы:

– Чардакта билбау яисә берәр нәрсәнең табылуы гаҗәп эшмени? Бәлки шул ук карак үзе, үзен җуар өчен урлагандыр да, кеше йортына яисә өй түбәсенә ташлап киткәндер? Караңыз картлар, кешене нахак гаепли күрмәңез!

Старшина:

– Дөрест, дөрест! Җибәреңез бу кешеләрне! Алар гөнаһсызлар! Икенче кешенең ташлавы да бик мөмкин шул. Ну Каюм! Мин никадәр уйлап карадым, аксакаллар белән дә киңәштем, минем башыма шундый уй килмәде! Һәм дөрест тә, бу Каюм сезгә старшина булачак...

Каюм яңадан бер-ике көн «Т» авылында йөреп, үзен халыкка күрсәтеп, халыкның исен китәргәч, эшкә диеп авылдан яңадан чыгып китте.

Халык: карты, яше, баласы-чагасы – һәммәсе берьюлы аның киткәненә бик үкенеп калдылар.

***

– Ах, бәхетсез балам, бәхетсез Ягъкуб! Сиңа Хода бәхетне бирмәде инде! – тол калган Гарифә карчык үзенең угылына шулай диде. Аның угылы Ягъкуб күптән түгел генә шәһәргә эшкә диеп барып, ике атнадан соң, бөтен киемен сатып, чак-чак кына авылына кайтып җиткән иде.

– Ни эшлисең соң, әни? Мин үзем дә бәхетсез икәнемне беләм, тәннән тир түгел, кан чыкканчы эшләп карыйм, тәмам хәлдән таям, байлар минем ябык тәнемә карап, мине бик көчлек белән генә яллыйлар. Ялласалар да, башкаларга караганда ким хак бирәләр. Тырышып та карыйм, анысын ярышып булмый инде. Ялкаулыкның нәрсә икәнен дә белмим, кайвакыт башкалардан артык та эшлим, һаман да искечә шул – хуҗалар миңа һаман да бер күз белән карыйлар.

– Берәр нәрсә уйларга кирәк инде, угылым! Бүтән кешеләргә кара! Алардан киңәш сора! Кайда барырга, кайда эш яхшырак, диген! Әнә Каюмнан сорап кара! Аның белмәгән нәрсәсе юк. Бар нәрсә дә аңа энәсеннән җебенә кадәр билгеле. Ничек эшли тагын! Аның анасы кем иде соң? Миннән фәкыйрьрәк иде, хәзер инде кара: бер бояр хатыны диярсең, якын барырга куркырсың. Каюмның үзе дисәң, бәйрәм көннәрне ничек киенә! Безнең писер дә аның белән җиңешә алмый. Аңарга киңәш итеп кара әле, бәлки берәр файдалы киңәш бирер, яисә үзе белән бергә алып китәр.

– Мин аңардан сораштыргаладым инде, әни. Үзең белән бергә алып кит, диеп ялынып та карадым. Бергә эшләрмез, син ничек, мин шулай, синнән бер илле дә калышмам, дидем.

– Соң, ни ди?

– Минем ялынганны күргәч тә миңа күзен акайтты.

Күзләре ут шикелле яна, йөзе ап-ак булды, бик озак карап торганнан соң, көчкә генә җавап кайтарды:

– Ничек эшләргә аптырыйсың икән, – ди, мин ни эшлим, син дә шулай эшлә – баерсың, ди. Миңа иптәш кирәк түгел, үзең теләсәң кая бар, ди. Шуннан соң минем яннан бик тиз китте. Яңадан әгәр бергә очрашырга тугры килсә, ул һәрвакыт минем күземә карый башлады. Мин аның белән сөйләшә башласам, миннән кача башлады. Юк, ул миңа иш түгел. Ул бай, ул грубиян. Калага барсам, ни эшләр икән? Анда бәхет очрамас микән, әни?

– И угылым, шулкадәр ераккамы? Йөз чакрым бит! Мине һәм хатыныңны, балаңны кемгә калдырып китәсең соң? Тагы син үзең кая чаклы бара аласың? Беләсеңме, ул бит кала дигән нәрсә җирнең аргы читендәдер?

– Ни булса да булыр, әни. Актык мәртәбә омтылып карыйм әле. Анда эш

уңайлы чыкмаса, аннан соң беркайда бармам.

Гарифә карчык ифрат кайгырды, елады. Ләкин нишләсен, угылын ерак юлга озатырга риза булды.

***

Калада бу вакыт ярминкә башланганы, ярминкәгә бик күп сатучылар килгәнлеге, күп товар ташылганлыгы, эшчеләрнең күп кирәклеге һәм аларга эш хакының да күтәренке булганлыгы ишетелгән иде.

Ягъкуб, әнисе, хатыны, бала-чагасы белән саубуллашып, юлга чыгып китте һәм өч көннән соң исән-сау шәһәргә барып керде. Ярминкә кайда булганлыгын сорашып, ярминкәгә килде. Ярминкәдә халыкның очы-кырые да юк иде. Ягъкуб халык арасыннан кысыла-кысыла эчкә керә башлады. Ләкин нигә кергәнен үзе дә белми иде. Бервакыт кинәт кенә кемдер аның терсәгенә төртеп: «Әй, егет, эш эзлисеңме?» – диеп сорады. Ягъкуб артына әйләнеп карады. Бер купес тора. Купес яхшы сукно казакиларга киенгән, башында каракүл бүрек. Ягъкуб кулын баш орып, куркып кына: «Эзлим абый, эш эзлим, Ходай берәр яхшы хуҗа табып бирмәс микән, диеп йөрим».

Купес:

– Син тугры кешеме соң? Берәр эшсез, ялкау түгелме?

Ягъкуб:

– Юк, абый, бервакытта да начарлык эшләгәнем юк. Хәтта уема да килгәне юк. Эш тугрысына килсәк, ул хакта үзеңез күрерсез.

Купес:

– Йә, ярый, алай булса, әйдә минем арттан.

Купес Ягъкубны үз фатирына китерде. Анда йорт эчендә төрле товар һәм әрҗәләр төягән йөкләр тора иде.

Хуҗа Ягъкубка:

– Кара, энем! Менә монда ямщиклар килер, шул товарларны ярминкәгә минем кибетемә илтсеннәр. Син һәрвакыт алар янында тор! Алардан бер табан да читкә китмә. Менә сиңа иптәш тә...

Ягъкуб иптәшенә карады. Ни күрсен, алдында Каюм тора. Ләкин Каюм әүвәлге кеби купшы түгел, өстендә киеме начар, билен җеп белән буган, башында бүреге дә тәмам тетелеп беткән иде.

Ягъкуб:

– Исәнме әле, иптәш Каюм? Ничек монда килеп эләктең?

Каюм:

– Ничек булсын? Синең бит туганнан бирле монда килгәнең юк, шулай да син килеп эләккәнсең. Ә миңа беренче кат кына түгел инде.

Ике авылдаш арасында сүз пешмәде. Ягъкуб Каюмнан бик күп сорый. Каюм исә бер йә ике сүз әйтә дә читкә борыла, йә ишетмәгәнгә салына иде. Ягъкуб уйлыйдыр, беләм, ул монда бигрәк эреләнә: юри ярлыга салынып, кыйммәт алырга тырыша, шуңа күрә ул хәйләкәр дә.

Хуҗа боларның авылдаш икәнен белгәч, тәмам шатланды һәм аларга тиешле әмерләрне биреп, бәһа тугрысында бернәрсә дә әйтмичә, өенә китте. Хуҗа киткәч, Ягъкуб бераз кайгырды һәм Каюмнан нишләргә кирәк, диеп сорады.

Каюм:

– Чурт беләме? Әгәр начар хак бирсә, без үземез дә ни эшләргә белермез. Син бары миннән калышма гына, һәрвакыт миңа буйсын. Мин кушканча гына йөре! Аннан соң мәңгегә җитәрлек акча табармыз.

Мондый сүзләрне ишетеп, Ягъкуб бераз гаҗәпләнде: «Бу Каюм ниндидер бер кызык, кеше аңламаслык нәрсә сөйли», – диеп бераз аптыраса да, күп тә үтми тынычланды. Соңра товарларны карап чыкты. Озак та тормый ямщиклар килеп җитеп, товарны ярминкәгә алып

киттеләр. Ярминкәгә хуҗа да килде. Кибетне ачып, товарларны киштәләргә тезәргә кушты. Товарларны чишә башлагач, Ягъкуб тәмам аптырады: нинди товарлар! Алтын да көмеш, простой, очсызлы бернәрсә дә юк! Тирә-ягында ялтырап торган алтын-көмешне күргәч, Ягъкубның тыны кысылды.

Ямщиклар товарны һаман әрҗәләрдән чыгаралар, хуҗага бирәләр. Хуҗа товарларны үзе җиренә урнаштыра бара. Ягъкуб товарга тотынырга курыкты. Каюм исә, һич илтифатсыз, кыйммәтле алтын нәрсәләрне алып, бер дә исе китмичә, аны кулында бәһасен үлчәгән шикелле үлчәп карый иде.

Хуҗа күбрәк Каюмга ышана иде. Чөнки бер караштан ук Каюмның булдыклы икәнлеге, мондый товарны берничә рәт күргәнлеге беленеп тора иде. Ягъкуб исә, яңа, һичнәрсә күрмәгән кеше булганга, булдыксыз һәм җыйнаксыз күренә иде.

Эш бетте. Товарларны кибеткә тезеп куйдылар. Хуҗа Каюмга йозакның ничек бикләнгәнен күрсәтте. Йозак ифрат серле иде. Уңга борыла, сулга борыла, өчкә бөкләнә, яңадан турылана торган нимес эшләгән йозак иде. Андый-мондый белмәгән кеше гомерендә дә бу йозакны ача алмаячак иде.

Хуҗа, ачкычларны алып, Ягъкуб белән Каюмга иллешәр тиен чәйлек бирде һәм аларга ярминкәдә йөрергә, фәкать кич кайтырга кушып, үзе өенә кайтып китте. Ике авылдаш ярминкә карарга киттеләр. Ләкин биш минут та үтмәде, Каюм янына төрле яктан белеш-танышлары җыела башладылар. Җыелган кешеләр бар да караңгы, шөбһәле кешеләр төсле иде. Җыелганнар башта Каюмнан нәрсә хакындадыр сораша башладылар. Аннан соң Каюм сорый башлады. Алар әллә нинди, кеше аңламаслык телдә сөйләшәләр иде. Шуңа күрә Ягъкуб аларның ни хакында сөйләшкәннәрен белә алмады. Бераздан соң Каюм һәм аның иптәшләре пышылдап сөйләшә башладылар. Сүз арасында Ягъкубка да карап куялар иде. Ягъкуб, сүз аның хакында икәнен белде, аны нindидер бер курку алды. Шуңа күрә ул шундук Каюмнан аерылып, бераз йөрде дә фатирына кайтып хәл җыярга ятты. Бик озак торгач, Каюм да кайтып җитте. Ул азрак исерек иде һәм, башым авырта, диеп, кичке ашны ашамыйча, шундук йокларга ятты. Хуҗа кайткач, Ягъкубны туйдырырга кушты. Һәм аңа тагы егерме тиен чәйлек биреп: «Сиңа һәрвакыт, ярминкәнең ахырына кадәр шундый хак, шундый аш булачак. Тик тугры хезмәт итәргә генә тырыш… Иртәгә иртүк кибеткә чык. Приказчиклар да чыгарлар. Аларның сүзен мине тыңлаган кеби тыңла! Товарны да сакла! Төнлә Каюм белән икеңез, чиратлашып, кибетне каравылларсыз! Аз гына берәр куркыныч сизсәң, хәзер үк миңа хәбәр ит! Тугры хезмәт итсәң, бу бирелә торган бәһадән өстен тагы наград бирермен», – диеп чыгып китте. Ягъкуб чын күңеленнән дога кылып йокларга ятты. «Ашау-эчүен тотасы юк, ашау тагы нинди? Мондый ашны мин бәйрәм вакытында да күргәнем юк, аның өстенә көн саен илле тиен: ун көн ярминкә булса, менә сиңа биш сум. Аллага шөкер!» – диеп уйлап, Ягъкуб шундук Алла белән ант итеп, хуҗасының малын үз малыннан да артык карарга сүз бирде.

Ахыры бар

Текстны басмага
***Рәисә Шәрәфиева** әзерләде.* ■

Гади кеше

Илдар Хәйруллин,
Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты

Туфан Миңнуллин турында сүз чыкса, татар кешесенең чын мәгънәсендә олпат шәхесе күз алдына килеп баса.

Әйе, үзенең бай иҗаты, күп еллык җәмәгать эшчәнлеге белән ул зур хөрмәт, абруй казанды.

Гади татар авылында туып, күп юллар үтеп, төрле профессияләрдә эшләп, Целинаны узып, Мәскәүдә укып кайтып, еллар узгач, иң мәшһүр татар драматургына әверелеп, Советлар Союзының Югары Советы депутаты, Татарстан Парламенты депутаты, Татарстан Язучылар берлеге рәисе булыр өчен табигатьтән бирелгән акыл, зәвык, милләте турында кайгырта белү, җәмгыятьнең проблемаларын күрә алу, аларны иң югары трибуналардан яңгырату – боларның барысын да гаять зур шәхес сыйфатларына ия булган кеше генә эшли ала.

Ләкин нинди генә биекләргә менмәсен, нинди генә үрләргә күтәрелмәсен, ул гомере буена Гади кеше булып калды. Гади җир кешесе булды. Үзенең уңышлары, җиңүләре белән, үзенең хаталары, каршылыклары белән.

Мин Туфан абыйны менә шулай ике рәвештә кабул итәм: Гади кеше һәм Бөек шәхес.

Аның яңа пьеса язып китерүе театрны селкетеп ала иде. Бөтенебез дә ул көнне зур вакыйга көткән кебек дулкынланып, шатланып көтә идек. Чөнки анда режиссер өчен күтелмәгән сюжет, артистлар өчен кабатланмас персонажлар, җор телле текстлар була иде.

Туфан абый исән чакта: «Туфанга рәхәт, ул ни генә язса да театр шуны куя», – дип әйтүчеләр бар иде.

Дөрес түгел. Әсәрләренә карата Туфан абыйга шактый каты тәнкыйть сүзләре дә, тискәре фикерләр дә ишетергә туры килде. Ул тәнкыйть сүзләрен Туфан абыйны яраткан, аны көтеп алган артистлар әйтә иде. Театрда шундый тәртип. Драматург, яңа пьесасын тәкъдим итеп, аны коллективка укый. Шуннан артистлар үз фикерләрен әйтә. Күп очракта әсәрнең уңай ягын санап киткәч, төп басым әсәрнең җитешмәгән якларына ясала. Бу – табигый күренеш. Сәнгатьтә фикер алышу, анализлау, капма-каршы карашларның бәрелеше булмаса – иҗат тынчый. Бер урында таптана башлый.

Ләкин күп авторлар, тәнкыйть

сүзләрен ишеткәч, ризасызлык белдерә, килешмиләр, театрга үпкәлиләр. Туфан абый да ризасызлык белдерде, үпкәләде, кабул ителмәгән пьесасын күтәреп өенә кайтып киткән чаклары да булды.

Шундый бер кызык хәл истә калган. Бер пьесасын укыганнан соң кабул итмәгәч, Туфан абый үпкәләп чыгып китте дә бер-ике ай театрга килмичә йөрде. Кемдер аны очратып: «Туфан абый, нигә театрга килмисез?» – дип сорагач, «Йөрмим, барсам, анда Илдарның малае* мине пьеса язарга өйрәтә», – дип, үпкәсен белдергән.

Ләкин, үпкәләсә дә, әйткән фикерләр белән килешмәсә дә, ул дәрәҗәсен төшермәде, артистларга маңгай астыннан сөзеп карамады, театрны сүгеп йөрмәде, риясыз булды. Кул биреп күреште, елмаеп сөйләште. Чын-чынлап гади, эчкерсез кеше иде.

Минемчә, аның уңышлы драматург булуына өч сыйфаты сәбәпче булгандыр.

Беренчесе, ул табигате белән көчле психолог иде. Шуңа күрә тормышны, кешеләрнең яшәешен яхшы белә, аларны игътибар белән күзәтә, күргәнишеткәннәрен дәфтәренә теркәп бара. Күп язучылар шулай тормышны күзәтеп, күргәннәрен куен дәфтәренә терки. Ләкин Туфан абый дөньяны үзенчә тоеп, аңа гына хас булган ракурстан күрә белә иде шул.

Ул һәрвакыт кулын бүгенге көн пульсында тотты. Җәмгыятьтә булган вакыйгаларның үзәгендә кайнады, шуңа таянып пьеса язды, язучының төп максатын үтәп барды.

Икенчесе, ул Мәскәүдә театр институтында укып, бөтендөнья драматургиясен өйрәнеп, аның серләренә төшенеп, пьесаларны ничек язарга икәнен өйрәнеп кайткан кеше. Гомумән, татар драматургиясен алсак, анда якты эз калдырган шәхесләр: Кәрим Тинчурин, Таҗи Гыйззәт, Хәй Вахит, Туфан Миңнуллин – барысы да драматург буларак театр мәктәбен үткән кешеләр.

Өченче сыйфат – аның тырышлыгы. Талантына белемне кушып уңышка ирешер өчен зур хезмәт, чиксез фидакярлек, алай гына да түгел, Ходай биргән илаһи көч кирәк. Бигрәк тә сәнгатьтә, бигрәк тә иҗатта.

Язучы, артист, рәссам – профессия түгел. Иҗат итү – кешенең эчке халәте, яшәү рәвеше. Үзеңне аяусыз чарлап, төн йокыларын калдырып, интегеп, меңәрләгән сорауга җавап эзләп, кешеләр бәгыренә үтәрлек итеп иҗат иткәндә генә әсәр тудырырга мөмкин.

Туфан абый гомере буе шулай яшәде, шулай иҗат итте. Үзен аямыйча янды, көйде, борчылды. Кичерешләрен, тойгыларын, йөрәк серләрен кәгазьгә күчереп пьеса тудырды. Шуңа күрә аның әсәрләре дә сәхнәдән төшмәде, халыкны елатты, көлдерде – иң мөһиме, кешеләрне уйланырга мәҗбүр итте.

Аның язу теле – әдәби тел түгел бит. Филология кануннарына таянып язмады ул. Кешеләр тормышта ничек сөйләшсә, шулай язды. «Мин урам теле белән язам», – дип ул үзе дә әйтә иде. Әсәрләрен укып чыксаң, шуны күрәсең – аның теле үзенә күрә бер байлык, үзенә күрә бер фразеологик берәмлекләрдән гыйбарәт. Шунлыктан, персонажлары да үзенчәлекле, җор телле, кабатланмас булды. Чөнки Туфан абый аларның барысын да ярата, үз итә иде. Игътибар итегез, аның әсәрләрендә әшәке, пычрак персо-

---

* Сүз Искәндәр Хәйруллин турында бара. – *Ред.*

нажлар юк. Һәрбер образның үзенең дөреслеге, үзенең тормыш позициясе, үзенең сөйкемлелеге бар. Пьеса язганда да, югары трибунадан чыгыш ясаганда да, ул коры рәсми тел кулланмады. Туфан абый һәрвакыт җанлы сүзләр таба иде. Шуның белән фикерен һәрдаим кешеләргә җиткерә, аларны үз чыгышлары белән тетрәндерә иде.

Аның тормышында тагын бер хәлиткеч вакыйга булды – ул үзенең фикердәшен, юлдашын очратты. Ул кеше – Марсель Сәлимҗанов иде. Аларның бер үк чорда, бер үк театрда очрашуы Ходай Тәгалә кодрәте белән булгандыр инде. Татар театрын баетыр өчен, аның дәрәҗәсен күтәрер өчен. Алар бер-берсен аңладылар, тойдылар. Кулга-кул тотынып иҗат иттеләр. Бер-берсеннән көнләштеләр, узыштылар, үпкәләштеләр. Ләкин бер-берсеннән башка яши алмадылар, чөнки алар бер-берсенең иҗатын баетып тулыландыралар иде.

Аларның иҗатларын бер-берсеннән аерсак, ни буласын күз алдыгызга китереп карагыз. Кайбер пьеса сәхнә күрмәгән булыр иде, күрсә, спектакль рәвешендә андый яңгыраш алмаган булыр иде.

Югыйсә, «Моңлы бер җыр» пьесасын – публицистика, диделәр, «Сөяркә»нең фикере нәрсәдә, дип аптырадылар, «Гөргөри кияүләре»н – бу нинди буш әсәр, дип гаҗәпләнделәр. Ләкин тәнкыйтькә эләккән бу пьесалар Марсель Сәлимҗанов кулыннан узгач, ул аларга җан өргәч, алар репертуарның иң уңышлы спектакльләренә әверелеп, күп еллар буена сәхнәдән төшмичә, тамашачыны куандырып яшәде. Һәм бу иҗади дуслык икесенең дә соңгы көненә кадәр дәвам итте.

Туфан абыйның иҗатын, тормыш юлын өйрәнеп монографияләр язарлар әле. Ул язмалар аерым китап булып чыгар. Туфан үзе иҗат иткән әсәрләр, татар драматургиясенең җәүһәрләренә әверелеп, күптомлы басмаларда дөнья күрде инде. Театр сәхнәләрендә уйналды, уйнала һәм әле бик күп еллар буена татар сәнгатен баетып, киләсе драматургларга үрнәк булып торырлар.

Ни аяныч, бүген без Туфан абый турында «иде» дип сөйләшәбез... Нишлисең?! – Адәм баласының гомере кыска. Ләкин үзеннән соң кеше якты эз калдырган икән, исәннәр аны олылап искә ала икән, димәк, ул халык һәм, Аллаһы Тәгалә каршындагы бурычын үтәгән булып чыга. Һәм, миңа калса, Татарстан җитәкчеләре бик кирәкле һәм вакытлы карар кабул итте. Озакка сузмыйча, бюрократия юлына җибәрмичә, Туфан абыйның якты истәлеген саклап калыр өчен, Казан үзәгендәге урамнарның берсен аның исеме белән атадылар.

Ул урамнан узган саен күңелемә рәхәт булып китә. Туфан абыйның җан җылылыган тоям сыман. Ул каядыр шунда, безгә читтән генә карап торадыр кебек. Безнең ничек иҗат иткәнебезне, кайсы юлдан барганыбызны, ничек яшәгәнебезне елмаеп кына күзәтә төсле.

Һәм иң мәгънәлесе – аның урамы Марсель Сәлимҗанов урамына килеп тоташа.

Ә ничек яшәргә икәнен, васыятен Туфан абый безгә үзенең «Әлдермештән Әлмәндәр» бабае аша әйтеп калдырды.

Урыны җәннәттә булсын. ■

Фото «Туфан Миңнуллин» китап-альбомыннан алынды.

Вафирәкәй

Әзһәр Шакиров

Үзенең фаҗигале үлеме белән күпме татар кешесен тетрәндерде ул! Минем әле мондый фаҗигале төстә вафат булган бер генә татар җырчысы турында да ишеткәнем булмады. Меңләгән тамашачысы аны соңгы юлга озатты.

Мин җырчыларны радиодан тыңларга яратам. Шулчакта җырчыларны гына түгел, аларның килеш-килбәтләрен, сәхнәдә үз-үзләрен тотышларын, кигән киемнәрен, кыланышларын күрмим, гомумән, җырчы буларак күз алдына китермим. Мин фәкать җырны – көйне, сүзләрне ишетәм, тыңлыйм, шуннан үземә тәм табам, ләззәт алам. Кайвакытны шулай була: җырчы сәхнәгә килеп чыга, аны, ничектер, җырчы дип кабул итә алмыйсың, аның кыяфәте, буй-сыны, үз-үзен тотышы аңа җырларга ярдәм итми. Менә шулчакта җырчыны жәлләп, минем йөрәгем өзгәләнә, ул күпме көч сала, тырыша, ләкин сәхнә өчен кирәк булган талант әле анда ачылмаган була, сәхнәдә ул ят күренә. Ә менә Вафирә сәхнәгә килеп чыккач, сәхнә матурланып, ямьләнеп китә, әйтерсең лә бөтен сәхнә матурлык белән тула. Аны зифа буе, озын кара чәчләре, зур кара күзләре, чибәр йөзе «менә бу кыз бала сәхнә өчен, җырчы булыр өчен туган» дип, бөтен халыкка искәртә. Әйе, аның башкару осталыгы искиткеч зур биеклектә иде.

Мин Вафирә белән 90 нчы еллар башында шактый очраша идем. Без Ирек мәйданында, Камал театры каршында, Сөембикә манарасы янында, урамнарда – кышкы салкыннарда, көзге яңгырларда «Азатлык!», «Азатлык!» дип, «Яшәсен Татар халкы, яшәсен Татар дәүләте!» дип, тамакларыбыз беткәнче кычкыра идек. Ул һәрвакыт үз чыгышларын «Ком бураны» көе белән башлый иде дә, бик күтәренке рухта тәмамлагач, «Азатлык!» дип халыкка кычкыра иде. Мин шуңа игътибар иттем: аның азатлык дип өндәве чын йөрәктән булганга, халык та бердәм күтәреп алып кабатлый иде. Ул шулхәтле күңеле,

Сулдан уңга: Камил Кәримов, Әбрар Кәримуллин, Роза Туфитуллова, Вафирә Гыйззәтуллина һәм Рәис Беляев. 90 нчы еллар

йөрәге белән янып йөрде ки, ансыз бер генә митингны да күз алдына китерүе мөмкин түгел иде.

Шулай беркөнне Вафирәне очраттым да:

– Нишләп бу араларда күренмисең әле, бер-бер хәл булдымы әллә? – дип сорадым.

– Депутат булам, малай, депутат. Менә көзге тунымны саттым әле, депутат буласың килсә, җиде мең сум акча кертергә кирәк икән, – дип җавап бирде ул.

– Эх, – мин әйтәм, – тун сатып кына депутат итеп сайлансаң, бөтен кеше депутат булыр иде. Аның өчен башка әйберне сатарга яки үзләрен сатып алырга кирәк, – дим.

– Юк, малай, мин үземнең сайлаучыларыма барсын да аңлатам: ничек гади халыкны талаганнарын да, безне ничек алдаганнарын да, – ди.

Мин әйтәм:

– Сине депутат итеп сайларлык татар халкы тумаган әле, аның бит үз фикере булганы юк. Ул өстән кемне кушсалар, шуны сайлый. Син инде шуны гына аңларга тиеш.

Әлбәттә инде, Вафирәне депутат итеп сайламадылар. Югыйсә, бәгырькәем, үзе һәр сайлаучыны йөреп чыкты.

Без Вафирә белән Яңа ел алдыннан очрашкан идек. Ул мине Фирдәвес Хәйруллина белән бергә үзенә чәйгә чакырды. Бүлмәсе бик матур итеп җыештырылган, өстәлен мул итеп әзерләгән. Бераз ашап-эчеп алгач:

– Беләсезме, мин бит хәзер шигырьләр язам, шуларга җырлар да чыгаргалыйм. Теләсәгез, берсен сезгә җырлап күрсәтер идем, – ди.

Без Фирдәвес белән менә ни өчен чакырулы икәнлегебезне аңладык.

Ул ике җырын җырлап бирде.

– Әллә син дә Сара апа кебек композитор булып китәсеңме? – дип сорадым мин.

– Нигә, мин бит хәзер төнлә йоклый алмыйм, торам да яза башлыйм, – диде.

Шунда уйлап куйдым: Ходай Тәгалә бирсә бирә бит кешегә көч һәм дәрт!

Аның шулхәтле эшлисе, кеше кебек яшисе килә иде. Нишлисең бит, Ходай Тәгаләдән узып булмый, язмышыңа үз үлемең белән үләргә язмаган икән, берни эшли алмыйсың. Хәйдәр Бигичев, Вафирә Гыйззәтуллина кебек җырчылар бу дөньядан вакытсыз киткәч, татарның музыка, җыр сәнгате авыр югалтулар кичерде. Сәнгатьтә шәхесләр кабатланмый. Хәйдәр, Вафирә кебек җырчылар тагын кайчан туардыр, бер Ходай гына белә.

Соңгы юлга аны меңләгән тамашачысы, шундагы халык үзенең гүзәл җырчысын гына түгел, ә бәлки милләт өчен янып-көеп йөри торган газиз баласын да югалтканына тәмам төшенеп озатты. ■

Татарстан Милли музеенда күренекле милләттәшебез Сара Касыймхан кызы Шакуловага кагылышлы кадерле ядкярләр саклана. «Мин 1887 елда Рязань губернасы Касыйм шәһәрендә дөньяга килгәнмен, — дип яза ул үзенең тәрҗемәи хәлендә. — 1894 елның көзендә мине шәһәрдән ун чакрым ераклыкта урнашкан татар авылына җибәрделәр. Андагы мәдрәсәдә бик тиз укырга һәм язарга өйрәндем... Туган телемне өйрәнеп җиткәч, мин авылда кала алмадым, чөнки хатын-кызлар гимназиясенә керергә әзерләнә идем».

Сорбонна шәкерте

Гимназиядә уку Сарага бик җиңел бирелә. Җиде ел буе ул алдынгы укучы була. Аеруча математика, тарих, әдәбият укытучыларын уңышлары белән сөендерә. «1905 елның октябрендә без гимназиядә тыныч кына укып йөри идек, — дип яза соңрак Сара Касыймхан кызы үзенең истәлекләрендә — 1905 елның 17 сентябрендәге Манифест Касыйм шәһәренә соңарып килә һәм һөнәр училищесы укучыларын бик нык дулкынландыра. Алар манифестация оештырып, гимназиягә юнәлә. Безнең беренче каттагы класс тәрәзәләре ачык иде. Мин тәрәзә аша чыгып күрше подъездның түбәсеннән манифестантларга таба киттем. Алар мине алкышлап каршы алды. Без фабрика эшчеләренә кушылдык. Яшьләр революцион фикерле кешеләр белән аралаша башлады...»

Сара Шакулованың гимназиядә укыган чагы. 1905 ел

Сара Шакулова элек тә математика һәм фәлсәфә буенча белемен тирәнәйтү турында уйлана. Ләкин кайда? Ничек? Россиядә хатын-кызларга югары уку йортларына юл ябык. Шакулова ничектер Цюрихта медицина докторы дипломы алган беренче рус хатыны Суслова турында «Дело» журналыннан укып белә.

Ниһаять, ул, тәвәккәлләп, үзе дә Сорбонна университетына юл тота һәм имтиханнарын уңышлы тапшырып, укырга кабул ителә.

1912 елда университетны тәмамлагач, Сара Шакулова туган иленә әйләнеп кайта. Мәскәү университеты ректоры белән катлаулы сөйләшүләрдән соң, аңа, Сорбонна дипломы белән, өлгергәнлек аттестатына имтихан тапшыру кирәклеге ачыклана. Шуннан соң гына Мәскәү университеты курсына тагын 25 им-

Сара Шакулова (уңда) әнисе һәм туганнары белән

тихан бирергә кирәк була. Боларның барысын да Сара 2 ел дәвамында тапшыра.

1915 елның гыйнвар аеннан ул Зарайск шәһәренең реаль училищесында математика укыта башлый. Казан уку округының халыклар училищесы инспекторы Спасский аңа, мөселман хатыны буларак, укыту эшенә рөхсәт бирми. Сара Касыймхан кызын укучылары бик ярата. Ул үз шәкертләрен иркле, хөр рухлы итеп тәрбияләргә омтыла.

Февраль революциясеннән соң, Шакулова Казан уку йортлары өчен смета төзү эшен җитәкли, мәгариф советын оештыруда катнаша.

1920-22 елларда Сара Касыймхан кызы Башкортстан мәгариф халык комиссариатында коллегия әгъзасы һәм нарком урынбасары вазифаларын башкара. Аның актив катнашлыгында һөнәр училищелары оештырыла.

1923 елның апрелендә Сара Шакулованы Мәскәүгә чакырып алалар. Ул РСФСР милли мәктәпләр инспекторы булып эшли башлый. 1925 елда аны Мәскәүнең Н.Нариманов исемендәге беренче татар мәктәбе директоры итеп билгелиләр. Булачак язучы Габдрахман Әпсәләмов та әлеге мәктәптә укыган.

30 нчы еллар башында гына Сара Шакулова үзенең «Лисанс эс Сьянс» Сорбонна дипломы турында «исенә төшерә» һәм лаеклы ялга чыкканчы Мәскәүнең югары уку йортларында югары математика кафедрасында укыта.

Шунысы кызык, беренче математик татар хатын-кызы һәм актив җәмәгать эшлеклесе булу белән беррәттән, аның архивында «Зөһрәкәй» исемле роман каралмасы да саклана.

Татарстан Милли музееның өлкән фәнни хезмәткәре
***Флүрә Дәминова** әзерләде.* ■

Фоторәсемнәрдәге гаилә ядкяре миңа XIX гасырда Казан губернасы Казан өязе Күшәр авылында яшәгән әниемнең бабасы Зарифулла Садыйкулладан мирас булып калды. Ә бу ядкярләрнең – халык гамәли сәнгате, көнкүреш, зәркән, тукылган һәм чигелгән әйберләрнең тарихы тагын да борынгырак, алар безнең бай һәм шанлы тарихыбызга барып тоташа. Кайчакта үзем дә гаҗәпләнеп уйлап куям: әби-бабаларым кырыс сәяси шартларда бу әйберләрне ничек саклап кала алдылар икән?

Затлы мирас – гаиләм ядкяре

Рафаэль Халитов

Әтием Халитов Төхфәтулла Сәмигулла улы (1936 елгы) вафат булганнан соң, әлеге ядкяр мирас булып миңа калды һәм аларны җитди рәвештә фәнни өйрәнә башладым.

Шулай итеп, бабам Зарифулланың туган төбәге – Әтнә районы Күшәр авылына юл тоттым һәм анда кардәшебез, 90 яшьлек Әдһәм бабай белән очраштым. «Синең бабаң бай кеше булган», – диде ул миңа, әмма әлеге тарихи җәһәттән әһәмиятле ядкярләр турында ул берни дә белмәде. Ә бабам Зарифулланың атасы Садыйкулла атлы булганлыгын мин Әдһәм бабайдан беренче мәртәбә ишетеп белдем, әмма

Татар хатын-кызының баш киемеННән фрагмент. XVII гасыр

Алка. XVII гасыр

Коръән савыты – күкрәкчә бизәнгече

Татар хатын-кызының баш киеме. XVII гасыр

ул аларның кайда җирләнгәнлекләрен әйтә алмады.

2010 елда мин хатын-кыз баш киеменең ничәнче елларга нисбәтле икәнлеген ачыклый алучы белгечне таптым. Ул – этнограф, тарих фәннәре кандидаты Мөхәммәдова Рәмзия Гыйният кызы. Аның белән очрашкач, мөхтәрәм галимә калфакның саклану дәрәҗәсен күреп: «Мондыйны минем инде күп еллар күргәнем юк иде», – дип

Төрки күчмәннәрнең йорт келәменнән фрагменты. XVIII гасыр

Көнкүреш кирәк-ярагын саклар өчен тегелгән капчык

Хатын-кыз билбавы. XVIII гасыр

гаҗәпкә калды. Рәмзия ханым ике ай дәвамында музейларның фондын өйрәнеп, баш киеменең XVII гасырдагы нугай татарларына нисбәтле икәнлеген әйтте. Мәгълүм ки, Казан ханлыгының патшабикәсе Сөембикә дә шул кавемнән.

Башка гамәли предметлар: төрки күчмәннәрнең йорт кирәк-яраклары, зәркәнчелек, көнкүреш әйберләре, чигүлекләр, савыт-саба – барлыгы иллеләп предмет та шактый әһәмиятле һәм кызыклы тарихи чыганак булып чыкты.

2014 елда ТР Милли музеенда Мәдәният министрлыгы ярдәме белән шушы хәзинә нигезендә «Үткәннән кайту» дип исемләнгән күргәзмә оештырылды. Әлеге күргәзмәдән фоторәсемнәр һәм башка тарихи ядкярләр белән тулырак www.beznenmiras.ru сайтыннан танышырга мөмкин.

Редакциядән. *Күп кенә татар гаиләләрендә борынгыдан сакланып килгән гаилә ядкяре бар. Ул зәркән-бизәнү әйберләре, эш кораллары, кызыклы фоторәсемнәр, иске китаплар һ.б. булырга мөмкин. Алар турында кыска гына мәкалә язып, фотога төшереп, безнең редакциябез оештырган «Гаилә ядкяре» конкурсына җибәрә аласыз.* ■

1969 елда Таҗикстанга – хәзерге Турсун-Заде шәһәренә баргач, бер вакыйга булган иде. Җәй урталарында, әнием сорагач, мин аны шул шәһәргә Миньямал апабыз янына кунакка алып киттем. Апабыз – гаиләдә иң өлкәне. Сугыш елларында бәхет эзләп, шул якларга китеп барган һәм кияүгә чыгып, тормыш корып, шунда яшәп калган. Ул мамык комбинатында эшли иде.

Онытылмас очрашу

Яшь чак булгангадыр инде, алмаш күлмәк-кием дә алмаганмын, тик укытучы булып эшли башлагач та беренче хезмәт хакына сатып алынган «Мелодия» баянын гына үземнән калдырмаган идем. Безне бик әйбәтләп каршы алдылар. Кичен апам биредә яшәүче утызга якын милләттәшебезне һәм күрше-тирә таҗикларны ашка чакырды. Апа минем баян күтәреп киләсемне башына да китермәгән, кулымда баян салынган чемодан булгач, хәзер юлда шулай чемодан белән йөриләрдер, дип кенә уйлаган.

Кунаклар сөйләшеп-гөрләшеп утыра торгач, күңел хисләрен – туган якларын, авыл чишмәләрен, беренче мәхәббәтләрен сагынуларын да – ачып салдылар. Алар арасында төрле кешеләр бар иде: берәүләр ачлыктан, икенчеләре репрессияләрдән качып киткәннәр, язмыш аларга шушы урында сыену һәм яшәү мөмкинлеге биргән. Сөйләшү кызыклы булды – алар бездәге, туган якларындагы хәлләр турында сорашалар, әни белән мин җавап бирәбез, сөйлибез. Шул арада кемнәрдер татар халык җырларын да суза башладылар.

СОК БУЙЛАРЫ

(Һ.Сафина. «Җыр дәвам итә» спектакленнән Зәйнәп җыры)

Һава Сафина сүзләре — Мәсгут Имашев көе



Кояш баткан чакта, Сок буенда
Синең җырларыңны җырладым.
Сайравыннан туктап, сандугач та,
Сандугач та сагынып тыңлады.

Сокның дулкыннары алып китте
Синең тарафларга моңымны.
Әллә кайтасыңмы туган якка? –
Сок буйлары көтә җырыңны.

Иңнәреңнән кочып, тал тирәкләр
Минем хисләремне сөйләрләр.
Күзләреңнән үбеп, ал чәчәкләр:
«Ул бит көтте сине», – диярләр.

Мин дә чемоданымны алдым һәм аннан, зурлап, баянымны тартып чыгардым. Мәҗлестәгеләр барысы да тынып калдылар, һәм мин Мәсгут абый Имашевның әле яңа гына язылган «Сок буйлары», көен уйнап, шул көйгә күңелдәге шигырь юлларын кушып җырлап та җибәрдем. «Әллә кайтасызмы туган якка, әти-әни көтә сагынып» дигән сүзләре хәтеремдә калган. Мин җырлап бетергәндә табын артында утырган бар кешенең күзләреннән яшьләр тама, хәтта туган якларын сагынып, үксеп-үксеп елап утыручылар да бар иде.

Биредә безне кемнәр генә кунакка чакырса да, башлап шушы җырны башкаруымны сорыйлар иде. Бу җыр, гомумән, ул елларда туган көйләр күңелгә бер азык булып ята, һәркемдә матур хисләр уятып, күңелне хушландыралар иде. «Сок буйлары»н да күпләр магнитофон тасмасына яздырып алып, без киткәч тә урамда уйнатып, безне искә төшереп торганнар, дип сөйләделәр.

Озату көне килеп җиткәч, иртәнге сәгать дүртләр тирәсендә тимер юл вокзалына юнәлдек. Мин, шәһәр буйлап, вокзалга кадәр шул гаҗәеп матур көйне уйнап бардым. Артымнан берничә дистә кеше миңа кушылып, җырлап барды. Ә вокзалга килгәч, ис китте: анда алтмыш-җитмешләп милләттәшебез, хәтта таҗиклар һәм үзбәкләр дә безне озатырга җыелганнар иде. Шунысы бик истә калды – «Сок буйлары»н вокзал алдында җыелган йөздән күбрәк кеше, хор белән җырлап, кемнәрдер елап басып торды.

Шуннан соң, поезд килгәнче дип, мин бию көе уйнап җибәрдем. Халык бии башлады. Ә яныма Калиндар исемле Бөек Ватан сугышы инвалиды, бер аяксыз абый килде дә, мине кочаклап елый-елый:

– Улым, сиңа мең-мең рәхмәт! Мин туган якларга кайта алмам инде. Их, аякларым булса… Сволочь фашист, – дип култык таягын җиргә бәреп сындырды да, бер аягында бии башлады!

Бу мизгелне һич онытасым юк. Түзеп кала алмадым, күземнән яшьләр акты. Яңадан «Сок буйлары» көен уйнап җибәрдем…

Поездда бик озак уйланып бардым. Безнең милләт нинди бердәм дә, кунакчыл да, кайда гына булмасын, туган илен, туган туфрагын бервакытта да онытмый икән! Бу очрашу мине тәмам тетрәндерде.

Ә халык күңелен яуларлык җырлар иҗат итүче Мәсгут Габдрахман улы Имашевка карата иң якты хисләр күңелем түрендә гомергә саклана.

Ранас Котлыев, *инженер.*

Редакциядән: *Әлеге җырның ни рәвешле туувы хакында Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Мәсгут ага Имашев менә ниләр сөйләде:*

– Әлмәттә музыка училищесы директоры булып эшләгән чагым. Минзәлә театры директоры Анатолий Богатырев, шалтыратып, «Җыр дәвам итә» дигән яңа спектакленә музыка язарга тәкъдим итте. Пьесаны Әлмәттә яшәүче Һава Сафина язган икән, алдым, укыдым, көйләр яздым. Җырларымны театр артистлары яратып кабул итте. Премьерадан, гастрольләрдән соң, шушы спектакльдән «Сок буйлары» дигән җыр халык арасында танылып, җырлана башлады, атаклы җырчыбыз Әлфия Афзалова аны үз репертуарына алып, ил буйлап яңгыратты. Бәхетле булып, ул җыр бүген дә халык күңелендә яши. Рәхмәт җыр сөючеләргә! ■

Миллият сүзлеге

Адлер Тимергалин

РОССИЯ ТАТАР ШӘКЕРТЛӘРЕНЕҢ БЕРЕНЧЕ КОРЫЛТАЕ – 1906 елның 10-15 майларында Казанда үткәрелгән. Корылтайны ислах комитеты җыя, ә аның программасы, чыгышлар, шул җөмләдән мәдрәсәләрдә ислах турындагы чыгыш та, Фатих Әмирхан тарафыннан яки аның җитәкчелегендә әзерләнә. Корылтайның рәисе дә Ф.Әмирхан булган.

Шәкертләрнең икенче җыелышы 1907 елның җәендә шулай ук Казанда үткәрелгән.

РӨШДИ, РӨШДИЯ *г.* – 1917 елгы инкыйлабка кадәрге Россиядә урта мәктәп. Элекке мәдрәсәләрдә «рөшди сыйныф» шәкертләрен үз араларында «касмак» дип йөрткәннәр. //Ибтидаи вә рөшди мәктәпләр гыйлемгә түгел, бәлки гамәлгә, тормышка хезмәт итәләр. Җамал Вәлиди.

Кара: Рөшед, 2.

РУН ЯЗУЫ *тар.* – Башкача – руника. Руник язу да диләр. Борынгы чорда төрки мохиттә барлыкка килгән бу алфавит согди алфавитына нигезләнсә дә, яңа тамгалар белән тулыландырылган һәм тырнап яки чокып ташка,

Рун язма истәлеге – Күлтәгин ташы

*Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә.

агачка язу өчен бик кулай булган. Ул 38 тамга-хәрефтән торган, тамгалар язуда бер-берсенә кушылмаганнар, аерым-аерым торганнар. Византия тарихчысы Менандр мондый язуны «скиф язуы» дип атый.

Төньяк Европа халыклары якынча II гасырдан алып Урта гасырларга кадәр файдаланып килгән алфавит хәрефләрен дә рун язуы дип атыйлар (төгәл итеп әйткәндә, бу язу беренчел булса кирәк). Борынгы герман рун язуында 24 тамга булган, ә англосаксларда аларның саны 33кә җиткән Соңрак викинглар 16 рун тамгасыннан файдаланганнар. XX гасыр башларыннан алып 1933 елга кадәр Көнбатыш Европада нимес оккультистлары рун язуын кулланышка кертергә тырышып караганнар.

Рун язулы истәлекләрдән Урхун елгасы буендагы ташка тырнап язган төрки истәлекләр («Урхун/Орхон язмалары») төрки каһанлыкның соңгы чорына—VIII гасырга карыйлар. Енисей буендагы язмалар исә VII-VIII гасырларга нисбәт ителә. Аларны XVIII гасырның 20 елларында Петр патшада хезмәттә торган нимес галиме Д.Мессершмидт һәм аның ярдәмчесе, русларга әсир төшкән швед офицеры И.Страленберг ачканнар. Ә бу алфавитның ачкычын Дания галиме В.Томсен тапкан. Гомумән, борынгы төрки рун язмалары белән Көнбатыш Европа руникасының борынгы тамырлары уртак булса кирәк.

Кыскасы, «гарәп алфавитына нигезләнгән язу үтеп кергәнгә кадәр үк инде Болгар дәүләтендә рун характерындагы борынгы төрки язуы була». («Татарстан АССР тарихы», 1970).

«Бүгенге «тәңречеләр» татар язуын борынгы төрек имласы—рунга күчерү ягында... Әмма бүгенге көндә рун имласына күчү латинга күчүдән дә зыянлырак. Чөнки бу очракта без тәмам бетәбез. Эш шунда ки, безнең борынгы Туран-төрек цивилизациясеннән бернинди дә диярлек рухи мирасыбыз калмаган». Бу фикер татар зыялысы Илдус Әмирханныкы (2003). Дәлилләре җитәрлек булмаса да, аның төп фикере дөрес, әлбәттә. Рун имласы—үтелгән баскыч ул, без бүген рун киеменә сыешмыйбыз инде. Рухи яктан мондый язу бездән бик ерак, ул безнең күңелдә сагыну, ностальгия хисләре дә уята алмый. Ул бүгенге фән телендә кулланыла торган символлар белән берничек тә ярашмый.

РУС — Рус милләте кешесе. Татар сөйләм телендә рус—урыс, вотякларда—дючь-мурт, чуашта—вюрезъ, черемисләрдә—рушь, пирмән һәм зыряннарда—роджь яки роч. (М.З.Зәкиев. «Проблемы языка и происхождения волжских татар», Казан, 1986).

Бүгенге матбугатта «урыс» язылышы активлашты, ләкин шулай да «урыс» сүзендә чит халыкка кире мөнәсәбәт, «урыс-улак» дип карау төсмерләнә. Ә бит, әйтик, Гаяз Исхакый бу халыкка ничек кенә тискәре карамасын, аның гадел каләме барыбер «рус» дип яза биргән. Габдулла Тукай да шулай.

РУМ — Византия, Кече Азия, поэзиядә — барлык көнбатыш илләре. Румистан да дигәннәр. Фарсы әдәбиятында румлылар, ак раса вәкилләре буларак, ак төс, көн символы, ә эфиоплар — кара төс һәм төн символы булган. Татарда очрый торган Румил-Румилә исеме, ахыргы исәптә, Борынгы Рим шәһәренә нигез салучы Ромул исеменә барып тоташа. Ә, гомумән, Руми сүзе борынгы Грециягә һәм Византиягә баглы. ■

قوياش

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1916 елның май ае

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Театр вә музыка

Җомга көн «Сәйяр» труппа артистлары тарафыннан ясалган видаг [саубуллашу] спектакленә миһманнар [кунаклар] гаять күп килгән иде. Тамашага куелган «Ике гашыйк»тагы мәсъулиятьле [җаваплы] рольләрдән мөтәгассыйб [кире] Рәхмәтулла бай (Г.Кариев), аның яшь хатыны Галимә (Әхмәдиева), Хөршидә (Болгарская), Габделкаюмны (Үзбәк Тинчурин) гаять табигый вә рухына кереп башкардылар. Соңгы пәрдәдә, хатын-кыз белән шаярмаган булуы белән бергә, хатын-кыз белән бер дә аралашмаган гыйффәтле Габделкаюмның, вәгъдә кылып, күрешергә килгәндә кыз илә мосахәбәсе [сөйләшүе] миһманнарның хушына бик килеште. Икенче дәрәҗәдәге рольләрне башкаручылар да бүтәннәрдән калышмадылар вә уенның уңышлы чыгуына ярдәм кылдылар.

Концерт вә музыка өлешендә скрипкада уйнаган Гали әфәнде Зайпин белән Фатыйма туташ Гомәрованы сәхнәбез өчен зур байлык дип санарга мәҗбүр булынадыр. Гали әфәнде Зайпин да, зур техника өстенә, көйләребез рухын саклавы һәм рухланып башкаруы – байлык өстенә янә бер зиннәттер. Фатыйма туташ Гомәрова бу юлы кайбер югары тонны (нечкә тавышлар) чыгарганда үз куәсеннән артыграк көчләнгәнен күрсәтте. Бүтән урыннары яхшы үтте. Матур тасвир ителгән «Язмыш» декламациясе башта бик яхшы барды, соңга таба язмышның амиранә хитабларындагы кайбер сүзләре зәгыйфьләр тавышы беләнрәк әйтелеп җибәрелгәләде.

Кояш. – 1916. – №960. – 3 май.

Яшьләрне чакыру

1897 нче елда туган яшьләрне гаскәргә каралырга чакырып игълан нәшер ителде. Каралу мобилизация ысулы белән булачак, ягъни яшьләр воинский начальник хозурына барып күренергә тиешләр. Күренү көненең башы майның 15 нчесенә билгеләнгән.

Мәдрәсәи «Касыймия» вә «Мөхәммәдия» талибәләренә бирелгән отсрочкаларның мөддәте [срогы] 1 нче июньгә кадәр генә икәне вә шушы көндә мөддәтләре тәмам булачагы мәдрәсә мөдириятенә игълям ителгән [белдергән].

Кояш. – 1916. – №965. – 13 май.

Иген машиналарын төзәтергә

Вак бурыч җәмгыятьләре[1] иттифакы [берләшмәсе] идарәсе, бу ел хезмәт кулы азайганлыктан, иген эшләү машиналары бик кирәкле урын тотканлыгын игътибарга алып, иген машиналары төзәтү йортлары ачтырырга карар кылган. Бу йортлар өчен смета 45 мең сумнар чамасында тотарга хисаплаган.

---

* Даталар иске стиль белән бирелә.

[1] Вак бурыч җәмгыятьләре – крестьяннарны орлык, авыл хуҗалыгы кирәк-яраклары, нәселле маллар алу өчен кредит белән тәэмин итә торган ширкәтләр.

Кыйммәтчелек сәбәпле

Шәһәрнең малия [финанс] комиссиясендә Казанка һәм Кабан күле аркылы көймәдә күчерүләр эшен карагач, электәге 1 тиен урынына 2 тиен алырга ярый, дип табылган. Су кергән өчен купальняларда 1 нче класска 15 тиен, 2 нче класска 7 тиен, номерлар 1 нче класска 50 тиен, 2 нче класска 30 тиен ясарга мөмкин табылган.

Кояш. – 1916. – №967. – 19 май.

Нишаннар

Падишаһ хәзрәтләре тарафыннан түбәндәге имамнарга «Ихлас белән хезмәтләре өчен» дип язылган муенга асмалы алтын нишаннар [знак отличия] ихсан ителгән: Олуг Мәңгәр имамы Мөхәммәдйосыф Зыятдин углы Арслановка, Казан шәһәре Госмановлар (Мөхәммәд хәзрәт) мәсҗеде имамы Мөхәммәдгариф Салиховка; Станислав тасмалы, күкрәккә тагар өчен: 11 нче мәсҗед имамы Кәшшәфетдин Кыяметдин углы Тәрҗемановка; көмеш медаль: 6 нчы (Әҗемевләр) мәсҗед имамы мирза Габдулла Габделвәли углы Габделгаффаровка.

Кояш. – 1916. – №971. – 26 май.

Фатиха Аитова мәктәбе выставкасы

Фатиха ханым Аитованың кызлар мәктәбендә выставка ачылды (бу көн – ирләр өчен актык көне, иртәгә хатыннар өчен ачык булачак). Монда кыз балаларның кул һөнәрләре байтак күп. Эчке киемнәрдән өстке киемнәргәчә тегәргә өйрәтүләр дәвам иттерелгән. Үткән елларда аз эшләнгән калфак эше бу ел яхшы ук төзәтелгән вә камил иттерелгән, бик килешле итеп нәфис эшләнгән калфаклар күп. Чигү эшендә бу ел накладной шов, кәгазьгә үрнәк ясап хәтфә белән ябып бизәкләү вә рәсем төшерү ысулы кертелгән. Эшләр арасында гади чигү белән чигелгән нәфис нәрсәләр күп. Эшләнгән нәрсәләр арасында Суфия Габделвәли кызы Госманова, Мәрьямбикә Бәхтиева, Хөршид Иманколова, Өммегөлсем Шәрипова, Рәфия Зариф кызы Мансурова, Әминә Хөсәенова, Зәйнәп Мөхәммәтҗанова, Зәкия Зариф кызы Вахитова, Галия Йосыповаларның кул эшләре аерым дикъкать ителеп эшләнгәннәрдәндер. Кул һөнәре мәктәпнең шушы шөгъбәсен [бүлеге] бер ысулга куйган В.С.Моисеева тәхте идарәсендә [җитәкчелегендә] булган. Моннан башка Разыя Хөсәенова һәм Мәрьям Госманова туташлар могунәлек [ярдәм итү] хезмәте өстенә, калфак эшләү вә бәйләү эшләренә мөстәкыйль мөгаллимәлек кылганнар. Выставкада ике йөз кадәр нәрсә бар.

Кояш. – 1916. – №973. – 29 май.

Сабан туе сәгать 2дә

Бүген җомга, 27 нче майда күл башындагы Аркадия бакчасында Сабан туеның беренче көне булачак. Туй мәрасиме сәгать 2дә башлана. Бу ел Сабан туена бару юлы мәшәкатьсез булып, туй урыны пароходта бара торган һәм трамвай юлыннан да ерак булмаган урындадыр. Туйның саф файдасы Казан җәмгыяте хәйрияи исламиясе файдасынадыр.

Кояш. – 1916. – №972. – 27 май.

КӨЛКЕ КУА КИЛӘ...

Фатих Әмирхан (1886-1926)

ҖҮБӘЛӘЙ

Берзаманда бер мәхәлләдә ике имам булганнар, имеш. Яшь имам мәдрәсәдә тәрбия кыйлган, мөгаллимнәр җитештергән, әлхасил, булган көчен, булдыра алган эшен кызганмаган.

Карт имам, бичара, «простой» кеше булган һәм бары «простой» кеше булган.

Егерме биш ел узгач, яшь имамга юбилей ясаганнар.

Бу вакытта карт имамның «хезмәт» башлаганына илле ел тулса да, юбилей хакында бер дә уйлаучы булмаган. Карт хәзрәт, табигый, кәефсезләнгән.

– Мулла кем егерме биш ел гына имам булып торды да, аңар «җүбәләй» (юбилей) ясаганнар. Менә мин илле ел мәхәллә имамы булып торам да, байларның берсе дә «җүбәләй» ясамый... Кухняма куярга бер лампа да китергәннәре юк, – дип бик самими зарланган, имеш. Бу анекдоттыр; кем белә, бәлки ма вәкагадыр (вакыйгадыр) да. Ничек булса булсын, дөньяда мондый да вәкагалар да булмый тормыйдыр.

Әйтеңез, зинһар, бу картны ничек иттереп кызганмаска кирәк инде? «Кызганыч», бик «кызганыч»! Җитмеш-сиксән ел дөньяда торган, үз фикеренчә хезмәт тә иткән, ләкин «җүбәләй» юк! Юк та бетте, вәссәлам!

Мин бу картны бик кызганам, хәтта, булдыра алсам, «җүбәләе»нә берәр җылы, бик җылы бер сүз дә әйтер идем. Ләкин, нишлим, хәзинәмдә аңар әйтерлек бер җылы сүз дә таба алмыйм. Нинди сүзне тотсам да, ул аның хезмәтеннән артыграк булачак. Юл бер генә: бернәрсә дә әйтмим. Шулай, әйтмим!

ОЗЫН-ОЗЫН РАМАЗАННАР...

(Халык мәзәге)

Әби белән бабай үзләре кунакка киткәндә кызларына әйтә:

– Кызым! Баздагы май белән балларга тимә, аларны хәзер ашарга ярамый. Менә тиздән озын-озын рамазаннар килеп җитәр, без аны шуңа дип әзерләдек, – ди.

Чит авылдан күршеләренә кунак булып килгән егет бу

сүзләрне ишетеп калган. Шул егет кич, ут алгач, бер-ике иптәш алып килгән дә ишек шакыган.

– Ач, сеңелем, бу без, озын-озын Рамазаннар! – дигән.

Кыз ачып керткән. Рамазаннарга тәпәне белән майны һәм балны кертеп утырткан. Рамазаннар, кызны шаяртып, рәхмәт әйтә-әйтә сыйланган.

Кызга Рамазаннар ошаган, ә Рамазаннарга кыз бик ошаган. Шулай итеп, алар кисмәктәге бал белән май беткәнче кич саен килеп йөргән.

Әби белән бабай кайтып төшүгә:

– Йортта ул-бу юкмы? – дип сораган.

– Юк. Озын-озын Рамазаннар гына килеп кунак булып киттеләр, – дигән кыз.

Гамил Афзал (1921-2003)

БЕР ТӨРКЕМ ИПТӘШЛӘР



Гамил Афзал.
Ф. Вахитов шаржы

Агымдагы оператив эшләр беткәч,
Аю иптәш, Бүре иптәш, Төлке иптәш
Чыктылар бер җилләнергә һава сулап,
Объектлар карый-карый урман буйлап.

Аю әйтә: – Баш авырта, арыткан, – ди.
Бүре әйтә: – Ничек карар Арыслан, – ди...
Кыюланып, Төлке әйтә шул урында:
– Ничек булыр, чамаласак өч борынга?

Аю, Бүре елмайдылар сүзсез генә.
Хәлне аңлап, Төлке иптәш тиз-тиз генә
Шап иттерде бер Куянны колагыннан.
– Менә, – диде, – шушы дурак тәртип бозган!

Өзеп кенә каптылар да берәр кисәк,
Сөйләшергә тотындылар, җиңне иснәп:
– Ягъни, дуслар, безнең аппаратка килсәк,
Штатны кыскартырга иде исәп.

– Куянетдин булдыксыз һәм ахмак иде,
Коты качкан ике күзе шакмак иде,
Андый куркак урманнарда сирәк иде...
Некролог әтмәлләргә кирәк инде.

Каерып алган каен тузы кайгы тойды:
Бүген иртән Куян иптәш дөнья куйды.
Куян иптәш иртә китте арабыздан.
Моң-зар ага йөрәктәге ярабыздан.

Куян иптәш сизгер иде, тыйнак иде,
Ул һәр җирдә көтеп алган кунак иде.
Урлашмады, тайпылмады уңга-сулга,
Принципиаль чаба иде туры юлда.

Образы урманга нур чәчәр, диеп,
Күңелләрдә мәңге-мәңге яшәр, диеп,
Кул куйдылар:
«Бер төркем иптәшләр» диеп.

МӘГЪСУМ ХУҖИНГА НИСБӘТЛЕ МӘЗӘКЛӘР

Фаил Шәфигуллин (1939-1982)

ЯЗУЧЫЛАР САБАН ТУЕННАН РЕПОРТАЖ

(Өзек)

...Карасана, Кояш (Тимбикова) күрми дә торган, имеш, — инде көрәшнең дә тәмам кызып җиткән чагы икән. Мәйданда ике батыр көрәшә. Икесе дә «Чаян» редакциясеннән. Мәгъсум Хуҗин дигәне, узган елгы Сабан туенда батыр калганы, яшь буенча да, эше буенча да Зөлфәт дигәненнән өлкәнрәге. Зөлфәт дигәненә бертуктаусыз акыллы киңәшләр бирә: «Сөлгеңне тегеләйрәк тот, кулларыңны болайрак эләктер», — ди. Тегесе үгез кебек киреләнә. Бөдрәләрен уңга-сулга селти. Мәйдан тирәли ах-ух килеп йөргәч, Хуҗин янә сүз башлый: «Өстәлеңдә тау кадәр эш өелеп тора, Сабан туена килеп йөрмәскә иде, эшләп бетерергә кирәк иде», — ди. Зөлфәт Хуҗинның сүзен колагына да элми. Җитмәсә, әледән-әле начальнигын селтәп ыргытырга «чамалый». «Бу айда премия бирәчәкләр», — ди Хуҗин, күзләрен йөнтәс кашлары астыннан хәйләле елтыратып. Зөлфәтнең кинәт биле дә, куллары да йомшый башлый. «Сиңа узган айдагы тәрҗемәләрең өчен гонорар яздым әле, — ди Хуҗин, — ялдан соң кереп алырсың». Аннары татлыләззәтле сүзләрдән балавыз кебек эрегән Зөлфәтне җиргә алып сылый.

Мәйдан гөр килә.

«Бер, ике, өч, — дип кычкыра судья, — бер, ике, өч. Кем чыга Хуҗинга?!» «Ичмасам, Нәби Дәүли дә йоклап ята», — дип көрсенә Кояш.

Мәйданга чал чәчле Хәсән Туфан чыга. Ул Хуҗинны, суларга да ирек бирмичә, биленнән каптырып ала да нарат күркәләре өстенә тәгәрәтеп җибәрә. «Молодец!» — дип кычкыра халык.

1974

Сөләйман Гараф

ОЧУ ҺӘМ ТӘПИ БАСУ

Мәгъсум Хуҗин белән Ләис Зөлкарнәй ресторан хәлен белмәкче була. Урам читенә тәгәрәгән сәрхушны күреп, Хуҗин туктала. Аптырабрак торгач, Ләис:

— Кызганыч тоелдымы әллә, Мәгъсум абый? — дип сорый. — Күтәреп торгызыргамы исәбең?

— Горький мәгълүм гыйбарәсен тәмамламаган икән. «Шуышырга туган оча алмый», дигәннән соң, «аунарга туган тәпи баса алмый», дип өстәргә кирәк иде. Әйдә, Ләис энекәш, без тәпи баскан, шуңа күрә өйләргә кайтыр юлларга борылыйк...

НУЛЬЛӘР БИЮЕ

Тамак туйдырыр өчен пенсиясе дә, «Татарстан» журналыннан тигән хезмәт хакы да җитмәгәч, Мәгъсум Хуҗин «Казан утлары»ннан эш алган. Тәрҗемә итәргә, һәр гамәлне чемләп, җентекләп башкарырга күнеккән Мәгъсум абый, ай буе утырып, тәрҗемәне, ниһаять, төгәлләгән. 20 мең түләп, машинкада бастырып та алган.

Дүрт-биш ай үткәч, «Казан утлары»на, гонорар бирәбез, дип олылап дәшкәннәр аны. Ведомостьта «М. Хуҗин»ны табып кул куйган да сумманы карыйсы иткән. «12» дигәнен күргән ул, әмма «12» артына тезелеп баскан «0»ләр биешә, күбәя башлаган. 1200000 түгелме соң?! Хуҗинның маңгаена тир бәреп чыккан. «Яшибез болай булгач!»

Бик иртә шатланган икән Мәгъсум абый: бухгалтер аңа 12 мең генә чутлап биргән.

1995 ■

Мирасворд



Төрле зурлыктагы тирән савыт, кәнди

Поляк (иск.)

Борынгы Идел

Тегермәндә ташларны әйләндереп алган стена

Мәчеттә мулла намаз укый торган махсус урын

Г.Камал театры каршында эшләгән труппа

... Риза (борынгы һинд рәссамы)

Борынгы Скандинавиядә диңгез сугышчысы

Батыр-Болгари, Янсуар

Гомер поэмасы

Афзал Шамов романы

Сугышчы (иск.)

XIX йөз рус рәссамы

... Канашевич

... Кайбицкая

Марис ... (латыш балет артисты)

Юпитер иярчене

Гаскәр (иск.)

Сәгыйть Рәмиев шигыре

«... дан радио» повесте (Шамил Усманов)

Мари телендә чыгучы әдәби журнал

Элек хатын-кызлар битенә ябып йөргән юка пәрдә

Нота

Мисыр мифологиясендә дөньяны барлыкка китерүче Алла

Гази, Салахов

«Өзелгән ...» (Г.Тукай шигыре)

Иосип ... Тито

Франциядә борынгы алтын тәңкә

Төркиләрдә кышны озату, язны каршылау бәйрәме

Теркәгеч

Байрак, флаг, әләм (иск.)

Язучы Тәүфикъ ...

... Сакаева

Зөянең сул кушылдыгы



Әмирхан ...

Борынгы грек шагыйре

... Исәнбәт

Эммануэль ... (мажар композиторы)

Совет кинорежиссеры, 16 экиятфильм авторы

4 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: «Яшен», капу, өтер, Шүрәле, «Илдар», ару, «Уклар», «Таз», ир, анфас, Кушлавыч, әнә, өр, муел, өзмә, Карәхмәт, на, ыру, намаз, лье, тәтe.

Өстән аска: шат, Көек, «Амур», «Зар», «Яшьләр», иләмән, Луара, Ухань, өке, «Ваем», Ает, стан, уй, ләим, «Пе», ки, ачу, тракт, Нуруллин, үз, да, Фәйзи, арзан, сәләт.

Рәис Габдулла төзеде.

Тукай клубы урнашкан Матбугат йорты. Узган гасырның кырыгынчы еллары

«Безнең мирас»

елъязмасы / май

● 210 ел элек (1806)

Казан университетының Ботаника бакчасы оештырыла.

145 ел элек (1871)

Педагог, дин галиме Габдулла Габделгалләм улы Бубый (Нигъмәтуллин) (1871-1922) дөньяга килә.

110 ел элек (1906)

18 майда Казанда «Таң йолдызы» газетасының беренче саны дөнья күрә. Мөхәррире – шагыйрь Сәгыйть Рәмиев.

95 ел элек (1921)

Татнаркомпросның укый-яза белмәүчелекне бетерү бүлеге рус һәм татар телләрендәге драма әсәрләренә конкурс игълан итә.

85 ел элек (1931)

«Азат Себер» газетасы хәбәр итүенчә, 6 майда Көнбатыш Себердә күчмә татар театр труппасы эшли башлый. Труппаның җитәкчесе – Камал I.

75 ел элек (1941)

20 майда әдәбият турында лекцияләр уку һәм әдәби кичәләр оештыру өчен Язучылар союзы ТАССР районнарына ике бригада чыгара. Беренче бригадада Муса Җәлил, Мирсәй Әмир һәм Нур Баян була.

70 ел элек (1946)

10 майда Казандагы Тукай клубында үткәрелүче чираттагы «Әдәби җомга»да Шәрәф Мөдәрриснең фронтта язган әсәрләре тикшерелә.

Мәскәүдә СССР Фәннәр академиясенең тарих һәм философия бүлегендә фәнни сессия була. Татарстан тарихының бәхәсле мәсьәләләре тикшерелә. Казан татарларының килеп чыгуы турында дүрт доклад тыңлана.

45 ел элек (1971)

14 майда «Социалистик Татарстан» газетасында, республикада 1 миллиард тонна нефть чыгарылу уңае белән, Хәсән Туфанның «Язып куй тарихка» дип аталган мәдхия шигыре дөнья күрә.

25 ел элек (1991)

13 майда РСФСР Президентын Татарстанда да сайлау турында карар кабул ителгәч, моңа кискен ризасызлык йөзеннән, бер төркем милләтпәрвәрләр Ирек мәйданында сәяси ачлык игълан итәләр. Алар арасында язучылардан Фәүзия Бәйрәмова, Рәшит Әхмәтҗанов, Зәки Зәйнуллин, Газинур Морат, Әхәт Мушинский һәм Заһит Мәхмүди дә бар. ■

Сурәтләрдә – Сабан туе

Вилсун һәм Римма Хәкимовлар. «Җайдак». Фарфор

Абрек Абзгильдин. «Көрәш». «Сабан туе» сериясеннән. Киндер, майлы буяу

Фәйзрахман Әминов. «Сабан туе». Киндер, майлы буяу

Шамил Нигъмәтуллин. «Иртәгә бәйрәм». Киндер, майлы буяу

www.beznenmiras.ru

БЕЗ – МИРАСЛЫ ХАЛЫК!

«Безнең мирас» белән бергә булыгыз!

ИНДЕКС:
Татарстанда – 54132 (П-2343)
Россиядә – 70275

«Безнең мирас» журналына башкача язылу:

- *www.uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә*
- *редакциядә*
- *www.tatpodpiska.ru сайты ярдәмендә электрон версия*

4 612750 670172

«Безнең мирас» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» (Бауман ур., 19; 29/11) кибетеннән, «Татмедиа» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), Казан киоскларыннан сатып алырга мөмкин.

Безнең мирас
№05 / 2016